ДИҢГЕЗ ҮЗЕБЕЗДӘ

Чит илгә юллама кыйммәтләнгәч, халык Россия буйлап сәяхәт итә

> 5

БУШ НИГЕЗ

«ВТ» хәбәрчесе өч кешелек Берлек авылында яшәүчеләрнең хәлен белеште

> 15

ӘСХӘТ ХИСМӘТ:

«Йөрәк белән җырларга кирәк»

> 18

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 84 (29051) | Җомга | 16 июнь | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

Марат Хабибуллин коллажы

ЧЕБЕШЛӘРНЕ КҮМГӘЧ САНЫЙЛАР

ӘРӘМ БУЛГАН КОШЛАР ӨЧЕН КЕМ ҖАВАП ТОТАР?

Эшмәкәрләр дә, гади халык та зар елый. Кемдер керемсез, бурычлары белән утырып калса, кемдер акчадан да, иттән дә мәхрүм булган. Тукай районының Шилнәбаш авылындагы «Илфат» фермер хуҗалыгыннан сатып алынган меңләгән чеби кайтып җитәр-җитмәс үлә башлаган. Республиканың дистәләгән районыннан әнә шундый хәбәрләр килде. Сәбәбе нәрсәдә? «ВТ» хәбәрчесе әлеге четерекле сорауга җавап эзләде.

> 6

Ишетми калмагыз

Зиннәтулла Билалетдинов киләсе сезонда да «Ак барс»ның баш тренеры вазыйфасын башкарачак. Ул Казан клубы белән бер елга килешү төзегән. «Яңа килешү төзү турында карар кабул итү җиңел булмады. Команда белән ярты ел эшләдем, башлаган эшне төгәллисе килә. Егетләр зур җиңү тәмен татысын дип телим», – диде баш тренер. Билгеле булганча, Зиннәтулла Билалетдинов «Ак барс»ка узган сезонда әйләнеп кайтты һәм баш тренер вазыйфасында Олег Знарокны алмаштырды. Казан командасы аның җитәкчелегендә Гагарин Кубогы финалына кадәр барып җитте һәм җиде матчка сузылган сериядә ЦСКАга оттырды. Зиннәтулла Билалетдинов «Ак барс» белән 2009, 2010 һәм 2018 елларда Гагарин Кубогын яулаган иде.

Быел Татарстанда 2464 янгын чыккан. Узган елның шул ук чоры белән чагыштырганда, бу – 22 процентка күбрәк. Әлеге мәгълүматны Министрлар Кабинетында узган утырышта Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстандагы Баш идарәсендә күзәтү һәм профилактика эшчәнлеге башлыгы Максим Трущин җиткерде. Янгыннар саны 33 районда арткан. Куркыныч очраклар барыннан да бигрәк Балтач (8дән 18гә җиткән), Зәй (38дән 82гә җиткән), Мөслим (10нан 24кә җиткән), Яңа Чишмә (12дән 40ка җиткән) һәм Чирмешән (17дән 60ка җиткән) районнарында күбәйгән.
Татарстанда булган янгыннарда 57 кешенең (узган елгыдан 5кә азрак) гомере өзелгән, 90 кеше имгәнгән (+11).

Якын араларда республикада явым-төшем көтелми. Шул ук вакытта 30 градуска кадәрге эсселек елларда салкынча һавага алышыначак.
Гидрометеоүзәк хәбәренә караганда, шимбә һәм якшәмбе – 17–18 июньдә, төньяктан салкын һава агымы үтеп керү сәбәпле, һава температурасының акрынлап кимүе күздә тотыла. Шимбә көндез +21...+26 градус, төнлә +9...+14 градус булачак. Якшәмбедә көндез термометрның терекөмеш баганасы +18...+23 градус күрсәтәчәк, төнлә +5...+10, уйсу урыннарда һава температурасы +2...+5 градуска кадәр төшәчәк.
Киләсе атна башында – 19–20 июньдә республикада салкынча һава фаразлыйлар. Көндез һава температурасы +16...+21 градус чикләрендә тирбәләчәк. Явым-төшем көтелми диярлек.

Татарстанда яз башыннан бирле 5069 кеше, талпан кадалу сәбәпле, табибларга күренергә мәҗбүр булган. Шуның 1057се – Казанда яшәүчеләр. Роспотребнадзорның Татарстан буенча идарәсе матбугат хезмәте хәбәренә караганда, узган елдагыдан – 13 процентка, күпьеллык уртача күрсәткечтән 36,6 процентка зуррак сан бу. Роспотребнадзор белгечләре киңәш иткәнчә, тәнгә талпан кадалган очракта медицина оешмасына мөрәҗәгать итәргә кирәк. Табибка күренү мөмкин булмаса, талпанны тәннән мөстәкыйль рәвештә тартып алып, бөҗәк кадалган урынны спирт яисә йод белән ышку, шуннан соң кулларны сабын белән юу шарт.

Районнарда ни хәлләр?

Аксубай

Тарханка авылы 100 еллык юбилеен бәйрәм итте. Риваятьләргә караганда, нәкъ бер гасыр элек аңа Емельян Пугачев даирәсендәге Чубук (Чәпәк) кушаматлы кеше нигез салган. Тарханка (чуашча Таркән) «Качкын» дип тәрҗемә ителә. Фермер Валерий Салеев төзекләндергән матур буа янындагы мәйданчыкта авыл халкы җыелды. Авылның гасырлык юбилеена Тарханкадан чыккан кунаклар да кайтты. Бәйрәмдә махсус хәрби операция зонасында хәрби бурычын үтәүчеләргә дә рәхмәт әйттеләр.
(«Авыл таңнары»)

Мамадыш

Берничә атна элек Ямаш авылы мәчетендә янгын чыккан иде. Аны бер сәгать эчендә сүндереп өлгерсәләр дә, янгын мәчет бинасының шактый өлешенә зыян китергән иде. Шуңа да бу урында яңа мәчет салырга карар кылдылар. Күптән түгел генә булачак мәчетнең нигезен салдылар. Әлеге тантаналы чарада Мамадышның имам-мөхтәсибе Илһам хәзрәт, Шәдче авыл җирлеге башлыгы Валерий Шрыков та катнашты. Яңа мәчет салу өчен акчаны «Зәкят» фонды белән берлектә җирле халык, хәйриячеләр туплаган. Бинаны кызыл кирпечтән салмакчылар һәм төзелеш эшләрен тиз арада тәмамларга ниятлиләр.
(«Мамадыш-информ»)

Түбән Кама

Түбән Камада яшәүче Андрей Клинов Россиянең трансфузиологлар ассоциациясе донорлар арасында уздырган бәйгедә җиңү яулады. Ул 23 яшендә кан тапшыра башлаган, хәзер аңа 52 яшь. Рәсми мәгълүматларга караганда, Андрей Клинов 152 мәртәбә кан тапшырган. Дөрес, ул үзе бу сан тагын да күбрәк диган фикердә. Илкүләм бәйгедә җиңгән донор алга таба да кан тапшырырга җыена. «Мөмкинлек булганда тапшырачакмын. Кешеләргә ярдәм итә алуым белән горурланам», – дигән ул.
(«Татар-информ»)

Апас

Бөек Ватан сугышы ветераны Зиннәт Хәйруллинны 100 яшьлеге белән котладылар. Зиннәт Кәлимулла улы 100 яшьлеге уңаеннан котлаулар кабул итте. Ут-сулар кичкән, гомерен яшь буынга белем һәм тәрбия бирүгә багышлаган, Фәхри Насретдинов һәм Бану Вәлиева музеен җитәкләгән аксакал, Татарстанның атказанган укытучысы, РСФСР мәгариф отличнигы ул. Район башлыгы Айрат Җиһаншин ветеранның өенә барып хәлен белеште, Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Миңнехановның котлавын ирештерде. Зиннәт Хәйруллин 1941 елның 25 августында фронтка китә, Мәскәү, Калуга, Смоленск, Калинин, Брянск өлкәләрен, Белоруссия, Польшаны азат итүдә катнаша. Җәйләрен Шәмбалыкчы авылында яши, кыш көне Казандагы фатирына китә.
(«Апас-информ»)

ИРТӘГӘ БҮГЕН БАШЛАНА

tatarstan.ru

Йөртүчесез «КамАЗ» машиналары, каһвә ясаучы робот һәм йөзгә якын делегация вәкиле. Чәршәмбе көнне илнең Төньяк башкаласында Петербург халыкара икътисадый форумы башланды. Анда Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов җитәкчелегендәге республика делегациясе дә катнаша. Бүген узачак пленар утырышта Владимир Путинны да көтәләр.

Уены-чыны бергә

Петербург халыкара икътисадый форумы 1997 елдан бирле, пандемия чорыннан кала, ел саен уза. Аның үткәрелү урыны да үзгәрешсез. 2005 елдан бирле әлеге чарада Россия Президенты да катнаша. Быел форум технологик суверенитетка багышланган. Шуңа күрә дә Татарстан стенды IT технологияләргә багышланган.

– Безнең төп шигарь – «Татарстан – киләчәк инде бүген үк». Республика делегациясе вәкилләре форумда катнашучыларны инновацияле эшләнмәләр, Россия компьютерлары һәм ноутбуклары белән шаккатырачак. Павильонда берничә робот та бар, – дип сөйләде форум ачылганчы ук Татарстан Инвестицион үсеш агентлыгы җитәкчесе Талия Миңнуллина.

Татарстан стенды янәшәсендә кунакларны каһвә ясаучы робот-бариста каршы ала. Шунда ук робот-кул белән «таш – кайчы – кәгазь» уены да уйнап алырга мөмкин. Ә стенд өстендәге махсус экранда пилотсыз аппарат «очып йөри». Бу – «Иннополис»ның яңа эшләнмәсе.

Талия Миңнуллина әйтүенчә, быел республикадагы күп кенә компанияләр форумда катнашу теләген белдергән.

– Татарстан стенды ул – республиканы тәкъдим итү урыны гына түгел, ә иң беренче чиратта – эш мәйданы. Гомумән, йөзгә якын вәкаләтле зат һәм бизнес вәкилләренә эш өчен бөтен шартлар да тудырылган, – диде ул.

Йөк ташу җиңеләя

Безнең «КамАЗ»лар Петербург халыкара икътисадый форумында катнашучыларны шаккатырырга өлгерде инде. Җыен кысасында «М11» федераль трассасында Санкт-Петербургтан Мәскәүгә төягә тапкыр пилотсыз йөк машиналары юлга кузгалды. Цифрлы «КамАЗ»лар киләчәктә ике шәһәрнең логистика терминаллары арасында хәрәкәт итәчәк дип фаразлана. Әлегә йөртүчесез йөк машиналары өчәү, июльдә аларга тагын өч «КамАЗ» өстәләчәк. Тантаналы чарада Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов та катнашты.

– Без пилотсыз автомобиль техникасын җитештерү юнәлешендә берничә ел эшлибез. Хәзер бу эшнең яңа баскычына чыктык – йөртүчесез йөк машиналары хәрәкәте башланды, – диде заводның генераль директоры Сергей Когогин.

Сынау барышында саклык чараларын үтәү өчен, «КамАЗ»ларга машина йөртүчеләр дә утырган. Алар хәрәкәтне күзәтеп барган. Сүз уңаеннан, йөк машиналары тиешле урынга бер сәгатькә иртәрәк тә килеп җиткән. Юл якынча тугыз сәгать дәвам иткән. Йөк машиналары ике араны сәгатенә 80 чакрым тизлектә узган.

Эш һәм аш

Татарстан йөк машиналары белән генә түгел, очкычлар белән дә дан тота. Саха (Якутия) Республикасы Татарстаннан «Ту-214» очкычларын сатып алырга ниятли. Бу хакта форумда билгеле булды. Республика Хөкүмәте «Туполев» ГАҖ белән килешү төзеде. Алдан алынган мәгълүматларга караганда, «Якутия» авиакомпаниясенә елына 12 очкыч кирәк булырга мөмкин. Килешү имзалаганнан соң, Рөстәм Миңнеханов Саха (Якутия) башлыгы Айсен Николаев белән дә очрашты. Сөйләшү барышында Айсен Николаев Якутиядә Федераль Сабан туе үткәрергә тәкъдим итте.

Тагын бер яңалык: Казанда өлкән сыйныф укучылары өчен агрогенетика буенча «Иннагрика» бөтенроссия бәйгесенең бер этабы узачак. Бу хакта Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнехановның «Иннопрактика» компаниясе генераль директорының беренче урынбасары Наталья Попова белән очрашуы барышында билгеле булды. Әлеге бәйгенең төп максаты – авыл хуҗалыгы һөнәрләренә карата кызыксыну уятудан гыйбарәт. Бәйгенең ярымфинал өлешләре исә илнең дүрт төбәгендә, шул исәптән Татарстанда узачак.

Татарстан Рәисенең Кытай милли химия-инжиниринг төркеме (CNCEC) идарәсе рәисе Дай Хаген белән очрашуында үзара файдалы хезмәттәшлекне тирәнәйтү турында сөйләштеләр. Рөстәм Миңнеханов әйтүенчә, безнең икеяклы мөнәсәбәтләрнең яхшы үрнәге бар. Мисал итеп ул Менделеевскида тормышка ашырылган проект (Аммоний) турында әйтте. Гомумән алганда, Кытай – илебезнең стратегик партнеры, дип билгеләп үтте Рөстәм Миңнеханов.

Икътисадый форумда Татарстан Рәисе «Мегафон» ГАҖ генераль директоры Хачатур Помбухчан белән дә очрашты. Очрашуда элемтәне яхшырту турында сөйләштеләр. «R1» генераль директоры Дмитрий Руетт һәм «БРОЗЭКС» компанияләре төркеменә нигез салучы Вячеслав Брозовский белән очрашу барышында Рөстәм Миңнеханов «Тура 2.0» сәнәгать паркы территориясен үстерү турында сөйләде. Ул әлеге мәйданны инвесторлар өчен отышлы урын дип атады.

Татарстан банклар белән дә хезмәттәшлекне ныгытырга тели. Мәсәлән, Рөстәм Миңнехановның «АБ «Россия» АҖ идарәсе рәисе Михаил Клишин белән очрашуында икеяклы эшчәнлекне тагын да көчәйтү фикере әйтелде. Очрашу ахырында «Россия» банкы һәм «КАМАЗ» ГАҖ арасында хезмәттәшлек турында килешү имзаланды.

Ерактагы якын төбәкләр

Петербург халыкара икътисадый форумында Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов Ставрополье крае губернаторы Владимир Владимиров очрашты. Смоленск өлкәсе губернаторы вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Василий Анохин белән ике арада хезмәттәшлек турындагы килешүгә кул куйдылар. Исегезгә төшерәбез: Василий Анохин 2023 елның мартында Смоленск өлкәсе губернаторы вазыйфаларын вакытлыча башкаручы итеп билгеләнде. Вице-губернаторларның берсе итеп Татарстаннан Алмаз Әхмәтшин сайланды (ул моңарчы Татарстанның Нурлат районы башлыгы вазыйфасын башкарган иде).

Тыва Республикасы башлыгы Владислав Ховалыг белән очрашу барышында ике республика арасында хезмәттәшлек турында килешүне тормышка ашыру буенча чаралар планын имзаладылар. Карелия Республикасы башлыгы Артур Парфенчиков белән очрашуы да элемтәләрне ныгытуга корылган иде.

Халыкара икътисадый форум кысасында Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов Россия вице-премьеры – сәнәгать һәм сәүдә министры Денис Мантуров белән дә очрашты. Чарада республиканың сәнәгать секторын үстерү, тармакка дәүләттән ярдәм чаралары күрсәтү турында фикер алыштылар, дип хәбәр итә Рәиснең матбугат хезмәте.

Форум 17 июньгә кадәр дәвам итәчәк.

Эльвира ВӘЛИЕВА

Антон СИЛУАНОВ, Россия финанс министры:
– Җирле бизнес вәкилләре бездән чыгып киткән чит ил компанияләрен бу кадәр тиз алмаштыра алачак дип көтмәгән дә идек. Без технологик суверенитетны тәэмин иттек, бәйсез системалар булдырдык. Хәзер шуның ярдәмендә алга таба барачакбыз. Узган елны начар тәмамламадык. Бездә чынбарлыкка карата «антитәнчек»ләр барлыкка килде. Хәзер башкалар авырсын әнә. Бүген безнең төп бурыч дөньякүләм икътисад «бәлеш»еннән мөмкин кадәр зуррак кисәк кисеп алудан гыйбарәт. Дөнья күләмендәге үзгәрешләр башка илләр, шул исәптән элек әйдәп баручылар булып саналган илләр өчен бик авыр уза.

ЫШАНЫЧ ТАНЫКЛЫГЫ

Гаиләләрне сакларга кирәк! Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин җәмәгать судьяларына аерылышу турындагы эшләрне караганда аеруча игътибарлы булырга киңәш итте. Бу хакта ул аларга парламент бинасында таныклык тапшырганда әйтте.

tatarstan.ru

Фәрит Мөхәммәтшин сүзләренә караганда, аерылышуларның 80 проценты диярлек суд карарлары нигезендә рәсмиләштерелә. Шул ук вакытта кайбер районнарда аерылышу буенча ир белән хатын катнашмаган утырышларда кабул ителгән карарлар күп булган. Апаста андый карарлар – 50, Лаешта – 50, Яңа Чишмәдә – 54,5, Нурлатта 75 процентны тәшкил итә. «Проблема даими игътибар таләп итә. Ир белән хатынны татулаштыру өчен активрак чаралар күрергә, мондый эшләрне читтән торып карауны мөмкин булганча киметергә, судта ир белән хатынның үзләрен катнаштыруга өстенлек бирергә кирәк. Ныклы гаиләләр – безнең һәм балаларыбызның киләчәгенең нигезе», – диде Фәрит Мөхәммәтшин.

Дәүләт Советында республиканың 17 суд участогыннан килгән җәмәгать судьяларына эш таныклыклары тапшырдылар. «Җинаять, гражданлык, административ эшләрне карау сездән барлык хокук тармаклары буенча яхшы әзерлек һәм белем таләп итә», – диде парламент башлыгы. 2022 елда Татарстанның җәмәгать судьялары тарафыннан 760 меңнән артык эш һәм материал каралган.

Фәрит Мөхәммәтшин җәмәгать судьялары республика җитәкчелегенең һәм аларны җәмәгать судьялары итеп сайлаган парламент депутатларының ышанычын акларлар дигән өметен белдерде. «Хәзерге судья профессионал булырга, законны төгәл үтәргә, намуслылык һәм бәйсезлек үрнәге булырга тиеш, – диде ул. – Һәм, әлбәттә, ул югары хокукый культурага ия булырга тиеш. Мондый судьяга кешеләр ышаначак, ә аның эше, процессны кимчелексез алып баруы җәмгыятьтә суд хакимиятенең абруен күтәрүгә хезмәт итәчәк».

Сентябрьдә – өстәмә сайлау

Татарстанда 10 сентябрьдә җирле үзидарә органнарына депутатларны өстәмә сайлау узачак. Барлыгы 36 районның 149 округында җирле үзидарә органнарына депутатларны өстәмә сайлау уздыру күздә тотыла. «Бердәм Россия» партиясе 121 мандат алуны планлаштыра. «Бердәм Россия»нең Татарстандагы төбәк бүлеге политсоветы Президиумы утырышында шул хакта сөйләштеләр. Утырышны төбәк бүлеге Секретаре, Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин уздырды.

Фәрит Мөхәммәтшин партиядәшләрен яңа шартларда сайлау кампаниясен үткәрүне аерым игътибар үзәгендә тотарга чакырды. «Бүгенге шартларда, барлык дәрәҗәләрдә (район, шәһәр, республика, федераль) хакимиятнең вәкиллекле органнары парламентларын булдыру, Россия Президентын, Татарстан Рәисен сайлау буенча өч еллык сайлау циклына кергән бер мәлдә, безгә – партия активына әлеге сайлау кампанияләрен уңышлы үткәрү буенча җитди эш алып барырга кирәк булачак, – дип басым ясап әйтте ул. – Куелган бурычлар арасында – партиянең аерым бер җирле бүлекләрендәге кимчелекләрне бетерү. Политсовет бу җәһәттән тиешле карар кабул итте. Ул республиканың барлык шәһәрләре һәм районнарына җибәреләчәк».

Фәрит Мөхәммәтшин Лисичанск шәһәрендә яшәүчеләргә гуманитар йөк җыеп юллауда актив катнашучы партиядәшләренә рәхмәт белдерде. «Партиядәшләребез генә түгел, бәлки сәнәгать, халык хуҗалыгының башка тармаклары вәкилләре дә бик күп гуманитар йөк юллады. Бурычыбыз – сафларыбызны тагын да ныгытып, уңышларга ирешү», – дип билгеләп үтте партиянең Татарстандагы төбәк бүлеге Секретаре.

Сүз уңаеннан, Татарстан, төбәкләр арасында беренчеләрдән булып, Белгород өлкәсендә яшәүчеләргә дә ярдәм җибәрде.

Махсус хәрби операция башланганнан бирле бердәмроссиялеләр республикадан Луганскига гуманитар ярдәм төялгән 93 йөк машинасы (барлыгы 1300 тоннадан артыграк) озаткан инде.

КҮРГӘННЕ ӘЙТӘСЕ



Илдар Мөхәммәтҗанов

Быел Татарстанда 125 кешене бер тапкыр исерек килеш эләгеп, кабат салган баштан рульгә утырган өчен җинаять җаваплылыгына тартканнар. Административ җәза алучылар – 5568 кеше. Куркыныч саннарны Татарстанның юл хәрәкәте иминлеге буенча баш дәүләт инспекторы Рөстәм Гарипов җиткерде.

Быелның биш аенда гына да исерек килеш машина йөртүчеләр гаебе белән килеп чыккан 50 юл һәлакәтендә алты кешенең гомере өзелгән, 62 кеше имгәнгән. Чагыштыру өчен: узган елның шул чорында республика юлларында алар китереп чыгарган 80 юл һәлакәтендә 15 кешенең гомере өзелгән, 105 кеше имгәнгән булган. Әмма хәмер белән дус булучы еш кына бер тапкыр авызы пешкәч тә өреп капмый.

– Кызганыч, исерек килеш машина йөрткән өчен инде бер тапкыр җаваплылыкка тартылган кешеләр кабат шушы адымга бара. Хәтта җинаять җаваплылыгына тартылган кешеләр дә кабат исерек килеш рульгә утыра, – диде Дәүләт автоинспекциясе башлыгы.

Журналистлар белән очрашуда подполковник Гарипов исерек йөртүчеләргә каршы бергәләп көрәшергә чакырды.

– Кешенең исерек килеш рульгә утырганын күрсәң, ачкычын тартып алырга, аны туктатып калырга тырышырга, ул да булмаса, ЮХИДИ хезмәткәрләренә хәбәр итәргә кирәк. 112 яки 02 номерлары буенча шалтыратырга яки ЮХИДИ идарәсенең «Телеграм»дагы махсус сәхифәсенә язарга мөмкин. Фаҗига килеп чыккач, күпләр без аның исерек икәнен белә идек, ди. Шуңа күрә әләкләү түгел бу, күпме фаҗигане булдырмыйча, никадәр кеше гомерен саклау калу, – диде ул.

Язучы сүзе

Колорадо коңгызы

Дөньяда колорадо коңгызыннан да хәстәрлеклерәк зат бар микән? Әйтеп булмый. Әле бәрәңге чыгып та өлгермәгән, болар һәр төпкә бишәр-алтышар булып чиратка басып, көтеп утыралар. Ә бәрәңге чыкмый, тегеләрнең киткәнен көтә.

Мин моңа карыйм да ни әйтергә дә белмим. Кешеләр дөньясы да шулайрак бит инде, бер карасаң. Бездә дә бит талантлы, акыллы кешеләрнең туганын көтәләр. Ул тусын, нәрсәләрдер эшләсен, тормышны алгарак җибәрсен өчен дип уйлыйбыз бит инде. Юк икән. Монда да шул колорадо кортлары кебек теге талантның башын ашарга дип өметләнеп утыручылар җыелган икән. Кайчагында шулай тоела. Ниндидер талант килеп чыккан хәлдә дә аны үстермиләр бит, үсендерәләр генә. Хәтта үзе үсәргә маташып үҗәтләнсә дә, ирек бирмәскә тырышалар. Бәрәңгенең һәр ботагына, һәр яфрагына чат ябышкан коңгызлар кебек кыланалар. Нәтиҗәдә теге талантлы бахырның йөрәге колорадо коңгызы теткәләп бетергән бәрәңге яфрагы кебек булып кала. Корый талант иясе, юкка чыга.

Гаепләп әйтмим моны, бәлки, чынлап та шулай булырга тиештер ул. Бәлки, бу – һәр иҗатчы, һәр галим узарга тиешле санаусыз сынауларның берседер. Бәрәңгенең коңгызга бирешми торган сортлары да бар бит. Сәләт ияләре дә бәлки шундый төрләргә бүленәдер, бирешми торганнары гына җиңеп чыгадыр. Шулай тиештер.

Ә колорадо коңгызыннан берничек тә арынып булмый. Колак очы гына күренеп торган бәрәңгегә агу сибәргә кул бармый. Җыеп карыйбыз. Кичтән җыеп чыгасың, иртән теге кортлар тагын тезелешеп утыра. Иске бәрәңгене урталай ярып торым-торымга куеп чыгарга кирәк, диләр. Бу кортның игътибарын былтыргы бәрәңгегә юнәлтү өчендер инде. Мантыйк буенча шулай. Куйдык. Тик колорадо коңгызының мантыйгы кешеләрнеке белән бер түгел икән. Ярылган бәрәңгене чынлап та берничә корт сырып алган. Тик яңалары төбендә берниндй үзгәреш юк. Һаман шулай җыелышып көтеп утыралар. Әллә нинди киңәшләрне тыңлап, әллә ниләр кыландырып карадык, файдасы юк. Шуңа рецептларын язып тормыйм. Иң файдалы һәм зарарсыз ысул, минемчә, берәү генә: ата коңгызларны җыеп алырга да печеп (стерилизация ясап) чыгарып җибәрергә. Шул очракта ана коңгызлар күкәй сала алмый, салсалар да, ул кысыр була.

Бәрәңгене сакларга кирәк инде. Ул бит бөтен халыкны туйдыра. Ә коңгызның бер файдасы да юк. Чынлап та шулаймы соң? Колорадо корты белән көрәш өлкәсендә кемнәр генә эшләми! Галимнәр. Аларның төрлесе бар. Берәүләре коңгызның организмын, икенчеләре үз-үзен тотышын, таралу мөмкинлекләрен, өченчеләре аны юк итү ысулларын, дүртенчеләре төрле агулар уйлап таба, бишенчеләре шул агуларны сиптерүче җайланмалар өстендә эшли, алтынчылары бәрәңгенең яхшырак сортларын уйлап таба, сигезенчеләре… Санасаң, бик озакка китә икән. Сәнәгать өлкәсе. Агуның үзен ясыйлар, сиптерү җайланмалары эшлиләр. Агу сиптергәндә агуланудан саклый торган киемнәр тегәләр. Авыл хуҗалыгы, табигатьне саклау министрлыклары. Икътисад белгечләре. Сәүдәгәрләр. Реклама хезмәте. Чынлап санасаң, колорадо коңгызы ул безнең бәрәңге бакчасында гына түгел, ул тормышның барлык өлкәләренә дә диярлек үтеп кергән икән. Бу дөньяда миллионлаган, миллиардлаган кеше шул корт белән көрәш өлкәсендә эшли, шуның өчен акча ала. Акча ала! Менә шуннан соң төгәл генә әйтеп кара инде: бәрәңгә күбрәк туйдырамы кешеләрне, әллә колорадо коңгызымы? Әгәр колорадо коңгызын тулысынча юкка чыгаралар икән, шушы өлкәдә эшләүчеләрнең барысы да эшсез, димәк, акчасыз, кала. Шулай булгач, нинди галим үз ихтыяры белән бу коңгызны бетерә торган агу эшләсен инде?!

Кул селтәдем әле бәрәңге бакчасына. Кортларга карап үртәлергә дә, агуларга да, башкача этләнергә дә кирәкми бугай. Бернинди каршылыкларга да бирешми торган талантлы, акыллы, көчле кешеләргә охшаган бәрәңгеләр барыбер үсеп чыгар әле. Азрак булыр, әлбәттә, андыйлар бик күп була алмый. Аның каравы берни белән агуланмаган талантлы, акыллы көчле бәрәңге ашарбыз. Ул файдалырак та, тәмлерәк тә булыр. Аз ризык һәрвакыт тәмле була.

Марат КӘБИРОВ

Әйтеп кенә бактым

Телдән язу

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

Мари Элдагы Раилә исемле кызны тиз генә оныта алмам, ахры. Шифаханәгә килүчеләрне теркәп утыра ул. Беренче күрүгә, урысчалатып: «Как вас зовут?» – дигән булдым. «И» хәрефенә басым ясап: «Раиля», – ди бу.

– И-и... үзебезнең татар кызы икән бит! Мин шулай диюгә, татарча күчте.

Татарстаннан түгел икән, Мари Эл Республикасындагы Күлбаш дигән авылда туып-үскән, мәктәптә татарча укыган. Тик менә хәзер аралашырга татарлар юк, дөресрәге, бик аз. Шуңа күрә безгә сөенде Раилә. Урысча бер сүз дә кыстырмыйча рәхәтләнеп сөйләшә. Аз-маз гына марича да сукалый. Ире – мари, әмма үз телен белми икән. Шуңа күрә гаиләдә расча-татарча аралашалар. Үз өстенә бик зур вазыйфа алган Раилә: балаларын татарчага өйрәтә. «Өч балам бар», – дигәч, егылып китә яздым. «Сине әле кычкыртып кияүгә бирерлек бит», – дим. Чыннан да, чибәрлеге өстенә бик яшь күренә иде Раилә. Бактың исә, олы малаена инде 17 яшь икән.

Җай туры килгән саен, аның белән аралашырга тырыштым. Һәм ана телен чиста, саф килеш саклый алуына сокландым. Чит республикада туып-үскән кызның: «Ана телен оныткан татар кем була инде ул?» – дип гаҗәпләнүе минем үземә бик гаҗәп тоелды. Безне – Татарстан татарларын бераз тәнкыйтьләп тә алды Раилә: «Сезнекеләр ни өчендер күбрәк русча сөйләшә. Мин шатланашатлана татарчага күчәм, ә алар русча җавап бирә. Кызык, әйеме, абый!» – ди.

Бер дә кызык түгел инде бу, Раилә сеңлем. Ана телебезне дәүләт теле дәрәҗәсенә күтәргән закон яшәгән татар илендә нигә шулай кыланабыздыр?! Бездә урысча сөйләшкән кеше үзен акыллырак хис итә кебек. Татарча белмәүләре белән горурланучылар да очрый әле. Бер танышым, җае туры килгән саен, дусларының бары тик урыс милләтеннән булуы белән мактанырга ярата. «Я учился в русской школе!» – дип безгә өстән аска таба карап куя. Без аның белән еш аралашабыз, дөресрәге, шулай туры килә. Чөнки уртак эшләребез бар.

Беркөнне чираттагы мактануыннан соң ада: «Ярар, урыс мәктәбендә укыдың да ди, а дальше что? Сиңа татарлар белән дә урысча гына сөйләшергә кушмаганнардыр бит!» – дидем. Начар егет түгел ул үзе, аптырап, каушап калды. Ык-мык килде, «извините» дип мыгырданды.

Извиняем, брат, извиняем, а какой толк?

Үземнең дуслар арасында төрле милләт кешеләре бар. Алар минем белән сөйләшкәндә берәр татар сүзе дә кыстыргалый әле яки берәр татар җырын көйләп куя. Күңелем булганны күреп шатланалар.

Мин мари җирендә мариларның үз телендә сөйләшеп маташтым һәм абруем күтәрелде, минем түгел, милләтемнең абруе. Юкса алар татарны мактап сөйли башламас иде, берсеннән-берсе уздыра-уздыра дигәндәй, Мари Эл Республикасындагы татар авылларын, татар районнарын санарга тотынмаслар иде. Үз милләтен яратмаган кеше башка милләтләрне дә ярата алмый инде ул. Мин яшь чактан ук: «Без национализма не может быть интернационализма!» – дип сөйләп йөрим. Аңлаган кеше аңлый, аңламаганы – юк. Үзенә үпкәләсен.

Милләтара мөнәсәбәтләр, тел саклау турында сүз чыкса, мин хәзер Раиләне телгә ала башладым. Ул кайбер ата-аналар кебек: «Татар теле белән кая барасың?» – дими. Андый уй Раиләнең башына да кереп карамый. Язганымча, ана телен телгә санамаган татарга гаҗәпләнә ул. Ә безнең кайберләребез өчен бу – табигый хәл, алай гына да түгел, шул «кайберләребез» урысча сөйләшүне үзләрендә акыл үсешенең иң югары дәрәҗәгә җитүе кебек кабул итә. Телдән язганнар, һәрхәлдә, шулай уйлый дип беләм.

ӘКИЯТ ДӨНЬЯСЫ

Әгәр сез татар халык әкиятләрен укып үскән булсагыз, кеше кыяфәтендәге юха еланнарның адәм балалары арасында яшәүләре, кайбер егетләрнең шуларга өйләнеп, аздан гына фаҗигагә тарымыйча калулары турындагы тәнгә каз итләре чыгара торган маҗаралар белән танышмый калмагансыздыр.

Әкият әкият инде ул, укыйсың, гыйбрәт аласың. Сабый чакта аның тәэсирендә төнлә куркып йоклый алмый ятарга да мөмкинсең. Әмма кайчан да булса җитди кешеләрнең – зур галимнәрнең, сәясәтчеләрнең рептилоидларның – көлтә еланнарның кешелек җәмгыятен үз кулларында тотулары турында теорияләрне алга сөрә башлаячагын әйтсәләр, син хәтта сабый акылың белән дә аңа ышанмас идең. Шагыйрь әйтә бит әле: «Эх сез, шомлы әбием әкиятләре, Кая сезгә җитү чынлыкны?! Сүз җитәрме сөйләп аңлатырга, Бу йорттагы вәхшәт, коллыкны!» – дип. Бүген глобаль кешелек дөньясында бара торган вакыйгалар һәм аларга бирелә торган рәсми аңлатмалар халык әкиятләрен күпкә артка калдыра.

Глобаль системалар җимерелгәндә, һәрвакытта да мистика алгы планга чыга. Хәтерлик әле, элекке совет кешеләре, социалистик системаның асты-өскә килгән үткән гасырның сиксәненче еллары ахырында матбугатта оча торган тәлинкәләр, илнең төрле почмакларындагы аномаль урыннар турында язмалар ничек еш басыла иде! Экстрасенс-сихерчеләр ничек күп үрчеде! Капитализм килү белән, алар берникадәр артка чиктеләр, «сары» матбугат өлеше генә булып калдылар. Укучылар дөрес аңласын: автор һич кенә дә кешеләрдәге экстрасенсор сәләтләрне кире кагарга җыенмый. Бер истәлек: 1978 елда Корчной – Карпов арасында планетакүләм шахмат таҗы өчен көрәш бара. Илен ташлап, каршы лагерьга күчкән Корчнойның көндәшен үзенә каршы көрәштә КГБ экстрасенслары куллануда гаепләве очраклы түгел иде. Мин хәтерлим әле ул матчларны. Совет пропагандасы Корчной – Карпов дуэлен капиталистик һәм социалистик системаларның көрәше рәвешендә тәкъдим итте һәм совет шахматчысының җиңүе ул чакта принципиаль һәм хәлиткеч мәсьәләгә әверелде. Ышерен хезмәтләр исә, гафу итегез, һәрвакытта да сихерчеләр белән актив хезмәттәшлек итәләр.

Социалистик система җимерелү белән, паранормаль (аңлатуга бирелми торган) күренешләр белән кызыксыну кимеде, фантастик сюжетлар өлкәсенә күчте, психикасы тотрыклы ук булмаган аерым төркем кешеләрнең хирысльк объектына әверелделәр. Ләкин конспирологик теорияләр (заговор теорияләре) буларак туктаусыз үстерелделәр. Аерма шунда гына иде: ул теорияләр белән мавыгучыларны җитдигә алмадылар, мокытлар буларак карадылар. Заговор теориясенең асылы шунда: кешелек җәмгыятендә бара торган вакыйгаларның артында йогынтылы һәм куәтле яшерен төркемнәр тора, шулар ясалма рәвештә хаос китереп чыгаралар дип аңлатыла. Планета белән идарә итәргә омтылучы Рим клубы, Бильдерберг клубы кебек оешмалар бар ул чынлап та. Аларның эшчәнлеге безнең өчен күп очракта яшерен булып кала.

Заговор теориясенең әкияткә якынрак тармаклары да яшн. Кешелек җәмгыяте белән кеше кыяфәтендәге еланнар – рептилоидлар идарә итә дигәне, мәсәлән, шундыйлардан. Рептилоидлар галәмнән килде дигән идея дә актив үстерелә. Коронавирус пандемиясе башлану белән, аның кешелек җәмгыятен юк итү өчен уйлап табылган ясалма корал булуы хакында идея таратылды. Ашыгыч рәвештә уйлап табылган һәм бөтен кануннарга каршы килеп, бернинди сынаусыз кешелек җәмгыятенә көчләп тагылган вакцинаны заговор нәтиҗәсе булуына ышанучылар җитәрлек иде. Американың вакцина җитештерүче Pfizer фармкомпаниясе җитәкчесе Альберт Бурланы рептилоид дип ышандыручылар да күп булды. Бурла исә үз продуктын үзе шундый итеп рекламалады: дүрт тапкыр вакцина ясатканнан соң да ковид белән чирләп күрсәтте.

Альберт Бурланың рептилоид булуы турындагы идеяне аерып алыйк әле әйдә. Мөмкинме бу хәл? Аек акыл кире кага, билгеле. Ничек инде бар кешелек дөньясына мәгълүм шәхес юха елан булсын ди?! Күчерелмә мәгънәдә куллана алабыз, әмма физик тән сыйфатында безнең каршыда әкият персонажының басып торуына ышану, гафу итегез, чиктән узган мокытлык бит инде. Үз-үзен хөрмәт иткән бер генә аек акыллы кеше дә бу хакта җитди сүз кузгалтмас. Вәләкин... «Российская газета»ның телеграм-каналын ачабыз да укыйбыз: «Инопланетяне посещали Землю много раз и сейчас они среди нас, заявил профессор Стэнфордского университета Гарри Нолан». Нолан, чит планета вәкилләре (рептилоидлар, юхалар дип укый аласыз) безнең арада һәм без алар белән бик еш очрашабыз, әмма аларның юха икәнлеген аңлый алмыйбыз, дип бик җитди сөйләшә. Татар халык

wallpaperstock.net

әкиятенең заманча вариантына нык охшаган, тик чын итеп тәкъдим ителә. Быел кышын америкалыларның күктәге билгесез объектларны бәреп төшерү белән мавыгуларын, оча торган тәлинкәләрнең планетаның әле бер, әле икенче почмагында еш күренүе турындагы төрле илләрнең рәсми хәбәрләрен искә төшерик. Фейк белән рәсми хәбәр арасындагы чикне билгеләү бик кыен хәзер, чөнки тотальләнгән таралган шартларда яшибез.

«Российская газета»ның 2020 елгы 9 декабрь санын ачыйк әле. «Израиль и США уже несколько лет назад «установили контакт» с инопланетянами, входящими в «Галактическую федерацию», но «держат это в секрете, чтобы не вызвать панику среди землян». Об этом заявил в интервью израильскому изданию Yediot Aharonot бывший глава программы космической безопасности, трижды лауреат премии Israel Security Award 87 летний профессор Хаим Эшед», – дигән юлларны укыйбыз. Козьма Прутков: «Фил читлегендә «буйвол» дигән язу күрсәң, үз күзләреңә үзең ышанма», – дип әйтә бит әле. Шул хәл инде бу. Россия сәясәте орбитасына атылып килеп чыккан бер күренекле персонаж күпләп таратылган рәсми хәбәрләргә: «Барон Мюнхаузен ял итә», – дип бәя бирде. Килешмичә булмый ул бәя белән. Җәмгыятьчелек фикерен иң булмастай хәбәрләрне дә кабул итүгә әзерлекнең алгоритмы исә әзлекле рәвештә тормышка ашырыла. Кичә юләрлек дип кабул ителә торган фактлар бүген чынбарлык рәвешенә керә һәм халык аны дөреслек дип кабул итә башлый. Хаим Эшед чит планета вәкилләре белән контактлар турында биш ел элек сөйләсә, клиникага эләккән булачагын белдерә. Хәзер инде (2020 ел ахырында) мәгълүматны игълан итүнең куркыныч булмавын әйтә. Дөньяның күренекле галимнәре арасында чит планета вәкилләренең (рептилоидларның) кешеләр белән яшәве, гаилә корулары, балалар үрчетүләрен ышанып кабул итү тенденциясенең өстенлек алуын да белдерә.

Миләрне бертуктаусыз юдыру нәтиҗәсендә кешеләрнең аналитик фикерләү сәләте тәмам юкка чыгарылды. Югары белемле һәм үз эшенең остасы булган җитди шәхесләрнең чүп нәрсәләрне чын итеп сөйләүләрен хәзер еш ишетергә була. Сөйләгән сүзләрен дәлилләр китереп кире каксаң, кайвакыт алар үзләре дә аптырыйлар. Кешеләрдә ялганга иммунитет югалу зур тенденциягә әверелде һәм куркыныч төс алып бара. Бу хәбәрләрнең чыганагы кайда булганын һәм аларның нәрсәгә китерәсен белә бу юлларның авторы, ләкин ул хакта яза алмый. Язса, аның адресына психиатрик клиникадан ашыгыч ярдәм машинасы юллаячаклар. Гыйбри Хаим Эшед һәм Стэнфорд профессоры Гарри Нолан калачаклар иректә, мине ябачаклар. Шуңа күрә котылгысыз нәрсәләргә каршы автор көрәшеп азапланмый. Планетада идарә юхалар кулына күчә башлагач, нишләтәсең инде. Халыкларның гипноздан айныганын сабыр гына көтәсе кала.

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Эльвира
ВӘЛИЕВА

ЕРАКТАГЫ КОЯШ

53 мең 923 сум. Җәен каядыр барып ял итү өчен бер кешегә уртача әнә шулкадәр акча кирәк. Халык арасында үткәрелгән сораштыру барышында ачыкланган сан бу. Ераграк юл тоткан саен, чыгымнар да арта, билгеле. Әллә шуңамы, сораштыруда катнашучыларның 40 проценты җәй айларын үз бакчасында гына үткәрергә җыена. Быел ял күпмегә төшәчәк? Татарстанда яшәүчеләр кайда ял итә? «ВТ» хәбәрчесе халык кәефен һәм юллама бәяләрен белеште.

pinterest.com

Ял «тешли»

Җырчы Рифат Зарипов шушы арада гына гаиләсе белән Мисырдан ял итеп кайткан.

– Былтыр ял итәргә барып булмады. Төзелеш алып баргач, ничектер җае туры килмәде. Алдагы елны әниләрне Төркиягә алып барып кайткан идек. Быел апрель азагында концертлар тәмамлангач, уйлаштык та Мисырга юллама сатып алдык. Тарих дәресләрендә өйрәнгән пирамидаларны күптән үз күзләребез белән барып күрәсе килгән иде. Хургадада ун көн ял итеп кайттык. Кунакханәдә туристларга мөнәсәбәт яхшы. Шәһәрдә хәерчелек күзгә ташлана. Гомумән, кайда гына барсам да, үз илебездә, Татарстанда яшәвебез белән горурланып кайтам. Мисырда бөтен нәрсә акчага корылган. Юл белешә башласаң да, акча сорыйлар. Хәтта исәнләшүләре дә бушка түгел. Узган елга кадәр туристларны пирамидаларга якын җибәрмәгәннәр. Хәзер бу рөхсәт ителә. Тик пирамидаларны бераз башкачарак күз алдына китергән идем. Анда туристлар өчен әллә ни шартлар юк, кешеләргә караганда, дөяләр күбрәк. Диңгез чиста. Мәчетләр күп булуы сөендерде. Безгә ял ошады. Гомумән, ял бөтен кешегә дә кирәктер ул. Мөмкинлек булганда әнә шулай дөнья күреп, һаваны алмаштырып кайтырга кирәк.

Рифат Зарипов ялга барып кайтуның күпмегә төшүен әйтмәде. Әмма болай да аңлашыла: җәй көне кешечә ял итәргә теләсәң, иң элек тырышып эшләргә туры киләчәк. Бөтенроссия халык фикерен өйрәнү иҗтимагый үзәге үткәргән сораштырудан күренгәнчә, бу җәйдә ял итү бер кешегә уртача 54 мең сумга төшәчәк. Чит ил кояшы астында ятасың килсә, тагын да кыйммәтрәк түлисе. Ял бәясен саный башлаганчы, кесә ягын тикшереп карыйк. Бу ел башына алынган мәгълүматларга караганда, Татарстанда уртача хезмәт хакы 46 мең сум тәшкил итә. Тагын бер сан: Татарстанда ике бала тәрбияләүче гаиләнең коммуналь хезмәтләр, мәктәп, балалар бакчасы өчен түләү кебек мәҗбүри чыгымнардан соң казнада аена уртача 45 мең сум акчасы кала, ди. Чагыштыру өчен: күрше Башкортстанда әлеге күрсәткеч – 34 мең, Чувашиядә – 23 мең, Ульян өлкәсендә – 19 мең, Киров өлкәсендә 17 мең сум тәшкил итә. Казанда яшәүче ике бала тәрбияләүче дүрт кешелек гаиләгә җәйге ял өчен ким дигәндә дүрт ай киенмичә, ашамыйча-эчмичә яшәргә туры киләчәк, кыскасы. Күршеләргә тагын да читенрәк.

ТУРИСТЛАР ҮЗ ИТКӘН ИЛ ТӨБӘКЛӘРЕ

Төбәк	Узган елның җәе белән чагыштырганда юллама сату күпмегә арткан
Дагыстан	+66%
Краснодар крае	+27%
Кавминводы	+25%
Мәскәү	+19%
Калининград	+16%
Санкт-Петербург	+11%

Туроператорлар ассоциациясе сайтыннан алынды

Кыйммәтле очыш

Каядыр барып ял итәргә телисең икән, акчаны узган ел белән чагыштырганда 20 процентка күбрәк түлисең. Белгечләр әнә шуны исәпләп чыгарган. Ә соңгы ун елда җәйге ялга дигән акча ике тапкыр үскән. Бәяләр «тешләгәнгәме», илдә яшәүчеләрнең 38 проценты бу җәйдә өйдә генә калачак. Төп сәбәбе дә билгеле. Күпчелек: «Җәйге ялга акча юк», – дигән.

– Пандемиягә кадәрге елларны сагынып искә алабыз. Чит ил коящы кыйммәт хәзер. Шуңа күрә халык диңгез буена юллама сатып алырга ашыкмый. Ел башыннан гына да чит илгә юлламалар 30 процентка диярлек кыйммәтләнде, – ди башкалада юлламалар сату белән шөгыльләнүче агентлык хезмәткәре Альбина Дорофеева. – Хәзер халык күбрәк Россия буйлап сәяхәт итә. Чөнки бу – арзанрак. Үзегез чагыштырып карагыз: быел Краснодар краенда – 15 миллион, Ә Төркия ярларында исә 3 миллион Россия туристы ял итәчәк дип көтелә. Бу җәйдә күбрәк Төркия, Мисыр, Берләшкән Гарәп Әмирлекләре, Абхазия һәм Туниска юлламалар сорап мөрәҗәгать итәләр. Очкычлар аз булу сәбәпле, хәзер юллама бәясенең төп өлешен юл хакы алып тора.

Казан – Дагыстан арасы

Әмма каядыр барып ял итәргә күнеккән халык барыбер өендә генә утырырга җыенмый. Чит илгә юллама кыйммәт икән, Россия буйлап сәяхәт итәләр.

– Билгеле вакыйгалар аркасында халык акчасын әрәм-шәрәм итәргә ашыкмый, дисәләр дә, быел халык сәяхәт итүдән баш тартырга җыенмый. Һәрхәлдә, эчке туризмга бәйле вазгыять шул хакта сөйли. Җәй айларына турларның яртысы диярлек сатылып бетте инде, – диде матбугат очрашуларының берсендә Туроператорлар ассоциациясе (АТОР) вице-президенты Сергей Ромашкин. – Без моны психологик яктан аңлатабыз: соңгы арада халык арасында: «Бер тапкыр гына яшибез, рәхәтләнеп ял итеп калыйк!» – дип фикер йөртүчеләр артты. Ил буенча җәйгә юлламаларны гыйнварда ук сатып ала башладылар.

АТОРдан алынган мәгълүматларга караганда, Россия буйлап сәяхәт итәргә яратучылар елдагыча күбрәк Краснодар краена юл ала. Узган ел белән чагыштырганда, бу юнәлештәге юлламаларга сорау 27 процентка арткан. Мәсәлән, быел әзер тур сатып алып Анапага барырга теләүчеләр – 35, ә Геленджикны сайлаучылар 40 процентка күбрәк. Туристлар үз иткән урыннар исемлегенә Мәскәү (+19%) һәм Санкт-Петербург (+11%) та эләккән. Ә менә Кырымга барырга ашкынып тормыйлар.

16 ИЮНЬНӘН ИКЕ КЕШЕГӘ БЕР АТНАГА ИҢ АРЗАНЛЫ ЮЛЛАМАЛАР

Ил яки төбәк	Кунакханәнең дәрәҗәсе	Ялның сыйфаты	Бәясе, сумнарда
Мисыр	4 йолдызлы	Иртәнге, кичке аш	90504
БГӘ	3 йолдызлы	Иртәнге аш	81425
Төркия	3 йолдызлы	Ашау-эчү кергән	81325
Анапа	2 йолдызлы	Иртәнге аш	68969
Дагыстан	1 йолдызлы	Ашаусыз	63486
Калининград	2 йолдызлы	Ашаусыз	55356
Абхазия	Кунак йорты	Ашаусыз	50572
Сочи	1 йолдызлы	Ашаусыз	44905

Tourvisor.ru сайтыннан алынды. Бәяләр үзгәрергә мөмкин

Хәер, быел Кара диңгез буендагы курортларга да көндәш бар. Ел башыннан бирле Дагыстанга юлламалар сатып алучылар 66 процентка (!) арткан әнә.

– Җылы якка барасыбыз килде. Уйлаштык та икәү Дагыстанга юл тоттык. Анда җылы, күләгәдә дә 33 градус, – дип сөйләде әле яңа гына Махачкаладан әйләнеп кайткан Инна һәм Марат Гатауллиннар. – Очкыч белән барып кайту икебезгә 57 мең сумга төште. Дагыстанда азык-төлек бәяләре безгә караганда арзанрак. Мәсәлән, сарык шашлыгының бер килосы 500 сум тора. Юл буенда агачта үсеп утыргач, абрикос, төче чия ише җиләк-җимешне дә чиләге белән генә саталар. Бәясе 400–500 сум тирәсе. Табигате бик матур. Халкы бик үзенчәлекле. Турист ир-атларга мөнәсәбәтләре яхшы, базарда да, урамда да сыйлап кына торалар. Ә менә хатын-кызларны, күзеңә карап торсалар да, күрмиләр. Урамда шорты яки футболка белән йөрсәң, шунда ук шелтә белдерәләр. Аш-сулары безнекенә охшаган: нигездә ит һәм камырдан тора. Туристлар бик күп. Автобуслары иске, саклык каешлары юк, бездә андый техника күптән йөрми инде. Шуңа күрә Дагыстанга балалар белән бармавың хәерлерәк. Гел тауларда йөргәч, төрле урыннарда тукталдык. Мәсәлән, тау итәгендәге кунак йортында бер төн кунып чыгу 6 мең сумга төште. Бу бәягә ашау-эчү кермәгән. Дагыстан – уңайлы, рәхәт ял өчен түгел. Бирегә ныклы физик әзерлек һәм сыйфатлы спорт аяк киеме белән барырга кирәк.

Юлламалар сату белән шөгыльләнүче агентлык хезмәткәре Альбина Дорофеева әйтүенчә, чикләүләрдән соң, Россия буйлап кыска вакытлы сәяхәткә чыгып китүчеләр саны да арткан.

– Узган ел белән чагыштырганда, быел автобуста теге яки бу шәһәргә барырга теләүчеләр ике тапкыр диярлек күбрәк. Шулай ук, шифаханәләргә сорау зур. Быел сәламәтләндерү турлары буенча уртача чек 50 процентка диярлек кыйммәтләнеп, 40–45 мең сумга җитте. Җәй айларына юллама сатып алучыларның өчтән икесе – балалы гаиләләр, – ди белгеч.

Исеме билгеле булган түләү сервисы компанияләренең берсе ил төбәкләрендә яшәүчеләрнең җәйге пакетлы турга күпме акча түләргә әзер булуын да белешкән. Ял дигәндә, иң юмарт халык Мәскәүдә яши. Ил башкаласында ике кешегә ашау-эчү, яшәү кергән ун көнлек юлламаны уртача 146 мең сумга сатып алалар. Алардан Ханты-Манси автоном өлкәсе (140 мең сум) һәм Түбән өлкәсендә (125 мең сум) яшәүчеләр дә калышмый. Сөенегез, беренче бишлектә Казан да бар. Татарстан башкаласында яшәүчеләр ике кешегә ун көнлек ялга уртача 92 мең сум акча түли икән. Ә сез бакча дисез…

Сан

2022 елда Россиядә яшәүче 3,5 миллион кеше чит илдә ял иткән. Чагыштыру өчен: пандемиягә кадәрге 2018 елда әлеге сан 12 миллионны тәшкил иткән.

ЧЕБЕШЛӘРНЕ КҮМГӘЧ САНЫЙЛАР

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Автор фотосы

Авыру чебиләр алып кайтып, акчаны гына түгел, халыкның ышанычын да югалттык, ди кош сатучы эшмәкәрләр.

«Мондый хәл күргән юк иде»

Бер айлык чебиләрне халыкка алып кайтып сатучы эшмәкәрләр белән без Тукай районындагы фермер хуҗалыгы янында очраштык. Җитәкчесе Илфат Хәснуллин белән күрешеп, нинди дә булса җылы сүз ишетергә өмет итеп, республиканың төрле районнарыннан (Әлмәт, Алабуга, Әгерҗе, Тукай, Арча, Кукмара, Сарман, Әтнә, Балтач, Мөслим, Ютазы, Балык Бистәсе) һәм Казаннан 30га якын алыпсатар җыелган иде ул көнне. Ләкин, аларның сүзләре буенча, зыян күрүчеләр тагын да күбрәк. Фермер хуҗалыгыннан бройлерларны Башкортстанның Туймазы шәһәреннән дә, Мари Элдан да килеп алып киткәннәр.

Алыпсатарларның сүзләре буенча, алар якынча 60 мең тирәсе кош-корт алып кайтып, 2–3 көн эчендә халыкка сатып бетергән. Бер чебине 280 сумнан сатып алганнар дип исәпләсәк, якынча 17 млн сумга якын товар сатылган диген сүз. Кемдер – 140 меңләк, кемдер – 200 меңләк, кайсыдыр 500 мең сумлык чеби алып кайткан.

Әйтик, Чаллыдан Зөлфия Солтанова 17 май көнне 630 баш чеби сатып алган. Аларны шул ук көнне сатып та бетергән. Икенче көнне кешеләр бер-бер артлы кошларның авырулары, үлүләре турында шалтыратып әйтә башлаган.

– 18 май көнне Илфатның урынбасары Айрат кайбер кешеләргә: «Кошлар авырып тора, без аларны дәвалыйбыз», – дип әйткән булган. Аның шулай икәнен белгән булсак, алмыйча да киткән булыр идек. Сатканнан соң кешеләр бер-бер артлы, чебиләр авырый, үлә, дип шалтырата башлады. Авырганнарына антибиотик бирергә куштык, тик аның файдасы булмады. Гомумән, берни белән дә дәвалап булмый. Кошлар күпләп үлә. Без кошчылык тармагында күптән эшлибез, ләкин моңа кадәр мондый хәл күргәнебез юк иде. Безгә халык каршында оят, чөнки алар белән һәрвакыт элемтәдә. Озак еллар эшлибез, – диде Зөлфия Солтанова.

Кошларның барысында да бер үк төрле авыру билгеләре күзәтелә: гыжлый, башлары шешә, тән температуралары күтәрелә, зәңгәрләнә һәм борыннарыннан сыекча ага.

Зыян күрүчеләр арасында Тукай районыннан Рәсмия Шәмсемөхәммәтова да бар иде. Ул халыкка акчаны үз кесәсеннән түләвен әйтте.

– Мин бройлерларны Әлмәт районы авылларында саттым. 16 май кичендә 140 мең сум түләп, 500 чеби алып кайттык, икенче көнне берничәсенең башы шешүен күрдем. Шунда ук башка алыпсатарларны: «Алардан алмагыз, чебиләр авырый», – дип кисәттем. Авыруларын читкә алып куйдым да яхшыларын халыкка сатарга чыгып киттем. Ләкин 2–3 сәгатьтән күбесенең башлары шешеп чыкты, үзләре гыжлый иде. Икенче көнгә беренче сатып алучым: «Биш чебинең башы шеште», – дип шалтыратты. Шуннан соң чебине саткан бөтен кешегә шалтыратып, кошларның хәлләрен белештем, аннан соң барысын да йөреп чыктым. Чебиләр авырый иде. Бик авыр хәлдә булганнарын чалдырып, акчаларын кире кайтардым. Әле дә булса үлгән чебиләр өчен акча күчереп торам. Авырганнарын дәвалар өчен антибиотикларга кадәр алып бирдем. Үземдә авырып калган бройлерларны дәвалап карадым, ләкин терелеп китә торган түгел алар. 30 ел эшләп, мондый хәл күргән юк иде. Күпме халык зыян күрде?! Пенсия акчасын җыеп чеби алган әбиләрнең кайсы елый, кайсы безгә рәнҗи. Безгә ни эшләргә хәзер? – ди ул.

Казаннан килгән алыпсатар Венера апа да күз яшьләренә буыла-буыла сөйли:

> *– Кешеләрнең йөзләренә карарга оят бит. Алар миңа көнгә әллә ничә тапкыр шалтырата. 20 көн дәвамында шушы хәл бездә. Мин калтырап тора торганга әйләндем инде. Халыкка 500 мең сум бурычым бар. 12 мең сум пенсиям белән ничек түлим мин аны? Түләмичә дә булмый, чөнки намус дигән әйбер дә бар бит.*

Алыпсатарлар арасында беренче кат алып киткән чебиләрне сатып бетереп, икенче партия артыннан килүчеләр дә бар. Әйтик, Арчадан Рүзәл беренче тапкыр барганда 1600 чеби алып кайткан.

– Аларны 1,5 тәүлек эчендә сатып бетердем дә кабат килдем. Минем белән тагын ике егет бар иде. Чаллыны чыкканчы ук чебиләрнең авыруларына игътибар иттек тә барыбыз да кире борылдык. Кошларны кабул итеп алдылар. Аларны бушатып, юлга кузгалгач ук беренче партиядәге чебиләрне алучылар шалтырата да башлады, – диде Рүзәл.

Күпчелек алыпсатарлар, халык алдында абруебызны югалттык, дип борчыла.

– Без озак еллар чеби сату белән шөгыльләнәбез. Үзебезнең клиентларыбыз бар. Алар өметләнеп көтеп алалар, ветеринария документлары бармы, дип сорыйлар. Халыкның ничә еллар дәвамында яуланган ышанычын югалттык бит без, – диде Әгерҗе районыннан килгән алыпсатар.

Авыру тавыкларга да күчә

Эшмәкәрләр керемсез калса, гади халык акчасыз да, итсез дә, кайберләре хәтта йомыркасыз да калган булып чыкты. Чөнки әлеге авыруның чебиләрдән тавыкларга күчү очраклары да барлыгы билгеле булды. Әйтик, Кукмарадан Нурзия Хәбибуллинаның алыпсатар Илдар Шәнгәрәевтән алган 32 чебиенең барысы да үлгән. Җитмәсә, авыру хуҗалыктагы тавыкларга да күчкән. 21 тавыкның унбере үлде, диде ул безгә.

– Антибиотик бирүдән туктагач, чебиләр кабаттан үлә башлый. Аны 5 көннән артык бирергә ярамый бит. Гел дару тутырган чеби нинди була инде ул? – ди Илдар Шәнгәрәев.

Лаеш районының Зимняя Горка авылыннан Альмира Сәрварова да 33 чеби сатып алган булган.

– Түбән Камадан күченгәч, ел да чебиләр ала торган идек. Быел да бройлер алдык. Тик уңышсыз булды. Мондый хәлне күргәнебез юк иде. Моңа кадәр бер чебинең дә хәтта кыек басканы да булмады. Болары алып кайтканда ук сәламәт түгел, гыжлап тора иде. Сарайга ябып кергәч, ирем: «Чебиләргә әллә ни булды, зәңгәрләнә бит алар», – диде. Шуннан соң берсе артыннан икенчесе үлә башлады. Ветеринарны чакырттык. Ул антибиотик бирергә кушты. Ләкин аның файдасы булмады. 33 чеби алган идек, әлегә шуларның дүртесе генә исән. Аларын да тулысынча сәламәт дип әйтеп булмый. Ашамыйлар да, хәлсез генә утырып торалар, – диде ул.

«Сезнең өчен вакытым юк»

Халыктан бер-бер артлы күңелсез хәбәр килә торгач, берничә көннән соң алыпсатарлар хуҗалык җитәкчесе Илфат Хәснуллин янына килә. Аңлатма һәм акчаны кире кайтаруны таләп итеп. Ләкин ул гына аларны колач җәеп каршы алмый. Алданган кешеләр белән сөйләшергә теләмәвен белдерә һәм: «Бездә авыру чеби юк», – дигән сүз белән генә чикләнә.

Илфат Хәснуллинга без дә шалтыраттык. Телефонны алса да, ниндидер аңлатма бирүне кирәк дип тапмады. «Сезнең белән юристыбыз сөйләшер. Үземнең эшем күп, вакытым юк», – дип кенә чикләнде ул. Безнең: «Сез киләчәктә эшегезне ничек алып барырга уйлыйсыз? Нәрсәгә өметләнәсез? Бәлки, чыгып, уртак фикергә килергә кирәктер?» – дигән сүзләребездән соң сөйләшүне бөтенләй өзде.

Шактый көттереп булса да, хуҗалыкның юристы Юрий Клюшниковны да күрү бәхетенә ирештек. Ул хуҗалыкта үз ветеринарлары булмавын һәм соңгы партиядә 90 мең бройлер чыгарылып, сатылып бетүен әйтте. 90 меңе дә са-

Мөнәсәбәт

Бу хәлләргә аңлатма бирүне сорап, без Татарстанның Баш ветеринария идарәсе башлыгы урынбасары Габделхак МОТЫЙГУЛЛИНга мөрәҗәгать иттек.



– Бүген кош-корт арасында иң зур куркыныч тудыручы авыру – кош гриппы. Шуңа күрә без иң элек шушы авыру булу-булмауга тикшерәбез. Бу юлы да шуны эшләдек. Үлгән кошларда кош гриппы юк, – дип аңлатты ул. – Аларда колибактериоз авыруы булуы ачыкланды. Ул – эчәклекләрдә була торган инфекция, куркыныч авыру булып саналмый. Карантин кертелергә тиеш түгел. Ләкин бу авыру массакүләм үлемгә сәбәпче була ала. Вакытында дәваланмаса, барлык кошларның да үлеп бетүе бар. Кошлар авыруны хуҗалыкта эләктереп, машинада кайтканда, стресс кичереп, ягъни уңайлы шартлар булдырылып, авыру көчәйгән булырга мөмкин.

тылып беткәнме, әллә берничә меңе хуҗалыкта ук үлгәнме? Анысын инде тәгаен генә әйтү мөмкин булмас. Елына 300 меңгә якын кош-корт үстереп сатучы зур хуҗалыкның үз ветеринарлары булмавы да яхшы күрсәткеч түгел югыйсә.

– Без бер көнлек чебиләрне үстереп сатабыз. Хуҗалыкта барлык санитар нормалар саклана, – диде Юрий Клюшников. – Бу хәлләрдән соң безгә 13 эшмәкәр мөрәҗәгать итте. Аларның һәркайсына рәсми документлар бирелде. Без тиешле таләпләргә җавап биргән товар саттык һәм аны кире алырга, акчаны кайтарырга тиеш түгел. Ә инде суд була калса, аның карары буенча эш йөртәчәкбез.

Сәбәп нидә?

Урынга баргач, Тукай районының баш ветеринары Ленар Хәйбуллин, озак кына көттереп булса да, алыпсатарлар һәм безнең белән очрашуга килде.

– Без мондагы вазгыятьтән хәбәрдар, – диде ул. – Ләкин бу хәл ферма эчендә түгел, ә читтә булды. Чебиләр шәхси хуҗалыкларга таратылгач, күпләп үлә башлады. Бу хәлдән соң без хуҗалыкка килеп, пробалар алдык. Лабораторияләрдәге анализлар авырулар буенча чиста булуын күрсәтте. Чебиләр үлеменә юлдагы стресс, яктылык, машинадагы үтәли җил дә сәбәп була ала.

Республиканың төрле районнарына, төрле авылларына, төрле машиналарда һәм төрле шартларда таралган чебиләрнең барысында да бер үк вакытта бер үк төрле авыру чыгуның сәбәбе стресс булу бер дә ышандырмады, әлбәттә.

Алайса, сәбәп нәрсәдә? Бу сорауга һәркем җавап табарга тырыша. Эшмәкәрләр үлгән чебиләр буенча иң элек үз районнарындагы ветеринарларга мөрәҗәгать итә. Тикшерү нәтиҗәләре чебиләрдә кош гриппы булмавын күрсәтә. Моннан тыш, Арча районы алыпсатарлары үлгән кошларны үзләре Республика ветеринария лабораториясенә анализга алып барган. Гәрчә мондый хәлне һәр районның үз ветеринарлары катгый контрольдә тотарга тиеш булса да. Анализлар кошларда колибактериоз авыруы булуын ачыклый.

Ләкин безнең белән очрашуга килгәндә Ленар Хәйбуллин алыпсатарлар тапшырган анализларның нәтиҗәләрен белми иде әле. Анысын үзебезгә җиткерергә туры килде. Ләкин белгеч шуннан соң да үз фикерендә калды һәм колибактериоз стресс вакытында килеп чыга торган авыру булуын кабатлады.

Монда игътибар ителергә тиешле тагын бер мәсьәлә бар. Алыпсатарларның кулларында булган документларда бер айлык чебиләргә ике генә прививка ясалган дип язылган. Гәрчә дүрт вакцина булырга тиеш булса да. Ленар Хәйбуллин калган икесе хуҗалыкның эчке актларында гына күрсәтелүен әйтте. Кызганыч, анысын карау мөмкинлеге булмады.

Бу хәлләрдән соң Татарстанның Баш ветеринария идарәсе башлыгы урынбасары Габделхак Мотыйгуллин хуҗалыкта тикшерү үткәрергә вәгъдә бирде.

– Шулай да мин тикшерү нәтиҗәләре буенча ике як уртак фикергә килеп килешерләр һәм эш судка ук барып җитмәс дип өметләнәм, – диде ул.

Тик авыру кошлар ни өчен сатылган соң? Әлеге сорауга җавап булмады.

Язманы газетага тапшырганда, фермер белән алыпсатарлар уртак тел таба алмаганнар иде әле. Хәзер зыян күрүчеләр берләшеп, фермерны судка бирмәкче булалар. Эшмәкәрләрнең суга аккан акчалары белән бергә халык каршында какшаган абруйларын да кайтарасылары бар бит әле. Әлеге мәсьәләне без дә күзәтеп торачакбыз.

Зөһрә САДЫЙКОВА

23 июньдә сәгать 10нан 12гә кадәр сезнең белән элемтәдә журналист **Зөһрә САДЫЙКОВА** була. Сорауларыгызны, әйтер сүзләрегезне 222-09-75 номеры буенча җиткерергә мөмкин.

ХАЛЫК АВАЗЫ

Нигә өйгә китермиләр?

Авылда биш ел инде хат ташучы юк. Газеталарны почта бүлекчәсеннән алып кайтырга туры килә. Аягым авырткач, барып йөри алмыйм. Үзем 28 ел хат ташыдым. Шуннан бирле юньләп эшләүче юк. Газеталарны өйгә китерсеннәр иде.

Оркыя ЗАРИПОВА.
Алексеевск районы
Юеш Көрнәле авылы

Ирина Прохорова, «Россия почтасы» Идел макрорегионының тышкы коммуникацияләр буенча юнәлеш җитәкчесе:
– Юеш Көрнәле авылы почта бүлекчәсендә ике хезмәткәр – җитәкче һәм хат ташучы исәпләнә. Җитәкче атнага өч көн дәвамында бүлектә хезмәт күрсәтә, ә хат ташучы авыл халкына пенсия, пособие, басма матбугат тарата. Газеталар китерүдәге өзеклек хат ташучының чираттагы ялга китүенә бәйле булырга мөмкин. Сез җиткергән мәгълүматны без почтамт җитәкчесенә тапшырдык, ул вазгыятьне контрольгә алачак.

Ни өчен сүндерәләр?

Арча районының Наласа авылында кичке сәгать 8дән соң баганадагы утларны сүндерәләр. Төнгә кап-караңгы була. Авыл җирлеге, лимит 204 мең сум, ди. Баксаң, кыш көне 180 мең сумлык ут янган икән. Ул лимитны кем билгели? Ни өчен утка тилмерәбез?

Наласа авылы халкы

Илфира Шакирова,
Наласа авыл җирлеге башлыгы:
– Бу бездән генә тормый. Район хакимияте ел саен һәр җирлеккә җирлекләрдәге багана утларын сүндерергә куша. Бу акчаны экономияләү, бюджетка салынган акча ел ахырына җитсен өчен эшләнә. Ни өчен дигәндә, утка бик күп түлибез. Лимиты халык санынннан чыгып, районның финанс бүлеге бүлеп бирә. Әйтик, безгә ут өчен елга 260 мең сум каралган.

20 августтан апрель ахырына кадәр утлар автомат рәвештә караңгы төшкәч яна һәм яктыргач сүнә. Җәен исә бөтенләй сүндерәбез. Әмма урам башы, тыкрыклардагы баганаларда, ягъни 12 урындагы дежур утларга тимибез.

Наласа халкына зарланырга урын юк. Мин эшкә килгәндә, черек баганаларда ун лампочка бар һәм бу халыкка җитә иде. Шушы вакыт эчендә Наласада 155 багана һәм 100 лампочка куйдырдым. Әгәр кирәк булса, ишегалдыннан ут сузып, җәйге сезонда прожектор куярга мөмкин. Болай эшләүчеләр күп. Безнең өйдә дә бар ул. Айга 332 сум акча түлибез. Бу – 100 сумга артыграк дигән сүз.

Фикер

Закон кирәк

Фатирда өлеше (доля) булганнар өчен яңа закон чыгарсыннар иде. Әйтик, 3 яки 5 ел дәвамында фатирга бер тапкыр да килеп карамаучыларны исәптән төшерсеннәр. Оныгымны 13 ел күргән юк инде. Мине тәрбияләүче бар анысы. Тик мин үлгәч, оныгым фатир бүлешеп йөрмәсме? Минем кебек хәлдә калган ялгыз әби-бабайлар күп бит. Әгәр закон чыкса, оныкларга акыл керер, болай югалмаслар иде.

ЕКАТЕРИНА әби. Казан

Илдар Мөхәммәтҗанов

Сара Садыйковага һәйкәл кайчан булыр?

Татар милләтенең йөзек кашы булган композитор Сара Садыйковага башкалада әлегә кадәр һәйкәл куелганы юк. Ул кайчан куелыр икән?

Сәгъдулла ШӘЙХУЛЛА. Казан

Татарстан Мәдәният министрлыгының матбугат үзәге:
– Сара Садыйковага һәйкәлнең урыны билгеле. Ул Татарстан һәм Тукай урамнары киселешендәге скверда урнашачак. Бу урын аның кызы һәм элеккеге скульптор – нәсел дәвамчылары Рада Нигъмәтуллинага да күрсәтелде. Андагы манзараны боза торган кечкенә кибетләр (ларек) алынды. Татарстан урамыннан бу урын яхшы күренәчәк. Хәзерге вакытта Казан башкарма комитеты белән сквер проекты әзерләнә. Бу – һәйкәл генә түгел. Аның янында матур мохит булдыру да күздә тотыла. Кыскасы, ике эш бергә алып барыла. Рада Нигъмәтуллина проекты нигезендә Мәскәүдән яшь татар архитекторы, скульптор Рим Акчурин һәйкәлнең проектын булдырды. Ул Мәдәният министрлыгы комиссиясендә каралды һәм хупланды. Бүген финанс чыганакларын эзләү эше дәвам итә.

Башында ник эшләпә?

Казан метросының Г. Тукай станциясендә татар гаиләсе сурәтләнгән. Хатын-кыз, ир-ат һәм 6–7 яшьлек бала. Барысы да – милли киемнән. Ир кешенең башында – Европа стилендәге эшләпә. Ул баш киеме татарныкы түгел бит. Үтенечем бар: аны үзгәртсеннәр иде.

Расих ҖӘЛӘЛ. Казан

«Метроэлектротранс» муниципаль унитар предприятиесе:
– Казанда метрополитенның беренче линиясе 2005 елда эшли башлады. Барлык станцияләр расланган проект нигезендә төзелде. Бу урында архитектура һәм дизайн шулай килештерелгән.

Оныклар бүлешә аламы?

Улым үлде, аның ике хатыннан ике баласы калды. Беренчесендә – улы, икенчесендә кызы бар. Мин фатирны бүләк итеп оныгым Маратка яздырдым. Оныкларның берсе дә фатирда пропискада тормады. Әгәр мин үлсәм, алар фатир бүлешә аламы?

Гөләндәм әби ВӘҖИЕВА. Казан

Булат Закиров, юрист:
– РФ ГК 209 маддәсе нигезендә милекче милкенә үзе хуҗа. Законга каршы килмәгән очракта, ул аның белән теләсә нәрсә эшли ала. Әби фатирны оныгына бүләк иткән һәм андый килешү Росреестрда тиешенчә рәсмиләштерелгән очракта, әбинең башка варислары әлеге фатирга дәгъва кыла алмаячак. Ни өчен дигәндә, хәзер йорт әбинең милке түгел инде. Бүләк итү килешүенә суд аша гына дәгъва белдерергә мөмкин.

Җавапларны Сәрия МИФТАХОВА әзерләде

Кайтаваз

«КӨН-ТӨН УКУ ӘҖЕРЕ» ЯЗМАСЫНА КАЙТАВАЗЛАР

Бөтенесе БДИны ямандый. Имтиханга тел-теш тидермәгез! Тырышкан кеше һәрвакыт теләгенә ирешә. Афәрин.

Рәзинә Сәгыйдуллина

* * *

Молодец, балакаем. Алдагы көннәрдә «Шәп табиб» дигән мактауны да ишетергә язсын!

Рәйсә ГАЛИЕВА

«70ТӘ – ҖИТМЕШЕНЧЕ ҺӨНӘР» ЯЗМАСЫНА КАЙТАВАЗЛАР

Пенсия яшендәге кешегә хөрмәт белән карарга кирәк. Бу яшьтә укырлык теләге, акылы бар икән, маладис. Укырга да, эшләргә дә теләмичә, трай тибеп йөргәннәргә кирәк ул МРТ.

Хәнифә ПАСМУРОВА

* * *

Дәрес эшли. Баш мие эш белән мәшгуль булса, Альцгеймер чире ерактарак йөрер.

Рамилә ГАФУРОВА

* * *

Тырыша инде Илфат. Гыйлем эстәү – файдага.

Дамира МИНҺАҖЕВА

19 июнь | Дүшәмбе

ВГТРК ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара» 16+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
09.00, 17.00 «ЯЛАНАЯКЛЫ КЫЗ». Телесериал 16+
10.00, 23.30 «ШИРОКА РЕКА». Телесериал (Россия) 16+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
11.30, 21.00 «Заман көзгесе» 6+
12.00, 22.40 «СЕБЕР КИЯВЕ». Телесериал (на татарском языке) 16+
13.00 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 16+
14.00 «Закон. Парламент. Общество» 16+
14.45 «Музыкаль мәйдан» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә». «Акыл батл» 0+
16.00 «Переведи!» (учим татарский язык) 6+
16.30 «Гаилә учагы» 12+
18.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 16+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Күчтәнәч» 0+
22.10 «Реальная экономика» 16+
00.20 «Соотечественники». Резеда Ахиярова. Музыка звезды 16+
00.45 «Каравай» 6+
01.10 «Таяну ноктасы» 16+
01.35 «Татар халык җырлары» 0+
02.05 «Манзара» 16+
03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
03.55 «Аулак өй» 6+
04.45 «Җырлыйк әле!» 12+
05.35 «Оныта алмыйм...» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара» 16+
08.00 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.40, 18.20, 23.10, 04.15 «Башваткыч» 12+
09.50 «Семь дней» 16+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30 «Туган җир» 12+
12.05 «Йөрәктән – йөрәккә». Татарстанның халык артисты Илдус Әхмәтҗанов турында телеочерк 16+
15.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
16.30 «Адымнар» 16+
17.00 «Музыкаль мәйдан» 16+
17.30 «Яшьләр тукталышы» 6+
19.10, 22.20, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
19.30 «Калеб» 6+
20.00 «Заман көзгесе» 6+
20.30 «Таяну ноктасы» 16+
21.25 «Әниемнең җылы кочагы» 16+
00.15 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
00.40 «Калеб» 6+
02.45 «Караоке татарча» 12+
03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 16+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
09.55 «Жить здорово!» 16+
10.50 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
16.00 «Мужское/Женское» 16+
16.50 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
19.50 «Куклы наследника Тутти» 16+
21.00 «Время»
22.00 Юлия Снигирь в исторической драме «ВЕЛИКАЯ» (S) 12+
23.00 «Большая игра» 16+
00.00 ПОДКАСТ.ЛАБ «АстроУмные» 16+
00.40 ПОДКАСТ.ЛАБ «Пусть не говорят, пусть читают» 16+
01.20 ПОДКАСТ.ЛАБ «Триггеры» 16+
02.00 ПОДКАСТ.ЛАБ «Креативные индустрии» 16+
02.40 ПОДКАСТ.ЛАБ «20 лет спустя» 16+
03.00 Новости
03.05 ПОДКАСТ.ЛАБ «20 лет спустя» 16+
03.20 ПОДКАСТ.ЛАБ «Обязательно к прочтению» 16+
04.00 ПОДКАСТ.ЛАБ «Все хотят летать» 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
16.30 Премьера. «Малахов» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Премьера. «ОПЕРАЦИЯ «ПРЕСТОЛ» 12+
23.10 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.00 Михаил Пореченков, Вера Панфилова, Александр Горбатов, Егор Корешков. «ОСТАТЬСЯ В ЖИВЫХ» 12+
03.55 Ярослав Бойко, Анатолий Васильев, Раиса Рязанова, Дарья Повереннова. «СЕМЕЙНЫЙ ДЕТЕКТИВ» 16+

МАТЧ ТВ

06.00, 14.25, 23.35 «Легендарные клубы» 12+
06.30 «Здоровый образ. Фигурное катание» 12+
07.00, 10.00, 12.55, 14.55, 17.00, 22.30 Новости
07.05, 20.30, 22.35 Все на Матч! Прямой эфир
10.05, 12.35, 00.35 Специальный репортаж 12+
10.25 Спортивный дайджест 0+
11.25 Смешанные единоборства. UFC. Даниэль Кормье против Стипе Миочича. Трансляция из США 16+
13.00 «Есть тема!» Прямой эфир
15.00 «География спорта. Волгоград» 12+
15.30 Еврофутбол 2022-2023. Лучшие голы сезона 0+
17.05 «Громко». Прямой эфир
18.30 Профессиональный бокс. Olimpbet кубок на Волге. Артём Сусленков против Рейнальдо Чарона. Прямая трансляция из Самары
21.00 Бильярд. «BetBoom Кубок Чемпионов». Прямая трансляция из Москвы
00.55 Баскетбол. Чемпионат Европы. Женщины. 1/8 финала. Трансляция из Израиля 0+
02.50 Новости 0+
02.55 Дартс. Профессиональная лига. Турнир «Красная площадь». Трансляция из Москвы 0+
05.00 Академическая гребля. Кубок мира. Трансляция из Италии 0+

НТВ

04.55 Детективный сериал «МОСКВА. ЦЕНТРАЛЬНЫЙ ОКРУГ» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 14.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25, 10.35 Сериал «ЛЕСНИК» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.50 «За гранью» 16+
17.55 «ДНК» 16+
20.00 «ЭФФЕКТ ДОМИНО» (S) 16+
22.15, 00.00 Остросюжетный сериал «РЕАЛИЗАЦИЯ» (S) 16+
00.45 «ЗОЛОТОЙ ТРАНЗИТ» (S) 16+
02.45 Сериал «МЕЧ» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.00 «Давай разведёмся!» 16+
09.00 «Тест на отцовство» 16+
11.15 «Понять. Простить» 16+
12.30 «Порча». «Бедная вдова» 16+
13.00 «Знахарка» 16+
13.35 «Верну любимого» 16+
14.05 «Голоса ушедших душ» 16+
14.35 «ЛЮБОВЬ ПО КОНТРАКТУ» 16+
19.00 «ТОЛЬКО ПО ЛЮБВИ» 16+
23.20 «Понять. Простить» 16+
00.30 «Порча» 16+
01.00 «Знахарка» 16+
01.35 «Верну любимого» 16+
02.00 «Голоса ушедших душ» 16+
02.25 «Тест на отцовство» 16+
04.05 «Давай разведёмся!» 16+
04.55 «Знать будущее. Жизнь после Ванги» 16+
05.45 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

05.30 «КАЛАЧИ» 12+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 17.00, 19.00 Новости дня 16+
09.15, 21.00 «Открытый эфир» 16+
11.00, 01.15 «ВОЗВРАЩЕНИЕ РЕЗИДЕНТА». 1-я серия 12+
12.35, 13.25, 15.05 «ЗАСТАВА ЖИЛИНА». Телесериал. 1-я – 4-я серии 16+
15.00 Военные новости 16+
17.15 «Освобождая Родину». Док. сериал. «Битва за Север. Провал «Серебристой лисы». 1-я серия 16+
18.00 «Освобождая Родину». Док. сериал. «Битва за Север. Провал «Серебристой лисы». 2-я серия 16+
18.50 «Специальный репортаж» 16+
19.55 «По горячим следам» 16+
20.10 «Загадки века». Док. сериал. «Предатель с фотокамерой» 12+
22.45 «Между тем» с Наталией Метлиной. 12+
23.15 «МИНУТА МОЛЧАНИЯ» 12+
02.25 «СВЕТЛЫЙ ПУТЬ» 12+
04.05 «ЗАСТАВА ЖИЛИНА». 1-я и 2-я серии 16+

20 июнь | Сишәмбе

ВГТРК ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 16+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
09.00, 17.00 «ЯЛАНАЯКЛЫ КЫЗ». Телесериал 16+
10.00, 23.00 «ШИРОКА РЕКА». Телесериал (Россия) 16+
11.00 «Фолиант в столетнем переплёте» 16+
11.15 «Память сердца» 16+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «СЕБЕР КИЯВЕ». Телесериал (на татарском языке) 16+
13.00 «Туган җир» 12+
13.30 «Юлчы» 16+
14.00 «Путь» 16+
14.15 «Не от мира сего...» 16+
14.30 Новости Татарстана 16+
14.45 «Музыкаль мәйдан» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Төймә» 0+
16.00 «Ватандашлар» 16+
18.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 16+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Күчтәнәч» 0+
21.00 «Ватандашлар» 16+
00.00 «Видеоспорт» 16+
00.25 «Каравай». Культура народов Поволжья 6+
00.50 «Соотечественники». Мажит Гафури. «Я – сын татарского народа...» 16+
01.15 «Башваткыч» 12+
02.05 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 16+
03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
03.55 «Аулак өй» 6+
04.45 «Вечерняя игра» 16+
05.35 «Оныта алмыйм...» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара» 16+
08.00 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.40, 18.20, 23.10, 04.15 «Җырлыйк әле!» 12+
09.40 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
10.30 «Заман көзгесе» 6+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30 «Нәсыйхәт» 16+
12.05, 21.25 «Ком сәгате» 16+
15.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
16.30, 20.30 «Таяну ноктасы» 16+
17.00 «Музыкаль мәйдан» 16+
17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
19.10, 22.20, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
20.00 «Халкым минем» 12+
00.15 «Тамчы-шоу» 6+
02.45 «Караоке татарча» 12+
03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 16+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
09.55 «Жить здорово!» 16+
10.50 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
16.00 «Мужское/Женское» 16+
16.50 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
19.50 «Куклы наследника Тутти» 16+
21.00 «Время»
22.00 «ВЕЛИКАЯ». Многосерийный фильм (S) 12+
23.00 «Большая игра» 16+
00.00 ПОДКАСТ.ЛАБ «Психика» 16+
00.40 ПОДКАСТ.ЛАБ «Легкие деньги» 16+
01.20 ПОДКАСТ.ЛАБ «Космические истории» 16+
02.00 ПОДКАСТ.ЛАБ «Произвольная программа» 16+
02.40 ПОДКАСТ.ЛАБ «Антропология» 16+
03.00 Новости
03.05 ПОДКАСТ.ЛАБ «Антропология» 16+
03.20 ПОДКАСТ.ЛАБ «20 лет спустя» 16+
04.00 ПОДКАСТ.ЛАБ «Триггеры» 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
16.30 Премьера. «Малахов» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Премьера. Павел Трубинер, Татьяна Арнтгольц, Михаил Горевой, Александр Макогон, Екатерина Волкова, Мария Малиновская. «ОПЕРАЦИЯ «ПРЕСТОЛ» 12+
23.10 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.00 Михаил Пореченков, Вера Панфилова, Александр Горбатов, Егор Корешков. «ОСТАТЬСЯ В ЖИВЫХ» 12+
03.55 Ярослав Бойко. «СЕМЕЙНЫЙ ДЕТЕКТИВ» 16+

МАТЧ ТВ

06.00, 23.35 «Легендарные клубы» 12+
06.30 «Магия большого спорта» 12+
07.00, 10.00, 12.40, 14.55, 17.55, 22.30 Новости
07.05, 15.00, 20.20, 22.35 Все на Матч! Прямой эфир
10.05, 12.20, 00.35 Специальный репортаж 12+
10.25 «Футбол на все времена» 12+
11.25 Смешанные единоборства. UFC. Конор Макгрегор 16+
12.45, 15.45 Футбол. BetBoom МКС 2023. Прямая трансляция
18.00 «Любовь под грифом «Секретно». Док. фильм 12+
19.10 Профессиональный бокс. Тим Цзю против Карлоса Окампо. Трансляция из Австралии 16+
21.00 Бильярд. «BetBoom Кубок Чемпионов». Прямая трансляция из Москвы
00.55 Баскетбол. Чемпионат Европы. Женщины. 1/8 финала. Трансляция из Словении 0+
02.50 Новости 0+
02.55 Дартс. Профессиональная лига. Турнир «Красная площадь». Трансляция из Москвы 0+

НТВ

05.00 Детективный сериал «МОСКВА. ЦЕНТРАЛЬНЫЙ ОКРУГ» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25, 10.35 Сериал «ЛЕСНИК» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.50 «За гранью» 16+
17.55 «ДНК» 16+
20.00 Премьера. Детективный сериал «ЭФФЕКТ ДОМИНО» (S) 16+
22.15, 00.00 Остросюжетный сериал «РЕАЛИЗАЦИЯ» (S) 16+
00.50 «Основано на реальных событиях». «Подвиг разведчика» 16+
02.35 Сериал «МЕЧ» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.00 «Давай разведёмся!» 16+
09.00 «Тест на отцовство» 16+
11.15 «Понять. Простить» 16+
12.30 «Порча». «Нити судьбы» 16+
13.00 «Знахарка» 16+
13.35 «Верну любимого» 16+
14.10 «Голоса ушедших душ» 16+
14.45 «ПСИХОЛОГИЯ ЛЮБВИ» 16+
19.00 «ХОЧУ ТЕБЕ ВЕРИТЬ» 16+
23.20 «Понять. Простить» 16+
00.30 «Порча» 16+
01.00 «Знахарка» 16+
01.35 «Верну любимого» 16+
02.00 «Голоса ушедших душ» 16+
02.25 «Тест на отцовство» 16+
04.05 «Давай разведёмся!» 16+
04.55 «Знать будущее. Жизнь после Ванги» 16+
05.45 «6 кадров» 16+
05.50 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

05.30 «ЗАСТАВА ЖИЛИНА». Телесериал. 3-я и 4-я серии 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 17.00, 19.00 Новости дня 16+
09.15, 21.00 «Открытый эфир». Ток-шоу 16+
11.00, 01.10 «ВОЗВРАЩЕНИЕ РЕЗИДЕНТА». 2-я серия 12+
12.35, 13.25, 15.05 «ЗАСТАВА ЖИЛИНА». Телесериал. 5-я – 8-я серии 16+
15.00 Военные новости 16+
17.15 «Освобождая Родину». Док. сериал. «Битва за Крым. Крах Готенланда». 1-я серия 16+
18.00 «Освобождая Родину». Док. сериал. «Битва за Крым. Крах Готенланда». 2-я серия 16+
18.50 «Специальный репортаж» 16+
19.55 «По горячим следам». Премьера! 16+
20.10 «Улика из прошлого» 16+
22.45 «Между тем» с Наталией Метлиной 12+
23.15 «ЭТО БЫЛО В РАЗВЕДКЕ» 12+
02.15 «МИНУТА МОЛЧАНИЯ» 12+
04.05 «ЗАСТАВА ЖИЛИНА». Телесериал. 5-я и 6-я серии 16+

Белдерү

ИЗВЕЩЕНИЕ О ПРОВЕДЕНИИ СОБРАНИЯ ПО СОГЛАСОВАНИЮ МЕСТОПОЛОЖЕНИЯ ГРАНИЦЫ ЗЕМЕЛЬНОГО УЧАСТКА

Кадастровым инженером Дерябиной Марией Владимировной (420124, РФ, Республика Татарстан, г. Казань, ул. Меридианная, д. 10, офис 5, mrczeo@mail.ru, +7-987-215-01-46, выполняются кадастровые работы по уточнению земельных участков с кадастровыми номерами 16:20:010401:130, расположенный по адресу: РФ, Республика Татарстан, Зеленодольский район, пгт Васильево, СНТ «Здоровье», №130 и 16:20:010401:61, расположенный по адресу: РФ, Республика Татарстан, Зеленодольский район, пгт Васильево, СНТ «Здоровье», №61.

Заказчиками кадастровых работ являются Халитова Светлана Петровна (РТ, г. Казань, ул. Ю. Фучика, д. 72, кв. 251, тел.: +79270400223) и Кириллова Наталья Николаевна (РТ, г. Казань, ул. М. Гафури, д. 4, кв. 45, тел.: +79172824041).

Смежный земельный участок, с правообладателем которого требуется согласовать местоположение границ: 16:24:190101:120, расположенного по адресу: РФ, Республика Татарстан, Зеленодольский район, пгт Васильево, СНТ «Здоровье». Собрание заинтересованных лиц по поводу согласования местоположения границы состоится по адресу: 420124, РФ, Республика Татарстан, г. Казань, ул. Меридианная, д. 10, офис 5 16 июня 2023 г. в 11 часов 00 минут.

С проектом межевого плана земельного участка можно ознакомиться по адресу: 420124, РФ, Республика Татарстан, г. Казань, ул. Меридианная, д. 10, офис 5.

Требования о проведении согласования местоположения границ земельных участков на местности принимаются с 16 июня 2023 г. по 18 июля 2023 г. Обоснованные возражения о местоположении границ земельных участков после ознакомления с проектом межевого плана принимаются с 16 июня 2023 г. по 18 июля 2023 г. по адресу: 420124, РФ, Республика Татарстан, г. Казань, ул. Меридианная, д. 10, офис 5.

При проведении согласования местоположения границ при себе необходимо иметь документ, удостоверяющий личность, документы о правах на земельный участок (часть 12 статьи 39, часть 2 статьи 40 Федерального закона от 24.07.2007 г. № 221-ФЗ «О кадастровой деятельности».

ТАТЭНЕРГОСБЫТ

АО «Татэнергосбыт» уведомляет, что в соответствии со Стандартами раскрытия информации субъектами оптового и розничных рынков электрической энергии, утвержденными постановлением Правительства РФ от 21.01.2004 N 24, на официальном сайте АО «Татэнергосбыт» tatenergosbyt.ru размещена информация о ценах и объемах электрической энергии каждого свободного договора купли-продажи электрической энергии, зарегистрированного гарантирующим поставщиком на оптовом рынке в отношении его зоны деятельности, а также величина корректировки составляющей предельного уровня нерегулируемых цен при учете свободного договора купли-продажи электрической энергии, определяемая коммерческим оператором оптового рынка в соответствии с договором о присоединении к торговой системе оптового рынка.

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

«Татагрохим» ачык акционерлык җәмгыяте коллективы, әтисе

Рәшит Нотфулла улының

кинәт вафат булуы сәбәпле, Балтач районы хакимияте башлыгы Нотфуллин Рамил Рәшит улының авыр кайгысын уртаклаша.

Республика керәшен җәмәгатьчелеге, керәшен этномәдәни хәрәкәте ветераны

ФОКИН Аркадий Васильевич

вафат булу сәбәпле, якыннарының, туганнарының кайгысын уртаклаша.

Республика керәшен Иҗтимагый оешмасы идарәсе

РЕКЛАМА БҮЛЕГЕ
(843) 222-09-65, 222-09-70.
E-mail: vtreklama@mail.ru

ТИРНЕҢ ИСЕ ЮК?!

Җир йөзендә яшәүчеләрнең 15 проценты чамадан тыш тирләүдән интегә. Рәсми саннар шул хакта сөйли. Беренче карашка гадәти күренеш кебек тоелса да, тир бик күп кенә җитди чирләр турында да кисәтергә мөмкин, ди белгечләр. Тир турында без тагын нәрсәләр белеп торырга тиеш? Чамадан тыш тирләмәс өчен, нинди кагыйдәләрне истә тотарга кирәк?

Республика клиник хастаханәсе табиб-терапевты, спорт табибы Анастасия ЯКОВЛЕВАның бу уңайдан фикерләрен белештек.

➤Кешенең бөтен тәне буйлап тир бизләре урнашкан. Шушы бизләр гади телдә тир дип йөртелгән секрет бүлеп чыгара. Тирнең төп бурычы – тәннең температурасын контрольдә тоту. Шуңа күрә тирләгәндә организмыбыз суына. Тир белән бергә организмдагы токсиннар да бүленеп чыга. Моннан тыш тир бүленеп чыгу аркасында тән тиресенең торышы да яхшыра.

➤Олыгайган саен кеше азрак тирли. Кешенең бармак эзләре бер-берсенә охшамаган кебек, тир исе дә аерыла. Хатын-кызларда тир бизләре ир-атлар белән чагыштырганда күбрәк. Шуңа да карамастан ир-атлар икеләтә күбрәк тирли. Кайчак кеше зур стресс кичергәндә тирләп чыга. Галимнәр кешенең елына 1264 литр тир бүлеп чыгаруын исәпләп чыгарган. Исерткеч эчемлекләр кулланган кеше, гадәттә, ныграк тирли.

➤Гомернең бер чорыннан икенче чорына күчеш вакытында кеше ныграк тирли башлый. Ник дигәндә, организмның гормональ системасы тулысынча үзгәрә. Шуңа күрә үсмерләр, менопауза чорына аяк басарга җыенган яки климакс башланган хатын-кызлар моннан аеруча интегә. Чамадан тыш тирләү артык авырлыктан, яман шештән интеккән, калкансыман биз авырулары булган, шикәр чире, вегетатив кан тамырлары дистониясе диагнозы вакытында да еш борчый.

➤Инфекцияле авыру вакытында бик нык тирләү нормаль күренеш санала. Әмма коронавирус белән авырып терелгән кешеләр еш кына авырып терелгәннән соң да тирләүдән зарлана. Ул әлеге чир белән авырганнан соң бер ай, хәтта бер ел буе да дәвам итәргә мөмкин. Моның сәбәпләре әле дә ачыкланмаган. Бу авырган вакытта эчкән дарулар, эндокрин һәм үзәк нерв системасындагы хилафлыклар, психологик һәм эмоциональ тайпылышлар аркасында да булырга мөмкин.

➤Организмыбыздагы токсиннар ашкайнату-эчәк тракты, бәвел юлы аша да чыгарга мөмкин. Алар начар эшләсә, «тыгылган» булса, токсиннар тән тиресе аша тир рәвешендә бүленеп чыгачак. Кайбер дaруларны эчкән вакытта тир исе кисәк үзгәрергә мөмкин. Кайчак организмда кайбер ферментлар бүленеп чыкмый. Ниндидер бер продукт организмга эләккәч, шушы ферментлар ярдәмендә эшкәртелә алмый һәм ул үзеннән-үзе токсинга әверелә. Тән тиресе аша тир ярдәмендә бүленеп чыгып, шулай ук тир исен үзгәртә ала. Мисал өчен, сарымсак та тир исенә йогынты ясый.

Абау!

Тир турында 3 кызыклы факт

Тир иссез. Тир дигәндә күз алдына авыр ис килеп баса. Чынлыкта тир иссез, төссез була. Тән тиресендәге бактерияләр аркасында гына исле һәм төслегә әверелә ул.

Тирләп кенә ябыгып булмый. Тир су, тоз һәм аксымнан тора. Шуңа күрә су эчүгә тирләгәндә организмнан бүленеп чыккан су кабат әйләнеп кайтачак.

Сулагайларның ике култык астыннан ике төрле ис килә. Күптән түгел Бөекбритания галимнәре шундый ачыш ясаган. Әмма моның ни сәбәпле шулай килеп чыгуын алар әле дә булса ачыклап бетерә алмый икән.

ЧАМАДАН ТЫШ ТИРЛӘМӘС ӨЧЕН КИҢӘШЛӘР



✓Иң беренче чиратта шәхси гигиена кагыйдәләрен истән чыгармаска кирәк. Көненә ике тапкыр душ керү тирләүдән коткара. Имән кайрысы, шалфейлы су белән коену да яхшы.
✓Табигый тукымадан тегелгән киемнәргә өстенлек бирегез.
✓Тирләп интектергән урынны содалы су белән сөртсәң, нәтиҗәсе озак көттермәс.
✓Ачы, тозлы, баллы, кыздырылган, кайнар ризык ашаудан тыелып торсаң яхшырак. Салкын су эчү дә зыянга гына булачак. Тирдән котылу өчен фастфуд, газлы эчемлекләрдән дә баш тартырга туры киләчәк. Ачы борыч, сарымсак нерв системасын ярсытып, көчле тир бүленеп чыгуга китерә. Ит һәм балыкның да майсыз төрләрен генә ашау хәерле. Яшелчә, җиләк-җимеш тә читтә калмасын. Рациондагы продуктлар B, E витаминнарына, кальцийга бай булырга тиеш. Ник дигәндә, тирләгәндә организм, нигездә, нәкъ менә шушы файдалы элементларны югалта. Карабодай, кишер, кузаклылар, кычыткан да тирләүне киметә.

Ут янып тора җиләк

Бакча җиләге өлгергән чорга аяк бастык. С витаминына иң бай җимешләрнең берсе санала ул. Аның 100 граммында әлеге витаминның көнлек нормасы бар. Бу яктан ул бары тик карлыганнан гына калыша. Уртача зурлыктагы биш җиләктә бер әфлисундагы кадәр С витамины бар. Бөер һәм сидек юллары авырулары белән интегүчеләргә сезон буена бакча җиләге ашарга кирәк. Ник дигәндә, ул бәвел куу үзлегенә ия. Бөер авырулары вакытында бакча җиләгенең җимешләре генә түгел, тамыры да файдалы.

Бакча җиләге составында салицил кислотасы бар. Шуңа күрә ул ревматизм вакытында авыртуны баса. Азканлылык вакытында исә организмны тимер белән тәэмин итә ул.

Бакча җиләге үзе дә, аның яфраклары да матдәләр алмашын һәм кан басымын нормальләштерә, йокысызлыктан булыша, атеросклероз һәм гипертония кебек авыруларны булдырмаска ярдәм итә.

Эчәклекләр, сидек куыгы һәм бөерләр ялкынсынудан көн саен ике-өч стакан бакча җиләге чәе эчәргә киңәш ителә. Аны әзерләү өчен ике аш кашыгы киптерелгән җиләкне бер стакан кайнар суга салып төнәтергә кирәк.

Җиләкнең яфраклары исә подаградан (организмда матдәләр алмашыну бозылу аркасында барлыкка килә торган тире һәм буын авыртуы) булыша. Зур гына өем киптерелгән яки яңа өзелгән яфракларны ярты литр суда төнәтеп, өстен каплаган килеш 10 минут тирәсе ут өстендә кайнатып алырга. Ашар алдыннан 100 мл күләмендә эчәргә кирәк. Бу төнәтмәне суыткычта ике тәүлек буена сакларга мөмкин. Шушы ук эчемлек бөер авыруларыннан да файдалы.

Эчәклекләре белән кыенлыклар туган һәм эч сыекланудан бер аш кашыгы киптерелгән бакча җиләге яфрагын бер стакан суга салып, 30 минут төнәтергә, шуны бер утыруда эчеп бетерергә киңәш ителә.

Ангинаны һәм тамак ялкынсынуларын дәвалау өчен, термоска җиләкнең киптерелгән яфракларын һәм чәчәкләрен салып, өстенә бер стакан кайнар су өстәп, сәгать буе томалап торырга кирәк. Соңрак һәр ике-өч сәгать саен авызны, тамакны шушы төнәтмә белән чайкарга кирәк.

Шешенүләрдән һәм югары кан басымыннан җиләкнең киптерелгән яфракларын стаканга салып, чәй пешергән кебек пешереп эчү булыша. Тәм өчен бер кашык шикәр комы өстәсәгез дә була.

Киңәш-табыш

КАВЫКТАН КОТКАРА

Кавыктан котылу, чәчне куерту һәм ныгыту өчен, баш тиресенә көн саен алоэ согы сөртергә кирәк. Моны 2–3 ай дәвамында эшләргә кирәк. Алоэдан ясалган битлек тә бик файдалы. Моның өчен тигез микъдарда алынган бал, кастор мае, алоэ согын яхшылап болгатып, юеш чәчкә сылыйсы да бераздан соң шампунь белән юып төшерәсе. Цистит, геморрой, бавыр һәм үт куыгы авырулары булганда, йөклелек вакытында алоэ согы белән дәвалану тыела. Алоэ препаратларын озак вакыт кулланганда, организмнан минераль матдәләр, бигрәк тә калий күп чыгарыла, бу исә су-тоз алмашын боза.

ҮКЧӘ ЯРЫЛГАННАН

100 грамм сыер маена 60–70 грамм прополис кушып, 0,5 литрлы банкага саласыз да кайнап торган чәйнек өстендә болгата-болгата эретәсез. Ул тулысынча эреп бетми, җилем кебек булачак. Аннан соң шуны марля аша берәр крем савытына сөзегез, чөнки прополисның калганы тиз ката. Бик хуш исле мазь килеп чыга. Шушы мазьны төнгә каршы юылган, ярылган үкчәгә сөртегез дә полиэтилен пакет каплагыз яки оекбаш киегез. Өч көн дигәндә ярылган үкчәләрегез рәткә килер.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА әзерләде

ТИСКӘРЕ ЙОГЫНТЫСЫ БУЛЫРГА МӨМКИН. КУЛЛАНЫР АЛДЫННАН ТАБИБ БЕЛӘН КИҢӘШЕГЕЗ.

Валентина СЕМЕНОВА

БЕР ЙОТЫМ СУ

shutterstock.com

Эчәр суны инде күптән сатып алырга ияләштек. Шәһәр халкы – бер хәл, инде хәзер кайбер авылларда яшәүчеләр дә, чишмәбез бик нык известьле булу сәбәпле, бөерләргә ком утырудан куркабыз, дип, аны кибеттән сатып алуны хуп күрә. Ә инде су мәсьәләсенә җаен тагын да күбрәк игътибар ителә. Барыбызның да сыйфатлы, чиста су эчәсе килә бит! Шулай икән, кибетләрдәге су турында нәрсәне белеп торырга? Кайсына өстенлек бирергә?

Бу хакта «Татарстан Республикасында Гигиена һәм эпидемиология үзәге» оешмасының туклану гигиенасы, балалар һәм үсмерләр гигиенасы бүлеге мөдире Ренат МУСИНнан белештек.

Ике төрле була

Ренат Әсгать улы әйтүенчә, сыйфатына бәйле рәвештә, суга ике категория бирелә – беренче һәм югары категория.

Беренче категориядәгесе – тегү яки бу чыганактан алынып, әллә ни сыйфатлы булмаса да, сәламәтлеккә зыян салмый торган су. Әлбәттә, сууткәргечтәгесеннән яхшырак, ләкин югары категориягә дә «тартмый». Эшкәртелгәннән соң анда хлорлы продуктлар калырга мөмкин чөнки.

Югары категориядәгесе – химик, биологик матдәләр белән пычранмаган чыганактан алына торган сыйфатлы су. Табигый составы бай булмаган очракта, тиешле микроэлементлар өстәлергә мөмкин. Мондый суга аерым таләпләр куела. Югары категориядәге суны балаларга да кулланырга мөмкин. Аны җитештерүдә углерод диоксиды һәм көмеш кебек консервантлардан (алар балаларның ашказаны-эчәклөренә тискәре йогынты ясарга мөмкин) файдалану катгый тыела.

Табигый су

Моңа җирнең түбәнге катламнарыннан чыгарыла торган артезиан суы керә. Дистәләрчә еллар дәвамында табигый фильтрлар – ташлар арасыннан чистарынып чыга торган яңгыр һәм кар сулары бу. Шул рәвешле су чистарынып кына калмый, бәлки әле файдалы минераллар, макро- һәм микроэлементлар белән дә баетыла. Артезиан суының составы чыганакның нинди тирәнлектә ятуына бәйле. Ләкин су никадәр тирәнрәк ятса, шуның кадәр сыйфатлырак, дигән сүз түгел. Кайвакыт тирәндә ятучы катламнардан зарарлы матдәләр дә эләгергә мөмкин.

Ә инде чишмә суының кайдан чыкканын аңлатып торасы юк. Аны барыбыз да беләбез. Тик яңгырлар һәм язгы ташулар чишмә суының да сыйфатына начар тәэсир итәргә мөмкин. Шуңа күрә аңа гадәттә беренче категория генә бирелә.

Боз суы иң чиста, иң «җиңел» су булып санала. Бозлыкның эрүе нәтиҗәсендә барлыкка килгәнлектән, анда зарарлы катнашмалар һәм тозлар юк дәрәҗәсендә.

Чистарту ысуллары

Теләсә кайсы су шешәләргә тутырылганчы чистартыла. Суны зарарсызландыру өчен хлор кулланылмаска тиеш. Сыйфатлы булып, берничә күрсәткече генә нормадан азрак тайпылса, гап-гади фильтрлар аша үткәрелә. Чистартуның иң киң таралган ысулы – «обратный осмос». Махсус фильтрлар ярдәмендә суны барлык катнашмалардан чистарту дигән сүз бу. Ләкин бер кимчелеге бар: су зарарлы гына түгел, бәлки файдалы матдәләрдән дә арындырыла.

Чистартуның тагын бер ысулы – озонлаштыру. Аның ярдәмендә су микроорганизмнардан чистартыла, шул ук вакытта минераль составы үзгәрешсез кала. Озон шешәдәге микроорганизмнарның үрчүен дә булдырмый.

Суны саклау

Эчәр су гадәттә 19 литрлы шешәләргә тутырып сатыла. Шешәсе сыйфатлы материалдан эшләнсә, суга аннан зарарлы матдәләр бүленеп чыкмый. Белгеч әйтүенчә, суны +2...+20 градуста, караңгырак урында сакларга кирәк. Мондый шартлар үтәлсә, 6 айдан 2 елга кадәр бозылмыйча сакланырга мөмкин.

Суны сайлаганда, аның чыганагы һәм категориясенә игътибар итәргә кирәк, дип киңәш итә Ренат Мусин. Иң яхшысы – суны тутыру урыныннан чыгару урынына туры килүе. Ник дигәндә, ерактан ташыганда, сыйфатына зыян килергә мөмкин. Этикеткасында суның категориясе, чыганагы һәм химик составы күрсәтелергә тиеш.

Югарыда әйтелгәннәрнең һәммәсе шәһәр урамнарындагы киосклардан үзебезнең шешәләргә тутырып сатыла торган суга да кагыла. Бу очракта бигрәк тә шешәгә игътибарлы булырга кирәк. Бер үк шешәдән ярты елдан артыграк файдаланырга ярамый, юкса материалы әйләнә-тирә мохит йогынтысында зарарлы матдәләр бүлеп чыгара башларга мөмкин.

Белеп тор!

Яфрак коткара

▶Үкчә ярылганда, чөгендер яфрагын кулланырга мөмкин. Йоклар алдыннан, берничә яфракны кайнар су белән пешекләп, берсе өстенә икенчесен куярга да ярылган урынга урнаштырырга. Өстен полиэтилен белән ябып, киҗе-мамык оекбаш киеп йокларга.

▶Бал корты, шөпшә яки башка бөҗәк чакса, тән шешү, ялкынсыну яки кычытудан дәфнә яфрагы (лавровый лист) ярдәмендә котылырга була. Моның өчен яфракны бераз чәйнәп, бөҗәк чаккан урынга куярга һәм бинт белән бәйләргә кирәк. Болай эшләгәндә, тәннең кызаруы яки шешүе бик тиз юкка чыгачак.

Исеңдә тот!

➤Урманнан талпан ияртеп кайтудан шикләнсәгез, кием-салым чистарту өчен чыгарылган ябышкак роликны сумкагызга салырга онытмагыз. Урманнан чыгуга, кием өстеннән шуның белән «йөреп» чыгыгыз – бөҗәк шунда ябышып калачак.

➤Кроссовканы машинага салып юганда, аяк киеменә оекбаш кидертегез. Болай эшләгәндә, машина дөбердәмәячәк.

➤Яшелчә яки җиләк-җимешне угычтан уганда, чәнечкедән файдаланыгыз. Бу ысул бармак-тырнакларны угыч тешенә эләгеп җәрәхәтләнүдән саклаячак.

СУГАН ЧИСТАРТА

Шашлык яки башка ризык пешергәннән соң шампурны, гриль рәшәткәсен юу – бик мәшәкатьле, авыр эш. Нишләргә? Суынганчы, металлны башлы суган согы белән «эшкәртергә» кирәк. Моның өчен суганны икегә бүлеп, бер өлешен чәнечкегә кадыйбыз һәм кайнар тимер өстеннән «йөртеп» чыгабыз. Болай эшләгәндә, металлга ябышкан ризык калдыклары, корым йомшарачак һәм су белән җиңел генә юып төшереләчәк.

«КУНАК»НЫ НИЧЕК ОЗАТЫРГА?

Өйдә кырмыска, таракан кебек ише чакырылмаган кунаклар пәйда булса, шундук алардан арыну чарасын күрергә кирәк. Юкса бөтен өйне басып алачакларын көт тә тор!

«Химия» кулланмыйча гына болай эшләргә мөмкин. 100 мл күләмендәге савыт-саба юу сыекчасына берәр аш кашыгы бор кислотасы, шикәр пудрасы һәм глицерин салабыз. Болгатып, катнашманы плинтусларның буеннан-буена, тәрәзә рамнары һәм тәрәзә төпләре почмакларына, идәнгә – мебель һәм ванна астына, өстәл аяклары тирәсенә юка гына полоса ясап сылыйбыз. Бер атна буе шулай тотабыз. Бу вакыт эчендә кырмыска-тараканнарның эзе суыначак. Аннан соң катнашманы губка белән юып алабыз.

Казанда яшелчә белән бәрән ите кыздыру

МИХАИЛ КУЗНЕЦОВ РЕЦЕПТЫ

Кирәк булачак: сөяксез бәрән ите (башка төрле ит булса да ярый), 1 кг башлы суган, 1 кг татлы борыч, 1 баш сарымсак, 1 әче борыч, 1 стакан кызыл шәраб, 100 мл үсемлек мае, тәменчә тоз, төелгән борыч, зира, хмели-сунели.

Бәрән итен вак кисәкләргә турыйбыз. Суган һәм сарымсакны чистартып, ваграк итеп шакмаклап турыйбыз. Татлы борычны юып, орлыкларыннан чистартабыз һәм өлешләп турыйбыз. Учак ягып, казанның төбенә май салабыз. Бераз чыжылдый башлагач, суган салып, болгата-болгата, 2 минут кыздырабыз. Татлы борыч салып, тагын 2 минут кыздырып алабыз. Ит салып, болгата-болгата, алтынсу төскә кергәнче кыздырабыз. Тоз, борыч, тәмләткечләр өстибез. Казанны капкачы белән ябып, салмак кына утта 40 минут пешерәбез. Сарымсак, кызыл шәраб һәм әче борыч (турамыйча гына) өстибез. Барысын бергә болгатып, тагын 15–20 минут утта тотабыз. Әзер ризыкны табынга чи яшелчә белән куябыз.

АЛЛАҺКА ЯКЫНАЙТКАН КӨН

Корбан бәйрәме ел саен зөлхиҗҗә аеның 10 нчы көнендә билгеләп үтелә. Быел ул 28 июньгә туры килә. Мөселманнарның иң көтеп алган, изге бәйрәме бу. Корбан чалганда нинди кагыйдәләрне истә тотарга кирәк? Корбанлык малына нинди таләпләр куела?

Корбан чалуга кагылышлы сорауларыбызга «Казан нуры» мәчете имам-хатыйбы Алмаз хәзрәт МӨХЛИСОВ ачыклык кертте.

– Ислам динендә ике олы бәйрәм бар. Шуларның берсе – Корбан бәйрәме, икенчесе – Ураза гаете. Корбан дигән сүз гарәп теленнән "якынаю" дип тәрҗемә ителә. Аллаһы Тәгаләгә якынаю, аның безгә биргән санаусыз нигъмәтләренә шөкер йөзеннән корбан чалып, аңа якынаю көне бу. Аллаһы Тәгалә: Коръәни Кәримдә: «Корбанлыкларыгызның ите дә, каны да миңа ирешми. Миңа тәкъвалык (Аллаһы Тәгаләдән куркуыгыз, аның ризалыгы өчен эшләгән изге гамәлләрегез) ирешә», – ди.

Корбан чалу йоласы Адәм галәйһиссәлам, аның балалары яшәгән вакыттан ук билгеле. Ләкин аның төп вакыйгасы Ибраһим галәйһиссәлам яшәгән чорда булган. Ул, баласын корбан итеп чалырга кушып, төш күрә. Аны башкарырга карар кыла. Әмма Аллаһы Тәгаләгә кеше каны кирәкми. Ибраһимның улы Исмәгыйль урынына җәннәттән тәкә иңдерә һәм, шул вакыттан башлап, иманлы кешеләргә корбан чалу йоласы тиешле була. Кеше бу гамәлне эшләсә, Аллаһы каршында бик саваплы була. Шуңа күрә корбанлык сатып алырга акчасы булган (быел корбан нисабы күләме 36 мең сум тәшкил итә. – **Д.Г.**), акыллы, балигъ булган, ирекле кешегә корбан чалу вәҗеб санала. Хәдисләрдән аңлашылганча, Корбан гаетендә иң саваплы, изге эш ул – корбан чалу. Шул ук хәдистә: «Әгәр кеше мөмкинлеге була торып та корбан чалмаса, намаз укый торган урыныбызга якынлашмасын», – диелә. Корбанлыкның беренче каны таму белән Аллаһы Тәгалә аны чалдырган кешенең гөнаһларын гафу итә. Корбаннарыбыз җәннәткә керергә дә бер сәбәп булып тора.

:: Корбанга нинди хайваннар чалына ала?
– Корбанга сарык, тәкә, кәҗә, сыер, буйвол, дөя, ягъни ике тояклы булган хайваннар чалына ала. Сарык, кәҗә 1 яшьтән дә кечерәк булмаска тиеш. Әгәр сарык бик зур булса, хәтта алты айлык сарыкны да чалырга рөхсәт ителә. Чалыначак сыер, буйвол, үгезгә килгәндә, алар ким дигәндә ике яшьлек булырга тиеш. Дөянең биш яшьтән дә кечерәк булмаганын гына чалырга рөхсәт ителә. Сарык, кәҗә – бер кеше исеменнән, дөя, сыер кебек зур хайваннар җиде кеше исеменнән чалына.

:: Корбанлык сатып алганда сатулашырга ярыймы?
– Халыкта, корбанлык сатып алганда сатулашырга ярамый, дигән сүз йөри. Әмма шәригатьтә андый кагыйдә юк. Киресенчә, корбанлыкны сатып алганда сатулашырга кирәк. Ул да зикер кебек санала, аның өчен дә савап бирелә. Өстәвенә бәйрәм көннәрендә корбанлык бәяләре болай да күтәрелә. Шуңа күрә аны алганда курыкмыйча сатулашырга мөмкин.

:: Билгеле бер сәбәпләр аркасында кеше корбан чалу урынында була алмаса, аның исеменнән корбанны башка кеше чалдыра аламы?
– Әгәр кеше корбан чалган вакытта ул урында була алмаса, аның исеменнән дип корбан чалынса, иншаллаһ, кабул була. Ләкин корбанны ул үзе чалса, иң күркәме, иң яхшысы шул санала. Әгәр үзе чала алмый икән, моны берәр оста кешегә кушып, шуның янында дога кылып тора ала. Алай да булдыра алмаса, акчасын күчереп, бу эшне шуны башыннан ахырына кадәр башкаручы кешеләргә тапшырырга да мөмкин. Иң мөһиме, нияте дөрес булырга тиеш.

:: Сүз уңаеннан, корбанны да хәзер өйдән чыкмый гына чалдырту хезмәтләре булдырылды. Картага акча күчерәсең дә синең өчен чалып та, эшкәртеп тә, хәтта таратып та бирәләр. Бу рәвешле чалдырылган корбан дөрес буламы?
– Һәр кешенең мөмкинчелеге төрле. Ләкин корбанлыкны үзебез сатып алып, үзебез ашатып, үстереп, үз кулыбыз белән чалып, үзебез эшкәртеп, өч өлешкә бүлеп, үзебез таратсак, иң саваплысы шул була. Дөрестән дә, кешеләр хәзер моның җайлы юлын тапты. Корбан чалган өчен акча күчерәләр дә вәссәлам. Үзләре күрмиләр дә, белмиләр дә. Иншаллаһ, ул болай эшләгәндә дә кабул була. Әмма монда бит төп мәгънә – гаиләбезне берләштерү, Аллаһы Тәгаләгә якынаю. Шуңа күрә корбан чалуны үзең башкару, анда үзең катнашу, үзең тарату хәерлерәк.

Илдар Мөхәммәтҗанов

КОРБАН ЧАЛГАНДА НИНДИ ХАТАЛАРДАН САКЛАНЫРГА КИРӘК?
– Корбанны акыллы, балигъ булган, нисабы малына ия булган мөселман кеше чалырга тиеш. Кайбер кеше: «Быел корбанны – ун яшьлек кызым исеменнән, киләсе елга хатыным исеменнән чалдырам», – ди. Бу дөрес түгел. Ник дигәндә, ун яшьлек бала әле балигъ түгел.
– Еш кына корбан чалганда фәлән кешегә, әйтик, «Мөхәммәт Габдулла улына корбан чалдык» дип әйтәләр. Бер карасаң, дөрес тә кебек. Әмма төптәнрәк уйлап карасаң, болай эшләү хакыйкатькә туры килми. «Мөхәммәт Габдулла улы исеменнән Аллаһы Тәгалә ризалыгы өчен корбан», – дип әйтергә кирәк. Мөхәммәт Габдулла улына дип әйтсәк, кешене Аллаһы Тәгалә дәрәҗәсенә күтәргән булабыз.

:: Үлгән кеше исеменнән корбан чалырга ярыймы?
– Беренчедән, корбан чалу ул исән кешегә тиешле. Шуңа күрә без иң беренче чиратта корбанны үз исемебездән чалырга тиеш. Аннары, икенче сарыкны сатып алып, аны үлгән кеше исеменнән чалсаң да була. Әгәр урын өстендәге кеше: «Корбан көннәренә җитә алмасам, вафат булсам, минем исемемнән корбан чалырсыз», – дип әйтеп, акчасын биреп калдыра икән, ул вакытта инде бу васыятьне үтәргә кирәк була.

:: Корбан ите ничек бүленә?
– Мохтаҗрак гаилә булса, аларга корбан чалу тиешле түгел. Шулай да алар корбан чалган булса, бөтен итен үзенә калдыра ала. Корбан ите үзе өч өлешкә бүленергә тиеш. Корбан чалган кеше аның бер өлешен – мескеннәргә, күршеләргә, фәкыйрьләргә, бер өлешен – туганнарына, якыннарына өләшергә, тагын бер өлешен үзенә калдырырга тиеш.

:: Корбан итеннән калган сөякләрне ни эшләтергә? Аны эткә бирергә ярыймы?
– Корбанлыкның итен, сөяген, канын артык изгеләштерергә кирәкми. Корбан сөякләрен күмәргә кирәк, диләр. Бу хөрмәт йөзеннән эшләнә. Әгәр ул аунап йөрмәсә, ул сөякләрне эткә бирергә дә рөхсәт ителә.

:: Корбан сарыгыннан шашлык пешерергә ярыймы?
– Корбан итеннән нәрсә теләсәк шуны, шул исәптән шашлык та пешерә алабыз. Ләкин корбан итеннән әзерләнгән ризык янында хәмер эчү, тәмәке тарту, гайбәт сөйләү, сүгенү тыела.

:: Корбан сарыгының тиресен сатарга рөхсәт ителәме?
– Корбан сарыгының тиресен сатарга рөхсәт ителә. Ләкин сатылганнан соң кергән керемне үзең өчен кулланырга ярамый. Аны мохтаҗларга сәдака итеп тарату хәерле.

– Корбан чалып биргән кешегә шушы корбан итен биреп кенә исәп-хисап ясасаң буламы?
– Әгәр корбан чалырга махсус кеше яллаганбыз икән, без аңа корбан ите, тиресе белән хезмәт хакы түли алмыйбыз. Бары тик сөйләшенгән күләмдә акчалата гына исәп-хисап ясый алабыз.



Корбан чалу тәртибе



✓Үзе чала белгән кеше корбанын үзе чалырга тиеш. Белмәсә, берәр сугымчы мөселманга әйтеп чалдыра ала.
✓Суйган чакта малга карата хөрмәтле булырга, аны җәфаламыйча, иплән кенә сугым башкарыласы урынга алып килергә кирәк.
✓Пычак алдан ук әзерләнеп, кайрап куелырга тиеш. Мал каршында пычак кайрау һәм бер хайванны икенчесе күз алдында чалу ярамый.
✓Бугазлар алдыннан, малны бәйләп яткыргач, ният әйтелә: «Ният кылдым Аллаһ ризалыгы өчен (фәлән улы яки фәлән кызы исеменнән) корбан чалмакка».
✓Аннан соң корбанның хуҗасы (үзе чалмаса да) түбәндәге доганы укыса яхшы: «Бисмилләһи валлаһу әкбәр. Аллаһуммә минкә уә ләк. Аллаһуммә тәкаббәль минни. Аллаһ исеме белән. Аллаһ бөек». Мәгънәсе: «Йә Аллаһ! Синнән алабыз һәм Сиңа кайтарабыз. Йә Аллаһ! Кабул ит!»
✓Алга таба суючы «Бисмилләһи Аллаһу әкбәр» дип әйтеп малның бугазын кисә.
✓Малның җаны чыкканын көтеп торган вакытта (янында кешеләр булса, бергәләшеп, булмаса – берүзе) берничә тапкыр түбәндәге тәкбирне кабатлап тору яхшы: «Аллаһу әкбәр, Аллаһу әкбәр, лә иләһе илләллаһ. Аллаһу әкбәр, Аллаһу әкбәр уә лилләһил хәмд». Мәгънәсе: «Аллаһ бөек, Аллаһ бөек, Аллаһтан башка илаһ юк. Аллаһ бөек, Аллаһ бөек, барча мактау Аллаһка!»
✓Корбан чалынып, итләре бүленеп, эш беткәннән соң, корбанның хуҗасы, намаз укый белсә, өенә кереп, ике рәкагать шөкер намазы укыса яхшы. Ләкин кеше чакырып укыту кирәк түгел, намаз укылмаса да, Корбан чалу дөрес була.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА әзерләде

Мин = милләт

Асыл

ВАРАЗДАТ ГИЛОЯН, ӘРМӘН, 17 ЯШЬ

ТӘРБИЯ ҺӘМ ТЫШКЫ КЫЯФӘТ – милли асыл минем очракта менә шулар аша чагыла. Үзеңнеке саналган нәрсәләрне дөрес урында куллана белү башкалардан **АЕРЫЛЫП ТОРЫРГА** ярдәм итә. Моннан тыш, безнең милләтнең ир-атларына корычтай характер һәм үзен кеше алдында лаеклы итеп тоту кебек сыйфатлар хас. **ЭТИКЕТ КАГЫЙДӘЛӘРЕ ҺӘМ ХӨРМӘТ ХИСЕ** – тәрбиянең нигезе.

КАЗАНЫШЛАРЫБЫЗ ҺӘМ МИЛЛӘТЕМ КИЧЕРГӘН СЫНАУЛАР – горурлану өчен төп сәбәпләр бу. Мин әрмән булуым белән һәм милләтем турында башкаларга сөйли алуым белән горурланам!

Гаиләбездә традицияләргә зур игътибар бирелә һәм алар үтәлә. **БАЛАЧАКТАН УК ӘТИ-ӘНИ БЕЗГӘ АЛАРНЫ СЕҢДЕРЕП КИЛДЕ**. Әйтик, бер генә Яңа ел бәйрәме дә гыйбадәтханәгә бармыйча узмый. Бер генә бәйрәм дә мул өстәлдән башка оештырылмый. Табын ризыктан да, кунаклар күплегеннән дә сыгылып торырлык булсын! Кунакларны каршы алу һәм аларга ихлас кунакчыллык күрсәтү – **БЕЗНЕҢ ХАЛЫККА ХАС АСЫЛ СЫЙФАТ**.

ТЕЛ, ИҢ БЕРЕНЧЕ ЧИРАТТА, ЯКЫННАРЫҢНЫ АҢЛАУ ӨЧЕН КИРӘК. Үз телләрен белмәгәннәр бик күп нәрсәдән мәхрүм дип саныйм. **БАШКА ТЕЛЛӘРГӘ ТӘРҖЕМӘ ИТЕЛМИ ТОРГАН, СИНЕҢ АНА ТЕЛЕҢӘ ГЕНӘ ХАС КҮПМЕ СҮЗЛӘР БАР!** Моннан тыш, Ватаныңның мәдәниятен һәм тарихын белү өчен дә кирәк ул тел.

Балаларга телне, иң беренче чиратта, гадәти тормыштагы сөйләшү аша тапшырырга була дип саныйм. Балачактан ук бала белән **АНА ТЕЛЕНДӘ** сөйләшергә кирәк. Шулай булган очракта **КИЛӘЧӘКТӘ БЕРНИНДИ ДӘ МӘШӘКАТЬЛӘР ТУМАС**. Аларга милләтнең барлыкка килү тарихын, гореф-гадәтләр турында сөйләү дә мөһим.

БЕР ТЕЛДӘ СӨЙЛӘШӘ ТОРГАН КЕШЕЛӘР ЯНЫНДА ҮЗЕҢНЕ ӨЙДӘГЕЧӘ ХИС ИТӘСЕҢ.

Вараздат быел мәктәп тәмамлаган. Югары уку йортына керергә җыена. Хыялы – ясалма интеллект, программалаштыру буенча белем алу.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА әзерләде. Фото: Анна АРАХАМИЯ

21 июнь | Чәршәмбе

ВГТРК ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара» 16+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
09.00, 17.00 «ЯЛАНАЯКЛЫ КЫЗ». Телесериал 16+
10.00, 23.00 «ШИРОКА РЕКА». Телесериал (Россия) 16+
11.00 «Каравай» 6+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «СЕБЕР КИЯВЕ». Телесериал (на татарском языке) 16+
13.00 «Жырлыйк әле!» 12+
14.00 «Туган авылым» 12+
14.15 «Если хочешь быть здоровым» 16+
14.45 «Музыкаль майдан» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Бергәләп өйрәник» 0+
16.00 «Переведи!» (учим татарский язык) 6+
18.00 «Халкым минем…» 12+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
21.00 «Соотечественники» 16+
00.00 «Каравай» 6+
00.25 «Соотечественники». Лилиана Терегулова. Делай добро и бросай в воду 16+
00.50 «Таяну ноктасы» 16+
01.15 «КВН РТ 2022» 16+
02.05 «Манзара» 16+
03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
03.55 «Аулак өй» 6+
04.45 «Жырлыйк әле!» 12+
05.35 «Онытa алмыйм…» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара» 16+
08.00 «Уткәннәр сагындыра» 12+
08.40 «Әй, язмыш, язмыш…» 16+
09.40 «Икe аккош». Нәҗибә Ихсанова, Исламия Мәхмүтова, Зәһрә Сәхабиева. Тормыш һәм мәхәббәт турында… 16+
10.40 «Туган авылым» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05, 21.25 «Кунак БиТ шоу» 16+
15.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә… 6+
16.30, 20.30 «Таяну ноктасы» 16+
17.00 «Музыкаль майдан» 16+
18.20, 23.10, 05.05 «Әй, язмыш, язмыш…» 16+
19.10, 22.20, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
20.00, 00.15 «Гаилә учагы» 16+
02.45 «Караоке татарча» 12+
03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
04.15 «Икe аккош». Нәҗибә Ихсанова, Исламия Мәхмүтова, Зәһрә Сәхабиева. Тормыш һәм мәхәббәт турында… 16+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
09.55 «Жить здорово!» 16+
10.50 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
16.00 «Мужское/Женское» 16+
16.50 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
19.50 «Куклы наследника Тутти» 16+
21.00 «Время»
22.00 «ВЕЛИКАЯ» (S) 12+
23.00 «Большая игра» 16+
00.00 ПОДКАСТ.ЛАБ «Креативные индустрии» 16+
00.40 ПОДКАСТ.ЛАБ «Свидетели Эйзенштейна» 16+
01.20 ПОДКАСТ.ЛАБ «Пусть не говорят, пусть читают» 16+
02.00 ПОДКАСТ.ЛАБ «Собрались с мыслями» 16+
02.40 ПОДКАСТ.ЛАБ «Жизнь замечательных» 16+
03.00 Новости
03.05 ПОДКАСТ.ЛАБ «Жизнь замечательных» 16+
03.20 ПОДКАСТ.ЛАБ «Свидетели Эйзенштейна» 16+
04.00 ПОДКАСТ.ЛАБ «Жизнь замечательных» 16+
04.35 ПОДКАСТ.ЛАБ «Письма» 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
16.30 Премьера. «Малахов» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Премьера. Павел Трубинер, Татьяна Арнтгольц, Михаил Горевой, Александр Макогон. «ОПЕРАЦИЯ «ПРЕСТОЛ» 12+
23.10 «Вечер» 12+
02.00 Михаил Пореченков, Вера Панфилова, Александр Горбатов, Егор Корешков. «ОСТАТЬСЯ В ЖИВЫХ» 12+

МАТЧ ТВ

06.00, 23.35 «Легендарные клубы» 12+
06.30 «География спорта. Волгоград» 12+
07.00, 10.00, 12.40, 14.55, 17.55, 22.30 Новости
07.05, 15.00, 20.20, 22.35 Все на Матч! Прямой эфир
10.05, 12.20, 00.35, 03.10 Специальный репортаж 12+
10.25 «Футбол на все времена» 12+
11.25 Смешанные единоборства. PRIDE FC. Лучшие бои Фёдора Емельяненко 16+
12.45, 15.45 Футбол. BetBoom МКС 2023. Прямая трансляция
18.00 «Король ринга. Николай Королёв». Документальный фильм 12+
19.10 Профессиональный бокс. Д. Бивол – Ф. Валера. Трансляция из Москвы 16+
21.00 Бильярд. «BetBoom Кубок Чемпионов». Прямая трансляция из Москвы
00.55 Футбол. Чемпионат Бразилии. «Сан-Паулу» – «Атлетико Паранаэнсе». Прямая трансляция
03.05 Новости 0+
03.25 Футбол. Чемпионат Бразилии. «Флуминенсе» – «Атлетико Минейро». Прямая трансляция.
05.35 Стрельба из лука. Кубок мира. Трансляция из Колумбии 0+

НТВ

05.00 Детективный сериал «МОСКВА. ЦЕНТРАЛЬНЫЙ ОКРУГ» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25, 10.35 Сериал «ЛЕСНИК» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.50 «За гранью» 16+
17.55 «ДНК» 16+
20.00 «ФЕНИКС» (S) 16+
22.15, 00.00 «РЕАЛИЗАЦИЯ» (S) 16+
00.50 «Основано на реальных событиях». «Подвиг разведчика» 16+
02.35 Сериал «МЕЧ» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.05 «Давай разведёмся!» 16+
09.05 «Тест на отцовство» 16+
11.15 «Понять. Простить» 16+
12.30 «Порча». «Не могу без тебя» 16+
13.00 «Знахарка» 16+
13.30 «Верну любимого» 16+
14.05 «Голоса ушедших душ» 16+
14.40 «ТОЛЬКО ПО ЛЮБВИ» 16+
19.00 «ПРИДУМАННОЕ СЧАСТЬЕ» 16+
23.20 «Понять. Простить» 16+
00.30 «Порча» 16+
01.00 «Знахарка» 16+
01.35 «Верну любимого» 16+
02.00 «Голоса ушедших душ» 16+
02.25 «Тест на отцовство» 16+
04.05 «Давай разведёмся!» 16+
04.55 «Знать будущее. Жизнь после Ванги» 16+
05.45 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

05.30 «ЗАСТАВА ЖИЛИНА». Телесериал. 7-я и 8-я серии 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 17.00, 19.00 Новости дня 16+
09.15, 21.00 «Открытый эфир» 16+
11.00 «КОНЕЦ ОПЕРАЦИИ «РЕЗИДЕНТ». 1-я серия 12+
12.35, 13.15, 15.05 «ЗАСТАВА ЖИЛИНА». Телесериал. 9-я – 12-я серии 16+
15.00 Военные новости 16+
17.15 «Освобождая Родину». Док. сериал. «Битва за Украину. Игра стратегов». 1-я серия 16+
18.00 «Освобождая Родину». Док. сериал. «Битва за Украину. Игра стратегов». 2-я серия 16+
18.50 «Специальный репортаж» 16+
19.55 «По горячим следам» 16+
20.10 «Секретные материалы». Док. сериал 16+
22.45 «Между тем» 12+
23.15 «БЕССМЕРТНЫЙ ГАРНИЗОН» 12+
01.10 «КОНЕЦ ОПЕРАЦИИ «РЕЗИДЕНТ» 12+
03.30 «Брестская крепость» 12+
04.15 «ЗАСТАВА ЖИЛИНА». Телесериал. 9-я и 10-я серии 16+

22 июнь | Пәнҗешәмбе

ВГТРК ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара» 16+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
09.00, 17.00 «ЯЛАНАЯКЛЫ КЫЗ». Телесериал 16+
10.00 «ШИРОКА РЕКА». Телесериал (Россия) 16+
11.00 «Каравай» 6+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 23.10 «РЖЕВ» 12+
14.45 «Песни военных лет» 12+
15.10 «Сәнечә» 0+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Шомабас» һәм «Алты хәреф» 0+
16.00 «Соотечественники» 16+
18.00 «Юлчы» 16+
19.00, 20.00 «Точка опоры» 16+
21.00 «Погружение на 100» 12+
21.10 «Соотечественники» 16+
22.00 «Вызов 112» 16+
22.10 «Безнең Республика – безнең гамәл» 16+
01.10 «Видеоспорт» 16+
01.35 «Соотечественники». Б. Кузнецов. С осколком под сердцем 16+
02.00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 16+
03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
03.55 «Аулак өй» 6+
04.45 «Кәмит Җәвит» 16+
05.35 «Онытa алмыйм…» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара» 16+
08.00 «Уткәннәр сагындыра» 12+
08.40, 23.10, 04.15 «Кәмит Җәвит». Юмористик тапшыру 16+
09.40 «Гаилә учагы» 16+
10.40 «Туган авылым» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05 «Әниемнең җылы кочагы» 16+
15.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә… 6+
16.30 «Таяну ноктасы» 16+
17.00 «Музыкаль майдан» 16+
18.20 «Кунак БиТ шоу» 16+
19.10 «Таң атмады бүген». Әдәби-музыкаль композиция 16+
20.00 «Әниемнең җылы кочагы» 16+
21.25 «Икe аккош». Нәҗибә Ихсанова, Исламия Мәхмүтова, Зәһрә Сәхабиева. Тормыш һәм мәхәббәт турында… 16+
22.20 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
00.15 «Юлчы» (субтитрлы) 16+
02.45 «Караоке татарча» 12+
03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш…» (субтитрлы) 16+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
09.55 «Жить здорово!» 16+
10.50 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
16.00 «Мужское/Женское» 16+
16.50 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
19.50 «Куклы наследника Тутти» 16+
21.00 «Время»
22.00 «ВЕЛИКАЯ» (S) 12+
23.00 «Большая игра» 16+
00.00 ПОДКАСТ.ЛАБ «Собрались с мыслями» 16+
00.40 ПОДКАСТ.ЛАБ «Космические истории» 16+
01.20 ПОДКАСТ.ЛАБ «Обязательно к прочтению» 16+
02.00 ПОДКАСТ.ЛАБ «Антропология» 16+
02.40 ПОДКАСТ.ЛАБ «Произвольная программа» 16+
03.00 Новости
03.05 ПОДКАСТ.ЛАБ «Произвольная программа» 16+
03.20 ПОДКАСТ.ЛАБ «Собрались с мыслями» 16+
04.00 ПОДКАСТ.ЛАБ «Свидетели Эйзенштейна» 16+

РОССИЯ 1

04.00 «22 июня, ровно в четыре утра… Реквием Роберта Рождественского»
05.10 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
16.30 Премьера. «Малахов» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Премьера. Павел Трубинер, Татьяна Арнтгольц, Михаил Горевой. «ОПЕРАЦИЯ «ПРЕСТОЛ» 12+
23.10 «Вечер» 12+
02.00 «22 июня, ровно в четыре утра… Реквием Роберта Рождественского»
03.10 «СОРОКАПЯТКА» 12+

МАТЧ ТВ

06.00, 14.25, 23.35 «Легендарные клубы» 12+
06.30 Матч! Парад 16+
07.00, 10.00, 12.55, 14.55, 17.20, 22.30 Новости
07.05, 15.30, 20.20, 22.35 Все на Матч! Прямой эфир
10.05, 12.35, 00.35, 03.10 Специальный репортаж 12+
10.25 «Футбол на все времена» 12+
11.25 Смешанные единоборства. UFC. Стипе Миочич против Фрэнсиса Нганну. Трансляция из США 16+
13.00 «Есть тема!» Прямой эфир
15.00 «Вид сверху» 12+
16.20 Автоспорт. Чемпионат России по дрэг-рейсингу 0+
16.50 Автоспорт. G-Drive Российская серия кольцевых гонок. Трансляция из Казани 0+
17.25 «Кулачные бои». Документальный фильм 16+
19.10 Бокс. Bare Knuckle FC. Лучшее 16+
21.00 Бильярд. «BetBoom Кубок Чемпионов». Прямая трансляция из Москвы
00.55 Футбол. Чемпионат Бразилии. «Гремио» – «Америка Минейро». Прямая трансляция
03.05 Новости 0+
03.25 Футбол. Чемпионат Бразилии. «Брагантино» – «Фламенго». Прямая трансляция
05.35 Стрельба из лука. Кубок мира. Трансляция из Колумбии 0+

НТВ

05.00 Детективный сериал «МОСКВА. ЦЕНТРАЛЬНЫЙ ОКРУГ» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25, 10.35 Сериал «ЛЕСНИК» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.50 «За гранью» 16+
17.55 «ДНК» 16+
20.00 «ФЕНИКС» (S) 16+
22.15, 00.00 Остросюжетный сериал «РЕАЛИЗАЦИЯ» (S) 16+
00.50 «Поздняков» 16+
01.00 «Мы и наука. Наука и мы» 12+
02.10 Сериал «МЕЧ» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.00 «Давай разведёмся!» 16+
09.00 «Тест на отцовство» 16+
11.15 «Понять. Простить» 16+
12.30 «Порча». «Затхлая вода» 16+
13.00 «Знахарка» 16+
13.35 «Верну любимого» 16+
14.10 «Голоса ушедших душ» 16+
14.45 «ХОЧУ ТЕБЕ ВЕРИТЬ» 16+
19.00 «ИДЕАЛЬНЫЙ ВЫБОР» 16+
23.20 «Понять. Простить» 16+
00.30 «Порча» 16+
01.00 «Знахарка» 16+
01.35 «Верну любимого» 16+
02.00 «Голоса ушедших душ» 16+
02.25 «Тест на отцовство» 16+
04.05 «Давай разведёмся!» 16+
04.55 «Знать будущее. Жизнь после Ванги» 16+
05.45 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

05.40 «ЗАСТАВА ЖИЛИНА». Телесериал. 11-я и 12-я серии 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 17.00, 19.00 Новости дня 16+
09.15, 21.00 «Открытый эфир» 16+
11.00 «КОНЕЦ ОПЕРАЦИИ «РЕЗИДЕНТ». 2-я серия 12+
13.50, 15.05, 17.15 «ЖДИ МЕНЯ». 1-я – 4-я серии 16+
15.00 Военные новости 16+
18.00 «Часовые памяти. Ставрополье». Документальный фильм 16+
18.50 «Специальный репортаж» 16+
19.55 «По горячим следам» 16+
20.10 «Код доступа» 12+
22.45 «Между тем» 12+
23.15 «Обыкновенный фашизм» 16+
01.25 «НА ПУТИ В БЕРЛИН» 12+
02.55 «БЕСПОКОЙНОЕ ХОЗЯЙСТВО» 12+
04.40 «ЖДИ МЕНЯ». Телесериал. 1-я и 2-я серии 16+

23 июнь | Җомга

ВГТРК ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Вести Приволжского федерального округа»
09.15 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 16+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
09.00, 17.00 «ЯЛАНАЯКЛЫ КЫЗ». Телесериал 16+
10.00 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
11.00 «Нәсыйхәт» 16+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00 «Ком сәгате» 16+
13.00 «Башваткыч» 12+
14.00 «Актуальный ислам» 16+
14.15 «Здоровая семья: мама, папа и я» 12+
14.45 «Музыкаль майдан» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Тизрәк! Алга! Җитезрәк!» һәм «Алты хәреф» 0+
16.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 16+
18.00 «Родная земля» 12+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Кучтәнәч» 0+
21.00 «Юлчы» 16+
22.10 «КВН РТ 2023» 16+
23.10 «ДЕЛО В ТЕБЕ» 16+
00.45 «Точка опоры» 16+
01.35 Н. Исәнбәт. «ГӨЛҖАМАЛ». Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры спектакле 16+
03.50 «Аулак өй» 6+
04.20 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 16+
04.45 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 16+
05.35 «Онытa алмыйм…» Ретро-концерт 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 16+
08.00 «Уткәннәр сагындыра» 12+
08.50, 18.20, 23.10, 04.15 «Ком сәгате» 16+
09.50, 16.30, 00.15 «Нәсыйхәт» 16+
10.30, 19.10, 22.10, 03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05, 21.25 «Уроки истории» 6+
15.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә… 6+
17.00 «Музыкаль майдан» 16+
20.00 «Родная земля» 12+
20.30 «Таяну ноктасы» 16+
01.05 Ж. Фәйзи, Т. Гыйззәт. «БАШМАГЫМ». Музыкаль комедия 16+
03.05 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш…» (субтитрлы) 16+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
09.55 «Жить здорово!» 16+
10.50 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
16.00 «Мужское/Женское» 16+
16.50 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.40 «Человек и закон» с Алексеем Пимановым 16+
19.45 «Поле чудес» (S) 16+
21.00 «Время»
21.45 «ВЕЛИКАЯ». Многосерийный фильм (S) 12+
22.45 «Прыжок из космоса» 12+
23.50 Документальный фильм «Первая женщина во главе Дома Моды Christian Dior» (S) 12+
00.55 ПОДКАСТ.ЛАБ «Не лыком шиты» 16+
01.40 ПОДКАСТ.ЛАБ «20 лет спустя» 16+
02.20 ПОДКАСТ.ЛАБ «АстроУмные» 16+
02.55 ПОДКАСТ.ЛАБ «Креативные индустрии» 16+
03.35 ПОДКАСТ.ЛАБ «Мелодии моей жизни» 16+
04.10 ПОДКАСТ.ЛАБ «Свидетели Эйзенштейна» 16+
04.45 ПОДКАСТ.ЛАБ «Легкие деньги» 16+
05.20 ПОДКАСТ.ЛАБ «Триггеры» 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
16.30 Премьера. «Прямой эфир» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.15 Местное время. Вести-Татарстан
21.30 Премьера. «Удивительные люди. Новый сезон». Финал 12+
00.50 Данила Козловский, Владимир Ильин, Ирина Горбачёва. «ТРЕНЕР» 12+
03.15 Фёдор Бондарчук, Сергей Бондарчук, Владимир Яглыч, Светлана Ходченкова. «ВОЙН» 12+

МАТЧ ТВ

06.00, 14.25, 23.55 «Легендарные клубы» 12+
06.30 Автоспорт. G-Drive Российская серия кольцевых гонок. Трансляция из Казани 0+
07.00, 10.00, 12.55, 14.55 Новости
07.05, 15.00, 23.00 Все на Матч! Прямой эфир
10.05 «Небесная грация» 0+
10.25 «Футбол на все времена» 12+
11.25 Смешанные единоборства. UFC. Хабиб Нурмагомедов. Лучшее 16+
12.35 «Лица страны. Андрей Корешков» 12+
13.00 «Есть тема!» Прямой эфир
15.30 Смешанные единоборства. One FC. Анатолий Малыхин против Аржана Буллара. Прямая трансляция из Таиланда
19.30 Смешанные единоборства. URAL FC. Прямая трансляция из Казахстана
21.30 Бильярд. «BetBoom Кубок Чемпионов». Прямая трансляция из Москвы
00.55 Баскетбол. Чемпионат Европы. Женщины. 1/4 финала. Трансляция из Словении 0+
02.50 Новости 0+
02.55 Футбол. Матч легенд. Команда Роналдиньо против команды Роберто Карлоса. Прямая трансляция из США.
05.00 Бокс. Bare Knuckle FC. Л. Паломино против Д. Лилли. Прямая трансляция из США

НТВ

05.00 Детективный сериал «МОСКВА. ЦЕНТРАЛЬНЫЙ ОКРУГ» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00 «Сегодня»
08.25, 10.35 Сериал «ЛЕСНИК» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.50 «ДНК» 16+
17.55 «Жди меня» 12+
20.00 Остросюжетный сериал «ФЕНИКС» (S) 16+
22.15 «РЕАЛИЗАЦИЯ» (S) 16+
00.00 «Своя правда» 16+
02.15 «Захар Прилепин. Уроки русского» 12+
02.40 «Квартирный вопрос» 0+
03.30 Сериал «МЕЧ» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
07.55 «Давай разведёмся!» 16+
08.55 «Тест на отцовство» 16+
11.10 «Понять. Простить» 16+
12.25 «Порча». «Пика» 16+
12.55 «Знахарка» 16+
13.30 «Верну любимого» 16+
14.05 «Голоса ушедших душ» 16+
14.40 «ПРИДУМАННОЕ СЧАСТЬЕ» 16+
19.00 «ЦЕНА ОШИБКИ» 16+
23.20 «Понять. Простить» 16+
00.30 «Порча» 16+
01.00 «Знахарка» 16+
01.35 «Верну любимого» 16+
02.00 «Голоса ушедших душ» 16+
02.25 «Тест на отцовство» 16+
04.05 «Давай разведёмся!» 16+
04.55 «Знать будущее. Жизнь после Ванги» 16+
05.45 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

06.35, 09.20 «ЖДИ МЕНЯ». Телесериал. 3-я и 4-я серии 16+
09.00, 13.00, 17.00, 19.00 Новости дня. 16+
09.55 «СТРЕЛЫ РОБИН ГУДА» 12+
11.40, 13.25 «УСНУВШИЙ ПАССАЖИР» 16+
13.55, 15.05 «РЫСЬ» 16+
15.00 Военные новости 16+
16.20, 17.15, 19.45 «УЧАСТОК ЛЕЙТЕНАНТА КАЧУРЫ». Телесериал. «Черная паутина». 1-я – 4-я серии 16+
22.00 «Здравствуйте, товарищи!» Премьера! 16+
23.00 «Музыка+». Премьера! 12+
00.10 «СЕМЬ ЧАСОВ ДО ГИБЕЛИ» 12+
01.25 «ВАМ И НЕ СНИЛОСЬ…» 12+
02.55 «1941-й. Накануне». Док. фильм 12+
03.50 «НА ПУТИ В БЕРЛИН» 12+

24 июнь | Шимбә

ТАТАРСТАН

08.00 «Вести-Татарстан»
08.20 Местное время. Суббота

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
07.00 «Сиңа Миннән Сәлам». Музыкаль котлаулар 16+
09.00 «Әй, язмыш, язмыш...» Винера Ганиева 16+
10.00 «Кайнар хит» 16 +
11.00 «Туган авылым» 12+
11.30 «Казаннан – Казанга» 16+
12.00 «Каравай» 6+
12.30 «Видеоспорт» 16+
13.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
13.30 «Гаилә учагы» 16+
14.00 «Илмир Низамов һәм дуслар». Концерт 12+
15.00 «Сабантуй 2023». Репортаж 12+
17.00 «Татар халык җырлары» 0+
17.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 16+
18.00 «Кәмит Җәвит». Юмористик тапшыру 16+
19.00 «Халкым минем...» 12+
19.30, 21.30 Новости в субботу 16+
20.00 «Адымнар» 16+
20.30 «Җырлыйк әле!» 12+
22.00 «Кунак БиТ шоу». К. Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры артистлары 16+
23.00 «ВЕЧНЫЙ ДЕНЬ СВЯТОГО ВАЛЕНТИНА» 16+
00.25 «Соотечественники». Альберт Асадуллин. Только любовь 16+
00.50 «Вехи истории». Путь татарстанского кинематографа 16+
01.15 «УЕННАН УЙМАК-2». Телевизион нәфис фильм 16+
03.20 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 16+
03.45 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
03.55 «Аулак өй» 6+
04.45 «Кәмит Җәвит» 16+
05.35 «Оныта алмыйм...» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00 «Баянын кулыннан төшмәде». Татарстанның халык артисты Рәшит Мостафин турында телеочерк 16+
07.00 «Сиңа Миннән Сәлам» 16+
09.00 «Кунак БиТ шоу» 16+
10.00 «Кайнар хит» 16+
11.00, 18.15, 03.00 «Башваткыч» 12+
12.05 «Җырлыйк әле!» 12+
13.00 «Туган авылым» 12+
13.20 «Бу – димәк, мәхәббәт». Габделфәт Сафин концерты 16+
15.00 «Сабантуй 2023» 12+
17.15 «Казаннан – Казанга» 16+
17.45 «Халкым минем» 12+
19.05 «Җырлыйк әле!» 12+
20.00 «Адымнар» 16+
20.30 «Җиде малай». Фирдүс Тямаев концерты 16+
23.20 Т. Миңнуллин. «АЛТЫ КЫЗГА БЕР КИЯҮ». Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры спектакле 16+
01.20 Г.Исхакый. «АЛДЫМ-БИРДЕМ». Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры спектакле 16+
03.50 «Җырлыйк әле!» 12+
04.40 «Юлчы» (субтитрлы) 16+
05.05 «Халкым минем» 12+
05.30 «Нәсыйхәт» 16+

1 КАНАЛ

06.00 Телеканал «Доброе утро. Суббота»
09.45 «Слово пастыря» 0+
10.00 Новости (с субтитрами)
10.15 Премьера. «Поехали!» 12+
11.05 «МКС-селфи» 12+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Поединки. «Нелегальная жизнь полковника Рыбкиной» 16+
14.05 «СУДЬБА РЕЗИДЕНТА» 12+
17.10 Веселые и довольно находчивые в программе «АБРАКАДАБРА!» (S) 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 «АБРАКАДАБРА!» (S) 16+
19.55 Премьера. «Кто хочет стать миллионером?» 12+
21.00 «Время»
21.35 «Сегодня вечером» 16+
23.40 «Акустика». Гарик Сукачев (S) 16+
00.40 «Алые паруса – 2023». Прямая трансляция из Санкт-Петербурга (S)
01.05 ПОДКАСТ.ЛАБ «Психика» 16+
01.45 ПОДКАСТ.ЛАБ «Космические истории» 16+
02.20 ПОДКАСТ.ЛАБ «20 лет спустя» 16+
02.55 ПОДКАСТ.ЛАБ «Обязательно к прочтению» 16+
03.30 ПОДКАСТ.ЛАБ «Триггеры» 16+
04.05 ПОДКАСТ.ЛАБ «Произвольная программа» 16+
04.40 ПОДКАСТ.ЛАБ «Пусть не говорят, пусть читают» 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России. Суббота»
08.00 Местное время. Вести-Татарстан
08.20 Местное время. Суббота
08.35 «По секрету всему свету»
09.00 «Формула еды» 12+
09.25 «Пятеро на одного»
10.10 «Сто к одному». Телеигра
11.00 Вести
12.00 «Доктор Мясников» 12+
13.05 Анна Андрусенко, Кирилл Кузнецов, Светлана Тимофеева-Летуновская, Людмила Нильская. «ЧУЖАЯ» 12+
17.00 Вести
17.50 «Привет, Андрей!» Вечернее шоу Андрея Малахова 12+
20.00 Вести
21.00 Премьера. «ТАЙНАЯ ЖИЗНЬ МАРГАРИТЫ» 12+
00.40 «Алые паруса – 2023». Прямая трансляция из Санкт-Петербурга
01.05 «ДЕРЕВЕНЩИНА» 12+
04.25 «ОАЗИС ЛЮБВИ» 16+

МАТЧ ТВ

06.00 Бокс. Bare Knuckle FC. Луис Паломино против Джеймса Лилли. Прямая трансляция из США
07.00, 10.00, 12.50, 18.55 Новости
07.05, 12.25, 15.50, 18.00, 21.00, 00.55 Все на Матч! Прямой эфир
10.05 «ПРИКЛЮЧЕНИЯ БОЛЕКА И ЛЁЛЕКА». Мультипликационный фильм 0+
10.40 «Кулачные бои». Документальный фильм 16+
12.55 Футбол. Суперлига. Женщины. «Локомотив» (Москва) – «Звезда-2005» (Пермь). Прямая трансляция
14.55, 16.10 Прыжки в воду. Чемпионат России. Прямая трансляция из Екатеринбурга
19.00 Футбол. Матч легенд. Команда Роналдиньо против команды Роберто Карлоса. Трансляция из США 0+
22.10 Смешанные единоборства. UFC. Джош Эмметт против Илии Топурии. Прямая трансляция из США
01.25 Баскетбол. Чемпионат Европы. Женщины. 1/2 финала. Трансляция из Словении 0+
02.50 Новости 0+
02.55 Футбол. Чемпионат Бразилии. «Крузейро» – «Сан-Паулу». Прямая трансляция
05.05 Karate Combat 2023. Прямая трансляция из США

НТВ

04.55 «Жди меня» 12+
05.40 Сериал «БЕРЕГОВАЯ ОХРАНА» (S) 16+
07.25 «Смотр» 0+
08.00, 10.00, 16.00 «Сегодня»
08.20 «Поедем, поедим!» 16+
09.20 «Едим дома» 0+
10.20 «Главная дорога» 16+
11.00 «Живая еда» с Сергеем Малозёмовым 12+
12.00 «Квартирный вопрос» 0+
13.00 «Модный vs Народный» 12+
14.20 «Своя игра» 0+
15.20 «Игры разумов» 0+
16.20 «Следствие вели...» 16+
19.00 «Центральное телевидение» с Вадимом Такменевым
20.20 «Секрет на миллион». Сергей Проханов 16+
22.25 «Квартирник у «Лахта центра» (S) 16+
00.20 «Международная пилорама» 18+
01.05 «Дачный ответ» 0+
02.05 Сериал «МЕЧ» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «6 кадров» 16+
06.45 «ИСТЕРЗАННАЯ» 16+
10.15 «ЛИЧНЫЕ ОБСТОЯТЕЛЬСТВА». 1-я – 8-я серии 16+
19.00 «МОЯ МАМА». 25-я – 29-я серии 16+
00.00 «ВСПОМИНАЯ ТЕБЯ» 16+
03.30 «6 кадров» 16+
03.35 «ЛИЧНЫЕ ОБСТОЯТЕЛЬСТВА». 1-я – 4-я серии 16+

ЗВЕЗДА

05.20 «МАТРОС ЧИЖИК» 6+
06.55, 08.15 «МОРСКОЙ ОХОТНИК» 12+
08.00, 13.00, 19.00 Новости дня 16+
08.40 «31 ИЮНЯ» 12+
11.40 «Легенды музыки». Михаил Боярский 12+
12.10 «СССР. Знак качества» 12+
13.15 «Не факт!» 12+
13.40 «Война миров». Док. сериал 16+
14.30 «Легенды кино» 12+
15.20, 19.25 «БОЛЬШАЯ ПЕРЕМЕНА». Телесериал. 1-я – 4-я серии 12+
21.20 «Легендарные матчи». «Кубок мира 2011. Волейбол. Мужчины. 11 тур. Польша – Россия» 12+
23.50 «УСНУВШИЙ ПАССАЖИР» 16+
01.20 «МОРСКОЙ ОХОТНИК» 12+
02.30 «СЕМЬ ЧАСОВ ДО ГИБЕЛИ» 12+
03.40 «Врангель. Путь русского генерала». Док. фильм 12+

25 июнь | Якшәмбе

ТАТАРСТАН

08.00 Местное время. Воскресенье

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00 «САБАНТУЙ МАҖАРАЛАРЫ». Телевизион музыкаль фильм 12+
08.00 «Адымнар» 16+
08.30 Мультфильмы 0+
08.40 «Сөенеч» 0+
08.45 «Әти һәм мин» 0+
09.15 «Тамчы-шоу» 0+
09.45 «Яшьләр тукталышы» 0+
10.15 «Ачыктан-ачык» 16+
11.00 «Туган авылым» 12+
11.20 «Килеп китсәм ни була?» Винарис Ильегет 12+
12.00 «Каравай» 6+
12.30 «Закон. Парламент. Общество» 16+
13.00 «Адымнар» 16+
13.30 «Погружение на 100» 12+
13.40 «Музыкаль мәйдан» 16+
14.00 «Безнең Республика – безнең гамәл» 16+
15.00 «Әниемнең җылы кочагы» 16+
16.00 «Ком сәгате» 16+
17.00 «Видеоспорт» 16+
17.30 «Соотечественники» 16+
18.00 «Башваткыч»12+
19.00 «Илмир Низамов һәм дуслар» 12+
20.00 «Заман көзгесе» 6+
20.30 «Профсоюз – союз сильных» 12+
20.45 «Батырлар» 12+
21.00 «Әй, язмыш, язмыш...» Сәлимҗан хәзрәт Домнин 16+
22.00 «ПОДМЕНА» 12+
23.35 «ОПАСНЫЕ ГАСТРОЛИ» 16+
01.05 «Уроки истории». Татарстан и татары 16+
02.00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 16+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 16+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 16+
04.45 «Җырлыйк әле!» 12+
05.35 «Оныта алмыйм...» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00 «Заман көзгесе» 6+
06.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
07.00 «Адымнар» 16+
07.30 Т.Миңнуллин . «ЙӨРӘК МАЕМ». Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры спектакле 16+
10.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
10.30 «Калеб» 6+
11.10 «Тамчы-шоу» 6+
11.40 «Бергәләп өйрәник» 6+
12.05 «Сәлам» 6+
12.35 «Халкым минем» 12+
13.00 «Туган авылым» 12+
13.20 «Гаилә учагы» 16+
13.50 Т.Миңнуллин. «ӘЛДЕРМЕШТӘН ӘЛМӘНДӘР». Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры спектакле 16+
16.20 «Кәмит Җәвит». Юмористик тапшыру 16+
17.15 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
18.10 «Әниемнең җылы кочагы» 16+
19.05 «Ком сәгате» 16+
20.00 «ЯЛТ-ЙОЛТ». «МУНЧА ТАШЫ» эстрада театры спектакле 16+
23.45 «Ком сәгате» 16+
00.40 «Сәлам» 6+
01.05 «Манзара». Мәгълүмати- күңел ачу программасы 16+
02.40 «Адымнар» 16+
03.15 Х.Ибраһимов. «ҖИЗНӘКӘЙ». Уфа «Нур» татар дәүләт драма театры спектакле 16+
05.25 «Шаян хәлләр» 16+

1 КАНАЛ

06.00 Новости
06.10 ПОДКАСТ.ЛАБ «Космические истории» 16+
06.55 «Играй, гармонь любимая!» (S) 12+
07.40 «Часовой» (S) 12+
08.10 «Здоровье» 16+
09.20 «Мечталлион». Национальная лотерея (S) 12+
09.40 «Непутевые заметки» с Дм. Крыловым 12+
10.00 Новости (с субтитрами)
10.15 Жанна Бадоева в проекте-путешествии «Жизнь других» (S) 12+
11.10 Премьера. «Повара на колесах» 12+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 «Видели видео?» 0+
14.05 «СПРОСИТЕ МЕДСЕСТРУ». Многосерийный фильм (S) 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
19.00 «Две звезды. Отцы и дети». Новый сезон (S) 12+
21.00 «Время»
22.35 Игорь Костолевский, Игорь Гордин в многосерийном фильме «СЕРЕБРЯНЫЙ ВОЛК» (S) 16+
23.35 ПОДКАСТ.ЛАБ «Антропология» 16+
00.15 ПОДКАСТ.ЛАБ «Кот Шрёдингера» 16+
00.55 ПОДКАСТ.ЛАБ «АстроУмные» 16+
01.40 ПОДКАСТ.ЛАБ «Не лыком шиты» 16+
02.20 ПОДКАСТ.ЛАБ «20 лет спустя» 16+
02.55 ПОДКАСТ.ЛАБ «Креативные индустрии» 16+
03.35 ПОДКАСТ.ЛАБ «Свидетели Эйзенштейна» 16+
04.10 ПОДКАСТ.ЛАБ «Мелодии моей жизни» 16+

РОССИЯ 1

06.10 Анна Невская, Константин Соловьёв, Анна Банщикова. «ПОЛЫНЬ ТРАВА ОКАЯННАЯ» 12+
08.00 Местное время. Воскресенье
08.35 «Когда все дома с Тимуром Кизяковым»
09.25 «Утренняя почта с Николаем Басковым»
10.10 «Сто к одному». Телеигра
11.00 Вести
12.00 Премьера. «Большие перемены»
13.05 Ольга Ломоносова, Дмитрий Ульянов, Ирина Розанова, Надежда Азоркина, Михаил Евланов, Дмитрий Орлов. «ВСЁ КАК У ЛЮДЕЙ» 12+
17.00 Вести
17.50 Премьера. «Песни от всей души». Вечернее шоу Андрея Малахова 12+
20.00 Вести недели
22.00 Москва. Кремль. Путин
22.40 «Воскресный вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
01.30 «ПОЛЫНЬ ТРАВА ОКАЯННАЯ» 12+

МАТЧ ТВ

06.00 «Легендарные клубы» 12+
06.30 Автоспорт. Чемпионат России по дрэг-рейсингу 0+
07.00, 10.00, 12.50, 20.30 Новости.
07.05, 18.05, 20.35, 00.05 Все на Матч! Прямой эфир
10.05 «ПРИКЛЮЧЕНИЯ БОЛЕКА И ЛЁЛЕКА». Мультипликационный фильм 0+
10.40, 15.55 Мотоспорт. Чемпионат России по шоссейно-кольцевым гонкам. Суперспорт. Прямая трансляция
11.45, 14.55 Мотоспорт. Чемпионат России по шоссейно-кольцевым гонкам. Супербайк. Прямая трансляция
12.55 Регби. Товарищеский матч. Сборная России – «Барбарианс». Прямая трансляция из Москвы
17.10 Прыжки в воду. Чемпионат России. Прямая трансляция из Екатеринбурга
18.25 Пляжный волейбол. Чемпионат России. Женщины. Финал. Прямая трансляция из Анапы
19.25 Пляжный волейбол. Чемпионат России. Мужчины. Финал. Прямая трансляция из Анапы
21.55 Футбол. Чемпионат Бразилии. «Палмейрас» – «Ботафого». Прямая трансляция
00.25 Футбол. Чемпионат Бразилии. «Сантос» – «Фламенго». Прямая трансляция
02.35 «Лица страны. Андрей Корешков» 12+
02.55 Новости 0+
03.00 Баскетбол. Чемпионат Европы. Женщины. Финал. Трансляция из Словении 0+
05.00 Мотоспорт. Чемпионат России по шоссейно-кольцевым гонкам 0+

НТВ

04.50 Сериал «БЕРЕГОВАЯ ОХРАНА» (S) 16+
06.35 «Центральное телевидение» 16+
08.00, 10.00, 16.00 «Сегодня»
08.20 «У нас выигрывают!» Лотерейное шоу 12+
10.20 «Первая передача» 16+
11.00 «Чудо техники» 12+
11.55 «Дачный ответ» 0+
13.00 «НашПотребНадзор» 16+
14.05 «Однажды...» 16+
15.00 «Своя игра» 0+
16.20 «Следствие вели...» 16+
18.00 «Новые русские сенсации» 16+
19.00 «Итоги недели» с И. Зейналовой.
20.20 «МСТИТЕЛЬ. СТРАШНЫЙ ЛЕС» (S) 16+
23.55 «Маска» (S) 12+
03.50 Сериал «МЕЧ» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «ЛИЧНЫЕ ОБСТОЯТЕЛЬСТВА» 16+
06.55 «ИСТЕРЗАННАЯ». 91-я – 94-я серии 16+
10.30 «ИДЕАЛЬНЫЙ ВЫБОР» 16+
14.45 «ЦЕНА ОШИБКИ» 16+
19.00 «МОЯ МАМА». 30-я – 34-я серии 16+
00.00 «ЛЮБОВЬ ЛЕЧИТ» 16+
03.15 «ЛИЧНЫЕ ОБСТОЯТЕЛЬСТВА». 5-я – 8-я серии 16+

ЗВЕЗДА

05.30 «АТЫ-БАТЫ, ШЛИ СОЛДАТЫ...» 12+
07.15 «ЕСЛИ ВРАГ НЕ СДАЕТСЯ...» 12+
09.00 «Новости недели» 16+
09.25 «Служу России» 12+
09.55 «Военная приемка» 12+
10.40 «Скрытые угрозы» с Николаем Чиндяйкиным. «Альманах №148» 16+
11.30 «Код доступа» 12+
12.20 «Легенды армии». С. Борзенко 12+
13.15 «УЧАСТОК ЛЕЙТЕНАНТА КАЧУРЫ». «Черная паутина». 1-я – 4-я серии 16+
18.00 Главное с Ольгой Беловой 16+
19.45 «Легенды советского сыска. Годы войны». Док. сериал 16+
21.25, 04.50 «Москва – фронту» 16+
22.00 «Кочевники». Док. фильм 12+
23.00 «Фетисов». Ток-шоу 12+
23.45 «СТРЕЛЫ РОБИН ГУДА» 12+
01.10 «КЛАССНЫЕ ИГРЫ» 16+
03.00 «МАТРОС ЧИЖИК» 6+
04.25 «Россия и Китай. «Путь через века». Док. фильм 12+

РАДИО РОССИИ

«ТАТАРСТАН» РАДИОСЫ НИЛӘР СӨЙЛИ?

Казан – FM 99,2 МГц
Чаллы – FM 92,01 МГц
Түбән Кама – FM 101,1 МГц

radiotatarstana.ru

Дүшәмбе, 19 июнь

6.00-8.00 «Яңа көн». Вакыйгалар панорамасы. Новости России и Татарстана
6.25 «Музыкаль мизгелләр».
6.45 «Актуаль әңгәмә»
6.50, 7.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
7.00 Вести радио России
7.10 Туры элемтә
8.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-18.10, 19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10 Айдар Хәлим. «Өч аяклы ат». Моноспектакль. 1–2 өлешләр
13.10 «Татарстан дулкынында»
18.10 Яңалыклар
18.25 «Сердәшханә»
18.35 «Җыр – минем гомерлек юлдашым»

Сишәмбе, 20 июнь

6.00-8.00 «Новый день». Новости России и Татарстана
6.25 «Музыкаль мизгелләр»
6.45 «Актуальное интервью»
6.50, 7.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
7.10 Прямой эфир
8.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-18.10, 19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10, 18.10 Яңалыклар. Новости
11.20 «Күркәм эшләр эзеннән»
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.20 «Фидакарьләр» проекты. 20 нче тапшыру
18.25 Нур Әхмәдиев шигырьләренә җырлар

Чәршәмбе, 21 июнь

6.00-8.00 «Яңа көн». Вакыйгалар панорамасы. Новости России и Татарстана
6.25 «Музыкаль мизгелләр»
6.45 «Юллар чатында»
6.50, 7.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
7.00 Вести радио России
7.10 Туры элемтә
8.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-18.10, 19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10, 18.10 Яңалыклар. Новости
11.20 «Актуальное интервью»
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.20 «Яшьлек аланы»
18.25 Композитор Заһид Хәбибуллин әсәрләре

Пәнҗешәмбе, 22 июнь

6.00-8.00 «Новый день». Панорама событий. Новости России и Татарстана
6.25 «Музыкаль мизгелләр»
6.45 «Перекресток»
6.50, 7.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
7.00 Вести радио России
7.10 Прямой эфир
8.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-18.10, 19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10, 18.10 Яңалыклар. Новости
11.20 Татарстан: национальные проекты
13.10 «На волне Татарстана»
15.20 «Офыклар»
18.25 «Утлы еллар җырлары». Концерт

Җомга, 23 июнь

6.00-8.00 «Иртәнге нур». Новости России и Татарстана
6.25 «Музыкаль мизгелләр». (Луиза Хәйретдинова җырлары)
6.50, 7.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
7.00-7.10 Вести радио России
7.10 Туры элемтә
8.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-18.10, 19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10, 18.10 Яңалыклар. Новости
11.20 Радиокомпозиция «Сабантуй» по поэме Рената Хариса
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.20 «Фидакарьләр» проекты
18.25 «Газиз тавышлар». Наил Әюпов язмалары

Шимбә, 24 июнь

8.10 «Яңгыр җиле булып кагылдың да...» Әдәби-музыкаль композиция
9.00-10.10, 11.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00 Трансляция радио России
10.10 «Язучылар – балаларга»
10.30 «7 көн». Атналык күзәтү
10.55, 13.55 Реклама, прогноз погоды, программа передач
11.10 «Мин әтине өйрәтәм». Радиосериал
11.25 Татар халык көйләре
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.10 «Шигърият». Кадыйр Сибгатуллин шигырьләре

Якшәмбе, 25 июнь

8.10-9.00 «Между Волгой и Уралом».
9.00-10.10, 11.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-16.10, 17.00 Трансляция радио России
10.10 «Көмеш кыңгырау»
10.30 «7 дней». Обзор событий недели
10.55, 13.55 Реклама, прогноз погоды, программа передач
11.10 Ял концерты
13.10 «Татарстан дулкынында». Рафис Корбан. «Тәүбә көне». Радиофильм премьерасы. 1 өлеш
15.10, 16.10 Рафис Корбан. «Тәүбә көне». Радиофильм премьерасы. 2–3 нче өлешләр

РЕКЛАМА БҮЛЕГЕ
(843) 222-09-65,
222-09-70.
E-mail: vtreklama@mail.ru

Сәрия МИФТАХОВА

ГОМЕРЛЕК БЕРЛЕК

Тәтеш

Ике әби, бер бабай. Кайчандыр, бергәлектә – көч, дип яшәгән Берлек авылының халкы әнә шуның кадәр – өч бөртек бүген. Авылның токтасы шулар. Беткән авыл үзенең йөз яшьлек сәгатен суга алырмы – анысы билгесез. Ә иске кибетенең диварына эленгән язу әле дә тора: «Туган авылым, мин сиңа тагын кайтам әле».

Илдар Мөхәммәтҗанов

Авылның токтасы – 77 яшьлек Минзифа апа Сабитова, 94 яшьлек Фәһим бабай Фәйзуллов, 85 яшьлек Галия әби Сабитова (сулдан уңга).

Тәтеш районының Жуково җирлегенә кергән Берлек авылы моннан биш ел элек 80 еллыгын билгеләп үткән. Бөтен эшне өмә ясап, бергәләп башкарганга күрә, авылга Берлек дип исем кушканнар. Авылы бар да, кешесе генә калмаган шул. Хәзерге вакытта өлкәннәрнең иң яше Минзифа апа Сабитовага – 77, Галия әби Сабитовага – 85 яшь. Фамилияләре бер, әмма алар туганнар түгел. Берсе урамның – бер, икенчесе бөтенләй икенче башында ук яши. Аралары ерак. Галия әби сөйләшергә сусаганда, ике таякка таянып, чокырлы-чакырлы, бормалы сукмаклар буйлап, ахирәте янына хәл белешергә килгәли. Минзифа апа да әбекәйне онытып бетерми. Әле тагын 94 яшьлек Фәһим бабай Фәйзуллов бар. Аның турында райондашлары: «Өздереп гармунда уйный, борынгы җырларны җырлый», – дигәч, аны күрмичә китмәдек.

Авылны эзләп табу кыен булмады. Жуководан ерак түгел ул. Йортларның кайсында кеше торуын гына чамалау кыенрак. Капкаларга йозак эленгән. Авыл башында яшәүче Минзифа апа ишеген ачмаса, без чуалган сукмаклардан кирәкле адресларны тапмыйча, кире борылыр идек. Урман эчендә кеше таба торганмыни?! Күңелегездә гел шулай ышаныч булсын, Минзифа апа!

«Гарифулла бабай дөрес әйткән»

Минзифа апа – күрше Кызыл Тархан авылы кызы. 59 ел элек килен булып килгәндә, Берлектә 44 йорт булган. Өйләргә газ кертелгән, су бар. Авыл уртасында Вәгыйз бабай ясап калдырган кое да исән әле. Суын алырга кеше генә юк.

– Элек башлангыч мәктәп бар иде. Күптән ябылды ул. Безнең балаларга эләкмәде. Жуковога барып укыдылар. Фермасы да булган. Тик мин килгәндә, юк иде инде. Күрше авыл медпунктында санитарка булып эшләдем. Кибетнең бүрәнәләренә кара иңеп бетсә дә, җил дә, давыл да куптара алмый. Бүрәнәләре бик нык. Автокибет килми. Кирәк-яракны балаларыбыз китерә. Улым, кызым бар. Алар үзләре дә алтмышка таба бара инде. Кемнекедер җиденче дистәне ваклый. Кышын юл ябылмый, шөкер. Авыл җирлеге трактор белән ачып тора. Тормыш зарланырлык түгел. Яшим дигән кешегә мөмкинлек бар, – ди Минзифа апа, ялгыз тормышына юаныч табарга тырышып.

Ире үлгәнгә 12 ел икән инде. Минзифа апаны кызы Әлмәткә дә алып китеп караган, әмма торган җирен сагынып кире кайткан ул. Авылда яшәгән Гөлҗиһан апасы да вафат икән инде. Бертуганнары белән аралаша. Тарханда яшәүче апасы да хәл белешергә килә. Балалары кайчак дүртәр көн кунып китә икән.

– Ничек күңелсез булсын ди инде? Телевизор карыйм. Интернет белән дус түгел мин. Кышын кар көрим. Үрдәкләр янында мәш килеп, көннең үткәнен сизми дә калам, җитми дә әле ул. Моңа кадәр сыерын, сарыгын асрадык. Әнә хәзер урам тулы печән, беркемгә дә кирәкми. Әрәм булып ята, – дип сөйли Минзифа апа. – Үз йортымны ташлап китәсе килми. Китсәң, кубарып бетерәчәкләр. Хәләл көч түгелгән бит. Ялгыз яшәү куркытмый. Без аерым торырга иялэнгән инде. Бөтен нәрсә – Аллаһ кулында. Язмышлар да шулай. Намаз укып, ил-көнгә тынычлык теләп яшим. Туксаннан узган Гарифулла бабай: «Слушай, Минзифа, син бу авылда берүзең яшәп каласың әле», – дип еш әйтә иде. Ул вакытта иң яше булгач, бу сүзгә әллә ни игътибар итмәдем. Дөрес әйткән бит Гарифулла бабай!

Җыр булсын күңелдә!

Фәһим бабайның битенә язмыш тирән буразналар сызса да, күңеле егетләрнекедәй җилкенеп тора әле. Килештереп, сөйкемле итеп елмаеп куя. Хет шунда көн буе гармун тартып, моңланганын тыңлап утыр. Әйдәгез, бер күрешеп, рәхәтләнеп сөйләшегез әле дип, өч ахирәтне бер капка төбенә җыйдык. «Тукта, чәчемне тарыйм», «күлмәк якасын рәтләп куйыйм әле», «әллә өс-башны алыштырыйммы?» дип бераз көязләнеп тә алмакчы иде үзләре.

Ике ел элек август аенда Фәһим бабайның өе янган. Әле ярый янында кызы Җәүһәриясе булган. Кара кисәүләр һаман да җирдә аунап ята әле. Йорт бүрәнәләрендә дә – янгын эзләре.

– Бакчага алмага чыгып барышым иде. Пирог пешерергә иде исәп. Карасам, сарайдан төтен күтәрелә. «Эти, янабыз», – мин әйтәм... Электр чыбыгы төзек булмаган. Аннан өйгә күчте. Түбәсе, бүрәнәләре янды. Җәен яшәп була. Өй салырга кешедән ярдәм сорамадык. Этине кыш чыгарга үзем белән алып китәм, – ди туган авылына кунакка кайткан Җәүһәрия апа.

Без килгәндә, Җәүһәрия апа бакчада, мәш килеп, чүп утый иде. Яшелчә, җиләк-җимешен, бәрәңгесен утыртканнар. Көзен бакча нигъмәтләрен җыйгач, шәһәргә китәчәкләр.

Фәһим бабайның хатыны үлгәнгә – 11 ел. Ике малае, бер кызы бар. Шәһәргә киткәч, авылын бик сагына икән.

– Көч тә, сәламәтлек тә бар әле. Колакка гына катырак мин. Авылда яшәргә була, монда рәхәт. Чалгы тотып печәнен дә чабам. Үрдәкләр дә карашам. Аларга ашарга пешерәм. Әмма сөйләшергә кеше юк. Үлеп ятсаң да, белүче булмас. Шуңа күрә кызымда яшим, – ди Фәһим бабай. – Авылның киләчәге юк. Беткән бит инде ул. Монда кайтучы юк. Балалар елга бер мәртәбә зиратка кайтып, җыештырып китә. Әгәр колхозны берләштермәсәләр, авыл гөрләп торыр иде. Колхозның 300 гектар җире, 84 баш аты бар иде. Ферма беткәч, халык эшсез калды да шуннан шәһәргә китеп бетте инде. Менә хәзер өч кеше калдык. Гомер буе шушы җиргә тугрылык сакладык. Без үскәндә, эштән башканы белмәдек. Колхозда төрлесен башкардым, соңгы 24 елда складта эшләдем. Йөреп, кыштырдап торам әле, Аллаһка шөкер. Нәрсә бар, шуны ашадык. Биргән гомернең бәрәкәте булсын.

Авыл сукмакларыннан атлыйбыз. «Монда олы абый яшәгән иде. Балалары Чаллыга алып китте, йорты бетте инде... Әтинең энесе әнә тегендә тора иде. Тугыз баладан җидебез үстек. Өчебез исән әле. Бер сеңлем – Тольяттида, энем Ханты-Мансида яши. Алар белән телефон аша аралашып торабыз», – ди бабай, чирәм каплаган буш нигезләргә төртеп күрсәтеп. Хәзер менә «шулай иде» дип сөйләргә генә калган.

Капка төбендә...

Бергәләшеп Галия әбигә киттек. Җәйләрен авылда еланнар да очрый икән. Шуңа күрә табигатенә сокланып, дөньяңны онытып йөреп булмый. Сазлыгы да өлкәннәр аягы өчен түгел. Шуңа күрә сак кына йөрергә кирәк.

Без килгәндә, Галия апа аптырап утыра иде. «Чәчемне юып, тарак белән кыстырып куйган идем, шуны һич сүтә алмыйм. Әле ярый килгәнсез, кызым», – дип ишекне ачуыбызга бик куанды ул. Чәчен дә сүттек, тормыш сәхифәләрен дә. Минзифа әби чәчен үреп куйгач, киттек капка төбенә гәрләшергә. Әбекәй 85тә булса, таякка таянып йөрсә дә, чәчәкләр үстерә. Шуларны сыйпап, иснәп тә ала.

– Бу авылга урмандагы «18 нче кордон»нан килен булып килгән идем. Хәзер бетте инде ул. Үзебезнең авыл да урман кебек хәзер. Картым сигез ел элек үлде. Балалар кайтып тора. Колхозда да эшләдем, кибетче, агент та булып карадым, – дип елмайды зәңгәр күзле әбекәй.

Капка төбендә өч ахирәт үз тормышлары турында гәп корды, үткәннәрне искә төшерде. Әле ярый килгәнбез, өчесен бергә җыеп, күңелле минутлар бүләк иттек бит. Аларга хәзер рухи азыктан башкасы кирәкми.

Җәйләре үрдәк асрап уза.

ВИДЕО VATANTAT.RU САЙТЫНДА

ГАЛӘМГӘ ИЛТҮЧЕ БАСКЫЧ

«ВТ» ЖУРНАЛИСТЫ ЮРИЙ ГАГАРИН ИСЕМЕНДӘГЕ КОСМОНАВТЛАР ӘЗЕРЛӘҮ ҮЗӘГЕНДӘ БУЛЫП КАЙТТЫ

Татарстанда эшләп килүче «Җиһангирлар» инициатив төркеме җитәкчесе Хәлил Гайнетдинов көннәрдән беркөнне космонавтлар яши һәм эшли торган Звездный шәһәрчегенә сәяхәт оештырды. Дөресе дә шулай инде: галәм дип күкләргә ашкынып яши белгәч, кеше күзенә күрсәтерлек эшләрең дә булгач, космонавтлар, андагы белгечләр белән дә аралашып, тәҗрибә уртаклашып яшәүгә ни җитә!

ЦПК, матбугат үзәге

Россия Герое, космонавтлар отряды командиры Олег Кононенко белән.

Татарлар килгән!

Без үзебезгә бу кадәр җылы мөгамәлә, игътибар булыр дип уйламаган да идек. Соңрак мондый мөнәсәбәтнең сәбәпләрен үземчә ачыклап, күңелемә салып куйдым. Беренчедән, Россия җитәкчелегенең илкүләм космик программаларга карашы уңай якка кискен үзгәрде; икенчедән, космонавтларны әзерли торган данлыклы Үзәк җәмәгатьчелек белән даими эш алып бара; өченчедән, шушы Үзәктә фәнни хезмәткәр Айрат Бикмучев, Сергей Королев исемендәге «РКК «Энергия» җәмгыятендә дөньяга танылган белгеч Рафаил Мортазин кебек милләттәшләребез эшли. Егетләребезнең эш-гамәлләре турында космонавтлар да, белгечләр дә горурланып сөйләделәр. Дүртенчедән, балаларга галәм серләрен өйрәтүче «Җиһангирлар» төркеме Россиядә беренчеләрдән булып оештырылды һәм матур гына нәтиҗәләргә ирешеп килә.

Алдан сөйләшкәнчә, әмма шулай булуга да карамастан, Үзәктә эшләүчеләрне дә гаҗәпләндереп, безнең белән очрашырга Россия Герое, космонавтлар отряды командиры Олег Кононенко үзе теләк белдереп килде. «Космос өлкәсендә балалар белән эшләвегезне белгәч, бик сөендем. Димәк, сез киләчәкне күздә тотып эшлисез. Андый кешеләр хөрмәткә лаек», – дип рәхмәтләрен белдерде.

Әйтергә кирәк, сәяхәтебез бик уңышлы килеп чыкты. Гел җай туры килеп торганга, хәтта Үзәкнең баш белгече, экскурсоводыбыз Мария Арбузова да шаккатты. Эш шунда: сәяхәт вакытында юлыбызга гел легендар шәхесләр очрап торды (дөрес, соңыннан ачыклаганча, алар белән очрашуны да оештыручылар алдан сөйләшеп куйган булып чыкты). Безгә өч тапкыр космик очыш ясаган, «Вызов» фильмын төшерүчеләрне җиһандагы халыкара космик станциягә алып менүче легендар космонавт Антон Шкаплеров, Россия Герое Салиҗан Шәрипов белән озаклап сөйләшергә, сорауларга җаваплар алырга мөмкинлек туды. Бу җәһәттән Мария да шаяртту катыш: «Моңа кадәр Шкаплеровның биш минуттан артык сөйләшкәнен күргәнем юк иде. Сезне бигрәк тә яратып җибәрде», – дип әйтеп куйды. Юрий Гагаринны йөрткән шофер Исфат Миңнеҗанов, үзәк хезмәткәре Юрий Байков белән дә рәхәтләнеп аралаштык. Экскурсияләр барышында танылган белгечләр, идарә җитәкчеләре Владимир Киршанов, Андрей Курицын белән дә очраштык. Ни гаҗәп, аларның барысы да Татарстаннан делегация килүен ишеткән. Һәрберсе, яныбызга килеп, хәлебезне белешеп, аралашып китүне кирәк дип тапты. Гомумән, Йолдызлы шәһәр бөтенләй башка дөнья кебек ул. Андагы геройлар аеруча гади, аеруча ихлас. Үзара мөнәсәбәтләр сокланырлык. Башка сыймаслык зур эшләр эшләнсә дә, һәр җирдә тынычлык, сабырлык хакимлек итә. Баштарак бу халәт хәтта гайре табигый кебек тоелган иде. Аннан, безгә дә артык ашыгып, сабырсызланып яшәмәскә кирәк, ахры, дигән уй биләп алды.

Йолдызлы шәһәр

Ракетаның акрын гына күккә күтәрелүен күзәткәндә, без гадәттә космонавтлар белән горурланабыз, аларның батырлыгына, сәламәтлегенә сокланабыз. Әмма теләсә кайсы очышның җирдән башланганын күп вакытта уйлап та карамыйбыз. Йолдызлы шәһәрчеккә сәяхәт безгә бу хезмәтнең нинди катлаулы һәм авыр икәнен аңларга ярдәм итте. Боларны белеп тору космонавт булырга хыялланган балаларга, яшьләргә дә комачауламас дип уйлыйм.

Йолдызлы шәһәрчек Мәскәү өлкәсендәге Щелково районында урнашкан. Анда 6700 тирәсе кеше яши. (Шушы урында Фәрит Әюпов, безнең Чувашиядәге Шыгырдан авылы кебек икән, дип әйтеп куйды.) 1960 елның 11 гыйнварында монда Сергей Павлович Королёв инициативасы белән Космонавтларны әзерләү үзәге төзелә башлый. Илебездәге барлык космонавтлар да галәмгә очарга шушында әзерләнә. Өлешчә чит илнекеләр дә әзерлек үтә, чөнки күп кенә сынау җиһазлары бары тик шушы үзәктә генә бар. Контроль пункт аша шәһәрчек биләмәсенә кергәч, безне саф һава, чиста, киң урамнар, төзек юллар, яшеллек каршы алды. Урамда светофорлар юк, машиналар аз йөри, шуңа күрә җәяүлеләргә тулы ирек бирелгән. Үз мәктәбе, балалар бакчасы бар.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

Ниләр күрдек, ниләр белдек?

«СОЮЗ». Башта без «Союз» корабльләренең тулы размерлы макетлары урнаштырылган залга кердек. Корабльгә менә торган баскычны, беренче космонавтка хөрмәт йөзеннән, «Гагарин баскычы» дип йөртәләр икән. Кайчандыр Юрий Гагарин анда аяк киемен салып, «Восток» космик кораблена менгән. Шул гадәт әле дә саклана. «Союз» корабльләре 1960 елда СССРда җитештерелә башлый һәм алар, Айны әйләнеп, Җиргә төшәргә тәгаенләнә. Белгәнебезчә, 1967 елда беренче «Союз»ның очуы фаҗига белән тәмамланды. Ул вакытта очучы-космонавт Владимир Комаров һәлак булды. Аннан соң ул, әлбәттә инде, камилләштерелә һәм хәзерге көнгә кадәр иң куркынычсыз космик корабль булып санала. Организмга артык йөкләнеш булмасын өчен, очкан вакытта космонавтлар эмбрион формасында ята. «Физик яктан нык булмаган кешегә бу бик авыр. Шуңа күрә хатын-кызларга үзләрен сынап карамаска киңәш итәбез», – дигәч, гүзәл затлар арасында тәвәккәлләүче кеше күренмәде. Хәлил белән Фәрит, санаулы секундларга булса да, «космонавт булып караудан» баш тарта алмадылар, әлбәттә. Эченә кереп, көчкә-көчкә сыеп дип әйтик, эмбрион формасында ятып карадылар. Сынауны уңышлы үттеләр. Ә космонавтлар исә бу тренажерларда корабльнең җирдән китеп станциягә тоташкан вакытына кадәр бөтен идарә итү процессын имитацияләләр.

ЦЕНТРИФУГА. Булачак космонавтлар узарга тиеш төп сынауларның берсе – центрифуга. Кеше үзеннән таләп ителгән йөкләнешне күтәрә аламы? Старт һәм җиргә төшү вакытында бу бигрәк тә мөһим икән. Мария безне: «Бу этап иң катлаулысы. Нәкъ менә шушы сынауны үтә алмыйча, бик күпләр космонавт булудан мәхрүм кала да инде. Аның тизлеге кеше башына сыя алмаслык – минутына 70 әйләнеш. Әзерлексез кеше шундук аңын җуярга мөмкин. Конструкциянең авырлыгы – 305 тонна», – дип таныштырды. Үзәктәге ЦФ-18 бердәнбер һәм дөньяда иң зур аппарат булып санала икән. Бу монументаль конструкцияне җитештерергә 1970 елда швед фирмасы алына. Моның өчен 10 ел вакыт сарыф ителә. Нәтиҗәдә 18 метрлы рычаг белән динамик тренажер пәйда була. Центрифуга шундый зур тизлектә әйләнү белән бергә, космонавтлар утырган кабинаны да аермалы яссылыкта әйләндерергә мөмкин.

ТЕРМОКАМЕРА. Атмосфераның тыгыз катламнарына кергәндә, Җиргә төшә торган аппарат меңнәрчә градуска кадәр кыза. Шуңа күрә да скафандрлар терморегуляцияләү системасы белән тәэмин ителгән. Тегеяки бу сәбәпләр аркасында кинәт кенә әлеге система сафтан чыкса, космонавтлар югары температураны үз җилкәсендә татырга әзер булырга тиешләр. Моның өчен термокамераларда сынау узалар. Аларны бер сәгатькә температурасы 100 градус, дымлылыгы 50 процент булган мунчага кертәләр. Чагыштыру өчен, мәсәлән, 110 градуслы мунчада 17 минут утыру бүген рекорд санала.

ИСӘН КАЛУГА СЫНАУ. «Галәмнән төшүче аппарат гадәттә план буенча хәрәкәт итә. Әмма кечкенә генә төгәлсезлек тә аны юлдан яздырырга мөмкин», – дип аңлаттылар безгә белгечләр. Кечкенә генә дигәннәре корабльне меңнәрчә километрга читкә җибәрергә мөмкин икән. Шуңа күрә аппарат теләсә нинди урынга – җиргә, суга, чүлгә, тайгага да төшәргә мөмкин. Мондый очраклар өчен космонавтлар үзләре белән «авария запасы» йөртә. Ул махсус капсулада саклана. Анда фонарь, аптечка, төтен ракетасы, рация, акулаларны куркыту өчен сыбызгы, агач кисү өчен титаннан эшләнгән пычкы бар. «Элек бу комплектта пистолет та булган. Бәлки сез Леонов белән Беляев тайгага төшкәннән соң булган хәлләрне хәтерлисездер әле. Аларның пистолеты бар иде. 2000 елда бу коралны мачетега (озын, киң, бик юка пычак-балта) алыштырдылар», – дип аңлатма бирде озата йөрүчебез. Мондый шартларга әзерләү өчен космонавтларны шушы запаслар белән елына бер тапкыр тайга, чүл яки океанга төшерәләр икән. Менә шушындый шартларда булачак космонавтлар 10–15әр ел галәмгә очарга әзерләнәләр. Ә бәхет, әйтергә кирәк, бик азларга гына елмая. «Отрядка алынганда комиссияне үткән кандидатлар да, тренажерларда шөгыльләнә-шөгыльләнә, сәламәтлеген югалтырга мөмкин. Төшенкелеккә бирелүләрдер дисезме? Әлбәттә, стресс. Әмма көчле кешеләр буларак, алар бу хисне дә җиңәргә өйрәнәләр. Үзәктә эшләүче белгечләрнең күбесе – кайчандыр я космонавтлар отрядына керергә әзерләнгән, я, сәламәтлеге какшау сәбәпле, бераздан төшеп калган кешеләр. Әзерләнү вакыты да организмның мөмкинлекләренә карый», – диде Мария. Бу җәһәттән Рафаил Мортазин да үз тарихын сөйләп алды. «Мин үзем дә космонавтлар отрядына язылган идем. Бердәнбер көнне медицина комиссиясен үтә алмадым. Шул мизгелдә моның нинди кайгы икәнлеген сөйләп тә, аңлатып та бетерә торган түгел. Әмма безне теләсә нинди вазгыятьтә көчле рухлы булырга өйрәтәләр. Сынмаска, сыгылмаска шул ярдәм итә», – диде ул.

«САБЫЙЛАР ЯТИМ ҮСМӘСЕН»

Гарифуллиннарның шәхси архивыннан

Лаеш районының Усад авылында гомер итүче 68 яшьлек Эльфира Гарифуллина ятим балаларга әни булган. Үзен дә сабый чакта әнисе ташлаган. Алып үстергән әтисе белән әнисе аңа бу хакта сиздермәгән. Туганнар да, дуслар да, бергә укыган укучылар да, авыл кешеләре дә ник бер сүз әйтсен! 2 яшендә кызлыкка алынган бала икәнен Эльфира апа еллар узгач кына белә.

– Миңа кем тудырганын белү кирәк тә булмады, – ди ул. – Әти белән әнием миңа җил-давыл тидермәде. Ятимнәр йортыннан алынган энем дә бар иде әле минем. Хәзер ул вафат инде. Без аның белән бик рәхәттә, бәхеттә яшәдек. Әниемнең кулы алтын иде. Нәрсәгә тотынса, шуны эшләп куя. Ризыкка, киемгә кытлык вакыт булса да, әти безне авыр яшәтмәде. Әти дәрәҗәле булды. Ул кирәк әйберне табып торды. Кая инде ятимлекне сизү!

Кадердә үскән иркә кызга кияүгә чыгарга вакыт җитә. Иртә чыкмый ул. Кулына диплом алгач та, ике ел эшли әле. Ә аннары Кәмәрҗан исемле егет белән гаилә корып җибәрә. Башта алар Үзбәкстанга китеп яшиләр. Шунда кызлары Эльмира туа. Тормышлары никадәр көйле булса да, яшьләр туган якка тартыла. Әлки районының Түбән Әлки авылына кайтып төпләнәләр. Бәхетләрен тулыландырып икенче кызлары дөньяга килә.

– Монда кайткач, ирем авырый башлады. Уң аягына зарлана иде ул. Табибларга йөри башлады. 30 яше тулган чак. Шул вакытта аның сеңлесе дә авырып китте. Яман чир иде анда. Үзен хастаханәгә салганнар, улын ятимнәр йортына җибәргәннәр иде. Башта безгә сиздермәделәр. Белгәч, ирем белән киңәштем дә, үзебезгә алып кайтырга карар кылдык. Иваново өлкәсендәге балалар йортыннан барып алдык без аны. Шамил безгә кайтканда 10 яшьтә иде. Олы кызым белән бер елгы. Икәү бергә укыдылар. Алар бертуган булып үсте, – ди Эльфира апа. – Тик, кызганыч, Шамилнең әнисен коткара алмадылар. Ул үлеп китте. Аның артыннан иремнең сәламәтлеге нык какшады. Кул-аяклары әкренләп эшләүдән туктады. Урынга ук калды. Ул ел буе авырды. 46 яшендә мәңгелеккә күзләрен йомды. Мин бу вакытта мәктәптә директор булып эшли идем.

Менә шул вакытта Түбән Әлки авылында тәрбиягә алынган өч баланы кире ятимнәр йортына илтәләр. Бу сабыйлар инде мәктәптә үз кешегә әйләнгән булалар.

– Без бу балаларны шулкадәр яраткан идек. Мин тәвәккәлләдем. Өч туганның иң олысын – Гөлнурны үземә алып кайттым. Айрат белән Руслан ятимнәр йортында яшәп калды. Йөрәк өзгәләнә генә бит. Шулай итеп, 6 ай вакыт узып та китте. Яңа ел алдыннан өйгә кайтып керсәм, ишек төбендә капчык-капчык нәрсәләрдер ята. Әллә ничә сумка да бар. Аптырап, кызым Гөлнурга карыйм. Ул исә: «Әни, Яңа ел күчтәнәче китерделәр», – ди. Ныклап карасам, Гөлнурның энеләрен китереп киткәннәр икән, – ди ул. – Сөендем генә! Мин ул балаларны якын итәм, холыкларын да белә идем инде. Өчесенә дә «әни» дип әйтә күрмәгез, дип әйтеп куйдым. Бер әниегез ташлаган, икенчесе кире илткән, өченчесе була алмыйм, Эльфира Харисовна диярсез, дидем. Сабыйлар кочагыма сарылды. Бик яратып үстердем. Алардан да үземә карата җылы мөнәсәбәт тоям.

Бик тыңлаучан була балалар. Яхшы укыйлар. Авырлык китермиләр. Әмма тәрбиягә өч бала алгач, Эльфира Харисовнага эшеннән китәргә туры килә. Уллары Айрат белән Руслан әйтмешли, алар хакына Эльфира Харисовна туганнарына кунакка баруны да, сәламәтлеген кайгыртуны да оныта.

– Бу йортка килеп, без өйле дә, яратулы да, гаиләле дә булдык. Тормышның башка матур якларын күрдек. Без Эльфира Харисовнага «әни» дип әйткән булыр идек. Йөрәккә авыр булмасын өчен, үзе әйттермәде. «Әни кеше бер генә була ул», – дип әйтә иде. Әмма без аннан да якын кешене тапмадык. Аның зур йөрәгендә һәрберебезгә урын бар. Ул безне аерып тормады. Кирәк чакта ачуланды, кирәк чакта яратты. Бөтен эшкә өйрәтеп үстерде, – ди улы Айрат.

Әтиле һәм әниле була торып, наз-яратуны читтән эзләп тап инде! Бу урында, өч баланың әнисе нинди йөрәк белән яшәгәндер, диясе килә. Әмма Эльфира апа аның турында бер генә начар сүз дә әйтми. Бөтен кешене аклый ул. Ташлаган әниләренең ире кул күтәргән, ул шуннан туеп, балаларын ташлап чыгып киткән, ди. Ул хатынның 7 баласы булган икән әле. Тәрбиягә алып, кире илтүчеләрне дә аңлыйм, ди. Баксаң, бу гаиләдә әни кеше авырып киткәнгә сабыйлар кире ятимнәр йортына кайтарылган икән. Аның каравы үзенең бәхетенә булган бу сабыйлар.

– Балаларым минем өчен өзелеп тора. Гөлнурым белән киявебез икенче бәбиләрен көтә. «Берәр атнага синең янга киләм», – ди әле. Үзем дә яратып көтеп торам. Айратым өйләнде. Хатыны Алия белән Казанда яшиләр, ике ул үстерәләр. Русланым өйләнмәгән әле. Ул – хәрби, – ди Эльфира ханым. – Улым махсус хәрби операциядә катнаша. Әлегә ялга кайтты, янымда тора. Газета аша күптәннән күңелемдә йөрткән рәхмәтемне җиткерим әле. Руслан миңа хәрби киемнәр алырга ярдәм итүче булмасмы икән дип хәбәр биргән иде. Мин бу хакта Әлки районында яшәүче Дамир Шәйхетдиновка җиткердем. Берсүзсез 25 мең сум акча бирде. Улыма кирәк-яраклар алдык. Үзем дә куштым. Шуннан соң Руслан, Эльфира Харисовна, мондагы егетләргә дә ярдәм кирәк, диде. «Ватсап» төркеменә шул хакта язып җибәрдем. Бер атна эчендә 150 мең сум акча җыелды. Барлык мәрхәмәтле кешеләр алдында башымны иям.

Алгансың икән, үзеңнеке итеп яратырга кирәк! Эльфира апа кебек. Ул алты баласына да назын тигез биргән. Кайтуларын көтеп тора. «Өчәү иделәр, тугыз булдылар», – дип сөенә. Оныклары да әбиләрен якын күрә.

– Балаларымның үз әниләре дә, сабыйлар яхшы кешегә эләккән, дип шатлана икән. Аларны үстерүемне батырлыкка санамыйм. Тормыш үз көенә барды да барды инде ул. Язмыштан узып булмый. Бер дә үкенмәдем. Киресенчә, мин бик бәхетле гомер юлын үтәм. Шушы яшемдә үз аякларымда йөреп торам икән, бу балалар тәрбияләүнең әҗере инде. Аллаһы Тәгалә мине шулай итеп бүләкли, – ди Эльфира апа. – Һәр балам өчен сөенәм. Алар борчылса, миңа читен. Балаларым белем алды, эшлиләр. Русланыма изге теләктә торам. Исән генә йөрсен! Ул үзе берни сөйләми. Мине борчырга теләми. Әмма мин барыбер сизәм. Язмышына озын гомер, ныклы сәламәтлек язылсын иде. Һәр балама бәхет телим. Үз сабыйлары ятим үсмәсен!

ИРЕК МОСТАФИН: *«Миллионынчы булганымны соң белдем»*

Ш.Байгильдинов

Эш тартмасында актарынам. Күп еллар буе җыелган фотоларны архивка тапшырганчы, тагын бер кат карап чыгарга булдым. Кулыма «Казанның миллионынчы баласы туган көн» дип язылган фото килеп керде. 1979 ел, октябрь диелгән. Ул кешенең кем икәнен интернет шундук әйтте. Ә менә үзен табар өчен шактый тырышырга туры килде. Социаль челтәрләрнең берсендә 1979 елда туган Ирек Мостафиннарны барладым. Һәркайсына хат язып чыктым.

Моннан 43 ел элек Ирек Мостафин Казанда миллионынчы бала булып теркәлә. Ул тугач, ТАССР башкаласы РСФСРда – унынчы һәм СССРда егерменче миллионлы шәһәр була.

Ирек катнаш гаиләдә туа. Әнисе Надежда Михайловна тегүче булып эшли, әтисе Шамил Җәмил улы машина йөртүче була. Ирек Мостафин туып, ярты ай узгач, аларның гаиләсен котлап, тантаналы төстә сабыйларын миллионынчы итеп теркиләр. Шул чакта баланың әти-әнисенә туу турында таныклык, истәлек медале, ордер һәм ике бүлмәле фатир ачкычы тапшырыла.

– Мин үземнең миллионынчы булып туганымны 6 яшь тулгач кына белдем. Шушы вакытта әти белән әни аерылышты. Таныклыгымны әниемнең документлары арасыннан очраклы гына рәвештә табып алдым. Әнием белән бу темага күп тапкыр сөйләшмәкче булдым, әмма ул һәрвакыт сүзне икенчегә борды. Нигәдер әниенең кешегә билгеле буласы килмәгән, – ди Ирек. – Әти-әнием вафат инде. Миллионынчы булып тууым аларга горурлык булгандыр. Әмма миңа бу статусым берни бирмәде. Бу хакта белүчеләр һәрвакыт миңа ни биреләгәнен генә сорый. Калганы аларга кызык түгел.

Ирек үзен татар дип саный. Мәктәптә рус төркемендә укый. Аларга татар теле дәресләре керми. Әтисенең әнисе оныгы белән татарча сөйләшкәләсә дә, егет аны оныта. Әтисе белән әнисе аерылышканнан соң, татарча бөтенләй сөйләшми башлый.

– Әти ягыннан бабаларым Әлки районыннан минем. Аларның бик тә тәртипле гаилә һәм дини булганнарын беләм, – ди Ирек.

Ирек төзүче һөнәрен сайлаган. Башта училищене тәмамлый, аннан югары белем ала. Төзелеш оешмасында инженер булып эшли.

– Казан читендә өй төзедем. Шунда гомер итәм, – ди ул. – Үземне әллә кемгә санамыйм. Бер гади кеше мин. Тормышта күпне күрдем. Шактый сынаулар уздым. Әмма һәр ялгышлык миңа сабак булды. Тормышны ничек бар, шулай яратып, булганына сөенеп яшим мин хәзер.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

ӘСХӘТ ХИСМӘТ:

«ХАЛЫК ҮЗЕНЕКЕ ИТЕП КАБУЛ ИТТЕ»

Татарстанның халык артисты Әсхәт ХИСМӘТ белән бу юлы күбрәк җыр турында сөйләштек. Сәбәбе дә бар, ул – Илһам Шакиров исемендәге премия лауреаты. Күптән түгел Камал театры оркестры белән концерт куеп та, зур бәйрәм ясады. Консерваториягә алабыз дип торганда, нишләп кермәгән инде, дим кайчак. Хәер, ул вакытта «Зәңгәр шәл»дәге Булатын, «Казан сөлгесе»ндәге Ильясын, авыл эте Акбаен, «Ахырзаман»дагы Ташчәйнәрен белми калыр идек.

:: Әсхәт абый, без нинди заманда яшибез?

– Бер уйласаң, катлаулы да… рәхәт тә заман. Вазгыять җиңел түгел, дибез, шул ук вакытта бөтен җирдә – бәйрәм. Берсенә берсе ничектер туры да килеп бетми. Кешеләр дә үзгә хәзер. Һәркем үзе өчен яши, үзе өчен генә җавап бирә. Минем әти фронтовик булган, танкист. Бер килгәндә, Җиңү паркына алып бардым. Әти карап йөрде, йөрде дә: «Улым, монда минем танк юк бит», – ди. Шуннан такси алып танк училищесына киттек. Аның каршында танк тора, беләсеңдер. Күрүгә шатлыктан әтинең күзләре яшьләнде, менә монысы – минем танк, ди, шул тимерне җан ияседәй кадерләп сыпырып-сыпырып куя. Менә алар ил өчен дип яшәгән буын инде…

:: Авырлыкны җиңәргә җыр ярдәм итәме?

– Әлбәттә, ярдәм итә. Миңа гына түгел, бөтен кешегә дә ярдәм итә. Тагын әтине искә алам инде: ул чакта бит фронтка тальян да алып барганнар. Әле беркөн «Тәртип» радиосыннан Фоат Галимуллин бер хикәя укыды. Тальянның фронтовикны пулядан саклап калуы турында. Андый әсәргә юлыксам, дөньямны онытып тыңлыйм. Күңел тулса, елыйм да, җырлыйм да.

:: Менә сез һәр әңгәмәдә Илһам Шакиров репертуарын яттан беләм дип әйтәсез. Ни өчен нәкъ менә Илһам Шакиров репертуары? Рәшит Ваһапов та, Таһир Якупов, Фәхри Насретдинов та түгел.

– Таһир абый репертуарын да беләм, Рәшит абый, Фәхри абыйныкын да. Рәшит абый җырларын Илһам абый да башкарган. «Уел» дисеңме, «Фирдәвескәй», башкасы. Аларны да беләм, ләкин күңелгә нишләптер Илһам абый кереп калган. Мин аның сәбәбен төгәл генә әйтә алмыйм. Әйтәм бит, мәктәптә 42 бала арасында бер мин артист булам дип инша язганмын. Үсә төшкәч, Илһам абыйга дип Казан филармониясенә хатлар яздым. Алганмы ул аларны, укыганмы, юкмы – белмим. Беренче тапкыр ишеткәч үк күңелгә кереп калды. Аның радиодан һәр җырын отып калырга тырыша идем. Бер мисал. 1968 елны озатып, 1969 елны каршы алабыз. Без сәхнәдә өчәү: мин – алып баручы, әти – Кыш бабай, сеңелкәшем Рәмзия – Кар кызы. Төрле уеннар уйнатабыз, әти бүләкләр тарата. Бүләк тапшырыр алдыннан телефоннан Верхоянскига «шалтыратып» ала. «Шалтыратып» ала да, фәлән кеше ел буе тырышып эшләгән, Кыш бабайдан аңа бүләк бар дип, бүләк тапшыра. Яки, киресенчә, бу кеше тәртипле булмаган икән дип, шелтәләп ала. Ни өчен Верхоянскига шалтыраткан ул – менә анысын әтидән сорап калмаганмын. Бер көнне шул турыда сүз чыккач, кызым Илсөяр, Верхоянскиның иң салкын җир булуы турында мәгълүмат эзләп тапты. Якутиянең бу шәһәре – Җир шарындагы иң салкын урын, аны хәтта төньяк ярымшарның салкын полюсы дип тә йөртәләр икән. Әти, мөгаен, шуны белеп, Кыш бабай шуннан килергә тиеш дип уйлагандыр. Менә шушы кичәдә «Яңа елда – яңа җыр» дигән конкурс оештырдык. Мин «Хәтерләү» дигән җыр башкарырга дип ниятләп торам. Авторлары кем булган, ул вакытта белмим дә инде. Илһам абый да җырлады аны, Флюра апа да. Чират миңа җитә, сәхнәгә чыгам – башлап кына китеп булмый бит! Гафу итегез, дип кереп китәм, башкалар җырлый, чират тагын миңа килеп җитә. Тагын башлап китеп булмый. Өченче тапкыр чыктым да, авылдашлар, гафу итегез, бу юлы да башлап китә алмасам, ачуланмассыз, мине төшереп калдырырсыз, дидем. Шуннан ничектер җайланып, ипле генә җырлап киттем:

Кырга чыксам, җылы җилләр чәчтән сыйпап иркәли.
Кырдан искән таң җилләре синнән сәлам икән бит…

Шушы җыр белән җиңүче булдым. Радиодан ишетеп, мин беренче отып алганмын булып чыкты. Авыл уртасындагы баганага эленгән репродуктордан иртән башкорт концертын бирәләр, без мәктәпкә барганда – татарча. Ул вакытта артистлар бармак белән генә санарлык булгач, аларның барысын да беләм. Хәер, авылга артистлар килсә, безгә квартирга да керәләр иде әле. Мәсәлән, Габдулла Рәхимкулов, Усман Әлмиев, Рәшит Ваһапов, Әзәл Яһудин, Фәйзи Йосыпов дәү әтиләргә квартирга керделәр. Солянка концерт булдымы, халтурамы – анысын әйтә алмыйм инде, ул вакытта әле кечкенә. Шунда авыл клубында гадәттән тыш хәл дә булды. Башкалар җырлый тора, Усман абый билет сата тора. Сәрхуш Сәхаб абый да керергә тели икән, Усман абый кертми, билет ал, ди. Теге озак уйлап тормый, Усман абыйны баскычтан суга да төшерә. Ул аны сәхнәгә чыккач көлдереп сөйләде дә әле. Ярый имгәнмәгән инде.

:: Сезнең өчен Илһам Шакиров кем ул?

– Минем кумирым инде ул. Казанга килгәч, мин үзешчән сәнгатьтә катнаштым. Башта укытучылар клубына, аннары Төзүчеләр мәдәният сараена йөрдем. Хәзер төзүчеләр дигән сүзе онытылып, Сәйдәш мәдәният сарае дип йөртәләр. Хәлемнән килсә, Сәйдәш исемендәге төзүчеләр мәдәният сарае дип үзгәртер идем. Төзүче һөнәренә хөрмәт күрсәтү булыр иде ул. Химиклар сараеның исемен үзгәртмәделәр бит. Бусы сүз уңаеннан инде. Менә шушы Төзүчеләр мәдәният сараена йөри башлагач, таныштым мин Илһам абый белән. Төзүчеләр көнендә «Идел» инструменталь ансамбле белән безгә концерт куйды ул. Минем бик тә танышасы килә. Концерт тәмамланды, бөтен кеше чыгып бетте, инде ишекләрне бикләргә йөриләр, юк кына бит, чыкмый. Болар, мөгаен, арткы ишектән чыгып киткәннәрдер дип, инде мин дә китәргә җыенган идем, карасам, Илһам абый чыгып килә. Бөтен кыюлыгымны җыеп, каршына килеп бастым да, мин сезгә хатлар да язган идем дип, бер тында бөтен кичерешләремне сөйләп бирдем. Шуннан Илһам абый мине култыклап алды да үзенә дип әзерләнгән табынга алып кайтып китте. Менә шулай, башта Илһам абый концертына акча түләп йөри идем, аннары баянчысы Ирек абый Галимовның әти-әнисе белән һәр концертын беренче рәткә утырып бушка карый башладым. Төзелештә эшләгәндә Казанда булган бер концертын да калдырмадым. Камал театрында эшли башлагач, я спектакль туры килеп, я башка эш килеп чыгып, йөрүләр сирәгәйде. Әмма дуслык ахыргача булды.

…Ленин бакчасында ресторан бар, Нурания Җамали кичә алып бара. Менә шул кичәдә Илһам абый вафат дигән хәбәрне шалтыратып әйттеләр. Мин инде аны халыкка җиткердем дә «Хушлаштың да китеп бардың» дигән җыр башкардым. Шуннан Илһам абыйны саклап төн кундык. Аның өч энекәше бар икән, Кыям абыйның балалары. Болар чиратлашып Илһам абыйның үзләренә нинди яхшылыклар эшләвен сөйли, таң калып тыңлыйбыз. Аннары Флюр абыйсы сөйләде. Төне буе күзгә йокы кермәде. Таң атып, пакьләнеп алгач, ике мулла, Флюр абый, мин Илһам абыйны юып, кәфенлеккә төрдек.

:: Сәнгать белән тормыш алып барып буламы соң дип, үкенгән чаклар буламы, Әсхәт абый? Илһам абыйның, «мин дә, төрмәдән чыккан күршем дә бер үк төрле пенсия алабыз» дип әрнеп әйткән сүзләре бар бит.

– Үкенгән чагым булмады. Мин бит балачактан сәхнә дип хыялланган кеше. Илһам абый әйткәндер. Аның җан әрнүләренең без белгәне күпме, без белмәгәне дә шактыйдыр. Фасил Әхмәтов сөйләгән сүзләр дә искә төшә. Менә шуның язмасын табасы иде. Ул Илһам Шакировның беренче мәхәббәте турында сөйләгән иде. Менә бит нинди хәл: Фасил абый йөргән кызы Йолдыз белән өйләнешә, ә Илһам абыйның йөргән кызы хыянәт итә. Шуннан күңеле кайта.

> Мин үзем Финляндиядә яшәүче Рәхилә апа белән Илһам Шакировның очрашулары шаһиты булдым. Ул чакта Илһам абый һәм без – Камал театры артистлары – Финляндиягә гастрольгә бардык. Шунда булды бу хәл. Алар очраштылар, бер-берсенә бик озак карашып тордылар. Икесенең дә күзләреннән яшь ага. Икесе дә тавыш-тынсыз елый. Аннары Илһам абый Рәхилә апаның иңенә Оренбург мамык шәлен салды. Кичәдән соң алар бик озак сөйләшеп утырды. Менә бит нинди мәхәббәт булган, әмма кавышу насыйп булмаган. Илһам абый анда бармаган, Рәхилә апаның Россиягә кайтасы килмәгән. Икесе ике якта ялгыз гомер иттеләр. Рәхилә апа да гаилә кормады.

:: Әтиегез дә, әниегез дә – үзешчән сәнгать кешеләре. Алар да сәнгать белән тормыш алып баруның авырлыгын аңлагандыр. Һәм менә уллары Казаннан, күпмедер вакыт «рабочий» булып эшләп алганнан соң, мин артист булам, дип әйтергә кайта. Кабул иттеләрме?

– Әти кабул итте, әни генә чыгып төшеп сөенмәде. Сәнгать аның җелегенә үткәндер, күрәсең. Чөнки әти – көндез эштә, кич аны клубка алып китәләр. Бөтен чарада катнаша, бөтен спектакльдә – герой. Әни, бүген бармыйсың, дип тавыш чыгарып та карый. Завклуб безгә килеп, әнигә ялынып-ялварып, «алма абый»ларын алып китә. Шулай итеп әнигә бөтен көндәлек эш, тормыш алып бару кала. Шулай да, әни спектакльләр карарга ярата иде. «Җырны мин үзем дә җырлыйм, спектакльдән гыйбрәт алам», – дип әйтә иде. Камал театрының 7 нче рәтендә, «проход»тан соң беренче урынга утыра да китми. Аңа: «Апа, монда кеше утыра», – дип тә карыйлар. Ул: «Белмим, белмим, минем малай театрда эшли», – дип җавап бирә. Әни мировой кеше иде минем. Урыннары оҗмахта булсын иде инде… Әти бик җырлый иде. Сәхнәгә үк менгезеп булмаса да, залга төшеп, янына килеп җырлаттым мин аны. Эх, сәхнәгә үк алып менәсе калган, дип үкенәм хәзер. Терсәк якын да бит, тешләп булмый…

Блиц-сораштыру

– Тормышымның горурлыгы дип кемне яки нәрсәне атар идегез?
– Горурлыгым – балаларым. Өлкән кызларым гаиләле, аларга шатланам. Әни әйткәндәй, җырын үзем дә җырлыйм, гармунда уйнаган кешене яратам. Булатны, бер шөгыле булсын дип, музыка мәктәбенә биргән идек. Мәктәпне дә, музыка училищесын да, консерваторияне дә тәмамлады. Аның гармунда уйнавын яратам.
– Бу ир-ат эше түгел дип нәрсәне әйтер идегез?
– Гайбәт сөйләүне.
– Ә нәрсә хатын-кыз эше түгел?
– Тәмәке тарту, чалбар кию.
– Артист хатыны нинди булырга тиеш?
– Артист тормышын аңларга һәм кабул итәргә тиеш. Рәшидә апаң әнә шундый. Мин булмады әле бу, дисәм, була-була, дип үсендереп җибәрә белә. Үзе дә театр өлкәсе кешесе булгач, ул безне яхшы аңлый. Шулай да, артист хатыны булу җиңел, дип әйтмәс идем.
– Артист балаларына ниндидер таләпләр куелганмы?
– Һәр әти-әни, яхшы бул, тәртипле бул, кеше арасында безнең йөзгә кызыллык китермә, дип әйтә. Бу – таләп тә, теләк тә. Әмма артист баласы театр тирәсендә бөтерелергә тиеш. Марсель Сәлимҗанов, балаларыгызны алып килегез, аралаштырыгыз, дип әйтә иде. Ничек алмаш әзерләгән бит! Хәзер театрда әнә нинди династияләр бар.

:: Әсхәт Хисмәтнең «коронный» җырлары.
– «Хушлаштың да китеп бардың» (Фәннүр Сафин сүзләре, Риф Гатауллин көе), «Әнкәй безне Сөннән алып кайткан» (Роберт Миңнуллин сүзләре, Сара Садыйкова көе), «Бер алманы бишкә бүлеп» (Әнгам Атнабаев сүзләре, Урал Рәшитов көе), «Карачтау авылы көе» (татар халык җыры). Саный китсәң, күп алар.

:: Танылу ул тырышлык нәтиҗәсеме, әллә «юлның уңуы»мы?
– Анысы да, бусы да түгел, минем борын күтәреп йөргәнем юк. Миндә «простойлык». Шуңа күрә кая барсам да, халык үзенеке итеп кабул итә.

:: Татарстан Рәисе каршында Мәдәният һәм сәнгать советы бар. Сезне шунда чыгыш ясарга чакырдылар ди, нинди төп өч проблеманы аерып күрсәтер идегез?
– Берзаман «андыйлары да булсын, җырласыннар» дигән сүз ишетелгәч, эстрада артистлары бик нык күбәйде. Контроль ясыйк әле шушы өлкәгә, дип әйтер идем. Аннары Илбашының Әтнәнең бер юбилеенда «колхозларны таратып дөрес эшләмәдек, ахры, бераз» дип әйткән сүзләрен искә төшерер идем дә, «Аларны яңадан кайтарып булмыймы?» – дип сорар идем. Авылны кайгыртам инде мин. Авыл ашата бит барыбызны да. Өченче проблема эчү мәсьәләсе хакында булыр иде. Дәүләт контролен көчәйтеп, контрафактларга чик куярга иде, дияр идем. Путинга да шуны әйтер идем.

:: Татар эстрадасы нинди хәлдә?
– Нәрсә дип әйтим инде мин сиңа... Халык җырлары онытыла, шунысы кызганыч. Аларны аңламыйча җырлаулары икеләтә кызганыч. Беркөн Илгиз Мөхетдинов «Казак кызы сөйгәнем»не башкарды. Илһам абый аны «Көт, матур яр, килермен тургайлар белән бергә» дип җырлый. Илгиз «яр»ны «кыз»га әйләндерә. Ну нишләп алай әйләндереп җырларга инде? Алинә Шәрипҗанова – бер дигән җырчы, әмма «Гөлҗамал»ны акырып җырларга ярамый. Ул – үзәк өзгеч җыр. Яшь кызларның сөйгән ярлары 25 елга армиягә киткән, әллә кайта, әллә юк алар. Монда гарип-гораба, мулла-мунтагай калган. Шуларга көчләп кияүгә бирәләр. Шуннан зарланып җырлыйлар бит аны. Бу җәһәттән улым Булат белән дә бәхәсләшәбез инде без. Кайвакыт, әти, нота буенча шулай ул, дип әйтә ул миңа. Нотасы шулайдыр, әмма йөрәк белән җырларга кирәк җырны.

:: Татар театры ни хәлдә?
– Музыкаль әсәрләр күбрәк булсын иде. Безнең халык бик музыкаль бит ул, җырлы спектакльләрне ярата. Шул ук вакытта академия театрында классика, әйтик, «Дон Жуан» да булырга тиеш. Ул җырлы спектакльләрне, әйтик, «Галиябану»ны, «Зәңгәр шәл»не яттан белә, барыбер карыйсы килә. Аларны мөгез чыгармыйча куярга кирәк. Бер хәлне сөйлим. Режиссер Дамир Сираҗиев бездән күчмә театрга күчте дә «Галиябану»ны куярга алынды. Булган инде бу, мин әйтәм, безнең ярты тамашачы тегендә китә икән, дим. Әмма Дамир яңача куярга теләгән икән. Нәтиҗәдә – халык юк. Андый әсәрләрдә мөгез чыгарырга ярамый шул.

Әңгәмәдәш – Гөлинә ГЫЙМАДОВА

< Дәвамы. Башы 9 июнь санында

РКАИЛ ЗӘЙДУЛЛА

КАРТЫЙ

(ХИКӘЯ)

– Кемнәр, кемнәр кайтка-ан... – дип көйли-көйли, ул түргә үтте, андагы – күрәсең, аның өчен! – буш торган урындыкка килеп утырды, ике учын йөзенә китерде, шактый гына озак мыдырдаганнан соң: – Алла әкбәр! – дип бит сыпырды. Үзен гаҗәпләнеп күзәткән Амалиягә күз ташлап, торынына борылды: – Руберт улым, кызың амин да итә белми мәллә?

– Менә өйрәнергә кайтты бит инде, – дип, кызганыч елмайды торын.

– Ярар, ярар, яхшы булган, соң түгел әле. Әйдәгез, чәйгә сузылыгыз.

Амалия сизмичә дә калган – чынаякларда инде чәй тутырык, бер әби аңа бавырсак салып маташа.

– Бездә шулай эчәләр, – диде әтисе.

Сездә эчсәләр соң... Амалия иренен турсайтты, чәйгә кагылырга уйламады да. Күтәрелеп караса, «директор» әбинең күзе аңарда! Амалия ашыгып чәйгә иелде.

– Амилә кызыма бал ерак, – диде «директор», ике әби каударланып кыз каршына бал савытын шудырдылар. «Бик матур исем – Амилә», – диештеләр.

– Әле Гөлҗиан килене тапкан малайга Абдрахман дип кушып кайттым, анасы, күзен терәп, Артурмы, Амурмы дип тик тора, адәм ыстрамы. Нишләп мин үз балама үзем исем куша алмыйм, беля-асызмы, мин аны ничек авырттырып таптым, ди бит әле, миңгерәү. Тилибизыр карап азынганнар. Ничауа, тәртип урнаштырып киләм инде. – Ул торынына карап елмайды: – Миңа кадәрге мулла бик йомшак иде. Халаякка тәртип куялмады.

– Хатын-кызга мулла булырга ярыймы?

– Нишлисең инде, – дип иңен сикертте кортка, – безнең картларның җыенысыннан бер чырапычак чыкмый. Әлепне таяк дип белмиләр. Урыс арасы бит, бернишләп булмый.

– Авыр түгелме соң бу яшьтә?

– Яшемә ни булган? Аллага шөкер, яшьләргә биргесез әле мин! – Ул янәшәсендәге карчыкларга карап алды. Тегеләре аны җөпләп ияк какты. – Шушы җәйдә йөз тирәсе була, әлхәмдүлилләһи...

Ул мут кына каш сикертте.

– Бәрәкалла! – дип, карчыклар баш селкеде.

– Зур юбилей бит бу! Зурлап үткәрергә дә кирәк, – диде кунак. Блокнотына нидер язып та куйды.

– Авыр инде, авыр булмыйча соң. – Карчык торынының соравын онытмаган иде. – Тик хак юлга чыксаң, Алла ярдәм бирә ул.

Чәйдән соң әтисе китәргә җыенды.

– Ярар, кызым, сау бул, абикаларының сүзен тыңла.

– Нинди абика булыйм әле мин, – дип, Робертның әнисе ризасызлык белдерде. – Миңа «картәнәй» дисен!

– Миңа «әбекәй» дисә дә ярый, бик күркәм сүз, – диде урталыкта калган карчык.

– Әбекәй! – дип мыскыллы елмайды «мулла» әби. – Миңа Амилә «картый» дип эндәшсен! Мин үзем әбиемнең әбисенә шулай эндәшә идем. Пуняла, я – картый!

– Пуняла, – диде Амалия... юк ла, Амилә!

Картый кул аркасы белән коп-коры күзен сөртеп алды.

– И-и, – диде ул әллә нинди еламсыраган тавыш белән, – картыемны сагындым, нишләп ятадыр бер ялгызы. Ямансудыр аңа, ә?

Амалиянең әтисе, ни әйтергә дә белмичә, җилкәсен сикертте. Амалия исә үз уеннан үзе интекте: нишләп берүзе ята икән соң ул бик-бик карт картый? Кайда ята икән?

– Өстенә һәмишә таш куелмаган, – дип, тагын еламсырады кортка, – акча җиткерәлмибез һаман...

Роберт Замалиевич каударланып кесәсенә тыгылды, берничә кәгазь акчаны кыенсынып кына корткага сонды. Тегесе, кәгазьләргә күз дә төшермичә, гаять тә табигый хәрәкәт белән аларны эскәтер астына шудырды, ике кулын йөзенә китереп озак кына мыдырдады, аннары:

– Амин, кабул ит Руберт торынымның сәдакасын! – дип, тантаналы итеп бит сыпырды. – Картый риза-бәхил булып ятар, Алла теләсә.

...Әтисе китте. Амилә калды. Бернишләп тә булмый!

Иртәгесен картый аны таң белән уятты. Кызның торасы килмәде, әлбәттә. Каникулда да рәхәтләнеп йокламагач! Тибенеп тә карады, тырнарга да маташты, шулай сугыша торгач, йокысы качты.

– Йокы чүлмәге булмыйлар алай, – дип сөйләнде картый. – Кояш чыкканда йоклап ятсаң, беләсеңме ни була? – Ул кызның колагына иелде: – ...йон чыкмый кала!

Кыз, әйе, Амилә урыныннан корт чаккандай сикереп торды. Картый нәберәсен кочаклап алды.

– Үсеп беткәнсең бит инде, йөрәк маем, күкрәгең дә әнә бөреләнеп килә. Бераздан, һии...

Ул аны ашыктыра-ашыктыра, кыстый-кыстый чәй эчерде. Үзе һич тынмыйча сөйләнә иде. Амилә инде аны аңлый да башлады сыман. Сүз сөрешен чамалый кебек иде ул аның. Тик әле авыз күтәреп кушыла гына алмый.

– Хәзер урманга барабыз, – ди картый. – Урман, пуняла?

– Пуняла, – ди Амилә.

– Әнә ул урман, авыл өстенә егылырга тора. Шунда бармыйча, авылда яталармы, юләр? Өйдә, шәһәрдәге кебек, үз исеңне иснәп...

Чыннан да, урман авылга ерак түгел икән. Һавасын сулагач, Амиләнең башы әйләнеп китте. Чәчәкле аланга килеп чыктылар. Картый иелеп үлән җыя башлады.

– Менә балтырган, мәле-мәле, ашап кара әле... Тәмлеме? – Ул болай гына кыстап калмый, табигать нигъмәтләрен кызның авызына ук тыга иде. – Һи, сез аның тәмен беләсезмени... Менә кузгалакны кап әле! Төкермә, юләр... Менә монысы – юа... Яле-яле, суган тәмәтәме берсәк?

Картый артыннан кичкә кадәр йөри-йөри, Амилә алҗыды, аяклары сыдырылды, черки талады.

– Бераз тамак ялгап алыйк, – диде картый, төенчегеннән ипи кисәге, ике пешкән бәрәңге, ике йомырка чыгарды. Андый тәмле ризыкларны Амиләнең беркайчан да татыганы юк иде! Ашап алганнан соң, ял итеп алдылар. Күк йөзе шундый тирән һәм серле. Болытка утырып, ак сакаллы Алла бабай килеп чыгар кебек. Картыйның Алла бабайны күргәне бар микән? Күрсә дә күргәндер, ул бит үзе дә бик карт икән, йөзгә җиттем, диме... Алланың улын да беләдер әле.

– Алла ул – берәү генә, аның улы да юк, хатыны да. – Әллә Амиләнең уен укый инде ул? – Ул бит кеше түгел үрчергә. – Картый торып басты, җыйган үләннәрен икегә бүлеп бәйләде. Кечкенәрәк бәйләмне Амиләнең җилкәсенә салды, зурысын үзе күтәрде. – Кайтырга вакыт. Югалтканнардыр безне. Әле Хәйрүшләргә ашка барасы да бар.

Бәйләм җыйнак булса да, аны күтәреп бару кызга кыенга килде, йөкне ул әле уң җилкәсенә, әле сулына күчерде. Ә картыйның исендә дә юк – юырта гына! Йөрешен үзгәртми генә сүзгә керешә әле:

– Исеңдә калдыр, кызый, сорасалар, әйт: Аллаһ – берәү генә! Аллаһ мәңгелек. Аны беркем тудырмаган, Ул беркемне тудырмаган. Һәм Аның тиңдәше юк.

Амилә йөгерә-атлый моңа кадәр гадәти булмаган сүзләрне кабатлады: «Аллаһ – берәү генә! Аллаһ мәңгелек...» Ул да булмады, картый бөтенләй ят телдә көйләп җибәрде: «Күл һү Аллаһу әхәд, Аллаһу сәмәд...»*

Амилә үзе дә сизмәстән картый артыннан кабатлый башлады, адымнары җиңеләйде, иңендәге үлән бәйләме дә бөтенләй онытылды. Ул бу халәтне олыгайган саен еш искә төшерер, ләкин серенә төшенә алмас... Ниндидер бер сәмави кодрәт аны үз ихтыярына алган һәм очырып алга алып бара иде. «Күл һү Аллаһу әхәд», – дип кабатлады ул һәм йөрәге белән аңлады: Аллаһ берәү генә һәм Ул мәңгелек!

Кайтуларына капка төбендә озын буйлы, ябык бер ир-ат көтеп тора. Ул тәмәке тарта иде, ахрысы, боларны күргәч, тәмәкесен каядыр яшерде.

– Нигә көттерәсез инде, муллаттәй, кунаклар күптән җыелды, Курән укыргае, – дип каршы алды ул аларны. Үзе озын булса да, тавышы шактый сыек чыкты.

– Бар, бар, елап торма, кайта тор, менә нәберәбез белән бик тиз килеп җитәрбез.

– Беләбез инде сезнең тиз дигәнне, – дип зарлана-зарлана, адәм тәганәсе китеп барды.

– Үзегез укый белсәгез, көтмәс идегез! – дип, картый кычкырып калды.

Алай да бик кичекмәделәр, җәһәт кенә юынып, киемнәрен алыштырдылар да мәҗлескә килеп тә җиттеләр. Өй эче урталай чаршау белән бүленгән, карчыклар – түр якта, берничә карт-коры ишек катына урнашкан иде. Әлеге бабайларны күргәч, Амилә имәнеп китте. Берсе, авызын каплап, минут саен гырык-горык йөткерә, чигәсендәге тамырлар шартлардай булып кабарып чыга, икенчесенең күзеннән бертуктамый яшь ага, ул аны керле кульяулыгы белән ара-тирә сөрткәләп тора.

Ахыры бар >

* Коръән-Кәримнең «Ихлас» сүрәсе (112).

«ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН»

медицина тикшеренүе узу өчен СЕРТИФИКАТ уйната

1 ЯЗЫЛ!
2023 елның
икенче яртыеллыгына
«ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН»
газетасына языл

П2435 – җомга саны
512 сум 70 тиен
П2409 –
атнага дүрт тапкыр чыга
1227 сум 30 тиен

2 КВИТАНЦИЯ КҮЧЕРМӘСЕН БЕЗГӘ ҖИБӘР!
89179270040 info@vatantat.ru
420097, Казан шәһәре, Академия урамы, 2 нче йорт.

3 БҮЛӘК ОТ!

Сертификатлар:
1) 9 төрле УЗИ+уролог консультациясе;
2) 9 төрле УЗИ+гинеколог консультациясе;
3) остеопат ярдәме.

Тулырак сайтта: vatantat.ru

Акция 2023 елның 28 апреленнән башлап 30 июнена кадәр дәвам итә.
Акцияне оештыручы – ТР ДБУ «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
Реклама 16+

МЦ «НУРМЕД»

«Сәламәт хатын-кыз»
*АКЦИЯ ~~5 100 сум~~ 3 100 сум

(843) 246-76-00
(843) 209-19-29

Анализлар. Кече оча әгъзаларына УЗИ.
Сөт бизләренә УЗИ. Гинеколог консультациясе.

Адрес:
Салих Батыев ур., 1 йорт

*Акция 2023 елның 30 маена кадәр дәвам итә.

Тулырак сайтта: nhkrt.ru

ТИСКӘРЕ ЙОГЫНТЫСЫ БУЛЫРГА МӨМКИН. ТАБИБ БЕЛӘН КИҢӘШҮ СОРАЛА.
Реклама 18+

...-том
... Ямашев
Мал-...
Уфа башкортча
... Туфан
Казандагы балалар радиосы
Сүзләрне карап аңлау
Сәяхәт
Кечкенәнең антонимы
... Маккартни
Лычма
Бая
«Азат ...» журналы
Ислам һәм христиан

Франциядә елга
Чор
Актер ... Шакиров
Онлайн хуплау
Үҗәт кош
Очырта торган җил
«... һәм Гита»
«... Юпитер 5» мотоциклы
Җырлы көймә
...-кура
Кисәкчә
Эчтәге кешегә боерык
Мошенник
Плотник эш коралы
Фирка
Бер ярты
Ганадагы елга
Ишарә
... Аллегрова

Бөҗәк
Кайбыч районы авылы
Табыну сыны
Бахбай
Урманда аяк астында
Колга муенлы җәнлек
Катык + су
Ислам уку йорты
Туган ...
Авылда югары ... һәм түбән ...
Франциядәге шәһәр
«..., йөрәгем, су бирегез»
Әйбер хуҗасы
«Матрица» кино герое
Татарча холодец
Барабан әйләндерүче
... Харатьян

БРИГАДА СТРОИТЕЛЕЙ ВЫПОЛНИТ ВСЕ ВИДЫ СТРОИТЕЛЬНЫХ РАБОТ ИЗ СВОИХ МАТЕРИАЛОВ:

• КРОВЕЛЬНЫЕ РАБОТЫ • САЙДИНГ
• БЕТОННЫЕ РАБОТЫ • ФУНДАМЕНТЫ
• ВОССТАНОВЛЕНИЕ СТАРЫХ ДОМОВ
• ПЛОЩАДКИ, ОТМОСТКИ
• ВЕРАНДЫ, ПРИСТРОЙКИ
• ХОЗБЛОКИ
• ВНУТРЕННЯЯ ОТДЕЛКА.

реклама 16+

Обращаться по тел.: 8(960)030-75-99, Николай.

Сканворд җаваплары

Горизонталь: тәм, Хәсән, Өфө, уку, Пол, сәфәр, зур, әле, хатын, дин, Ор, Әзһәр, давыл, Иж, каралты, ни, чык, алдар, ышкы, ым, пот, сирф, ат, РИУ, әйрән, Фәнис, ия, койка, Якубович.

Вертикаль: теплоход, партия, аракы, Оти, як, мәлкәт, вакыт, уф, лыгыр, Хөсәен, лайк, Нео, Саф, Зита, Мәски, ылыс, оч, Нурзадә, Дмитрий, Ирина, тукран, жираф, Нуар.

Беләсең килсә...

1 Автомобиль тәгәрмәченең тыны кирәгеннән кимрәк булса, ягулык куллану нишли?
а) кими;
б) арта;
в) үзгәрми.

2 Бу шәһәр дөньяда иң борынгы санала:
а) Яньши (Кытай);
б) Иерихон (Палестина);
в) Иерусалим (Израиль).

3 Мондый эт токымы юк:
а) бульбаш;
б) акбаш;
в) карабаш.

4 «Рәхмәт» сүзе удмуртча ничек була?
а) сюкпря;
б) тавтапус;
в) тау.

Җаваплар:
1. б); 2. б); 3. а); 4. в).

Сәхифәне Данил СӘФӘРОВ әзерләде

Баш мөхәррирнең беренче урынбасары – ХӨСНУЛЛИН Илнар Хәлил улы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Индекс П2435
Тираж – 14253 данә

Газетага сертификат бирелде
Заказ 284

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+